З.Н. Хәбибуллина, Х.Г. Фәрдиева,
Ә.Н. Хуҗиәхмәтов

Татар әдәбияты
8



Татар әдәбияты 8

В. Маликов.
Сугышта һәлак булганнарга монумент

З. Н. ХӘБИБУЛЛИНА, Х. Г. ФӘРДИЕВА,
Ә. Н. ХУҖИӘХМӘТОВ

Татар әдәбияты

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
8 нче сыйныфы өчен дәреслек

(*татар балалары өчен*)

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
тәкъдим ителгән*

Яңартылган өченче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1.821.512.145*08
ББК 83.3(2Рос=Тат)я72
Х82

Фәнни редакторы филология фәннәре кандидаты
Ф. Г. Галимуллин

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Хәбибуллина З. Н.

Х82 Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 8 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен)/ З. Н. Хәбибуллина, Х. Г. Фәрдиева, Ә. Н. Хуҗиәхмәтов.— Яңартылган 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2005.— 207 б.

ISBN 5-7761-1469-1

ISBN 5-7761-1469-1

© «Мәгариф» нәшрияты, 1999, үзгәрешләр белән
© «Мәгариф» нәшрияты, 2005, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

Кадерле укучылар!

Сез алдагы сыйныфларда да ана телендә язылган матур әдәбият әсәрләрен укыдыгыз. Туган телнең матурлыгы, бизәкләре, әсәрләрдәге гүзәллек дөньясы белән таныштыгыз. Быел да бу дәреслек сезгә фикердәш, юлдаш булыр.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, аерым алганда бәетләрне укып, халкыбыз тарихын тагын да тирәнрәк аңларсыз. Күренекле язучылар иҗатын өйрәнү белән бергә, татар сәнгатен үстерүгә күп көч куйган артистлар, рәссамнар, композиторлар иҗаты белән дә танышырсыз. Мөгаен, яраткан язучыларыгызның әсәрләрен үзлектән дә укый башларсыз.

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

БӘЕТЛӘР

Бәетләр халык иҗатының башка төрләреннән язма әдәбиятка якын торулары белән аерыла. **Бәет** — татар халык иҗатының лиро-эпик жанры. Аның нигезендә, күпчелек очракта, кайгылы яки көлкеле вакыйга ята. Тормышта төрле фаҗигале хәлләр булып тора. Халкыбыз шушы вакыйгалар уңаеннан бәет иҗат итә. Дөресрәге, моң, хәсрәт халык күңеленнән бәет булып бәреп чыга. Мондый әсәрләр бер дәфтәрдән икенчесенә күчә, аннары телдән телгә сөйләнеп йөри. Тора-бара аларның кем тарафыннан, кайчан чыгарылганы онытылып, кайберләре әдәби мираска әверелә, кайсысы шул килеш кәгазь битендә кала. Халык телендә «бәет әйтү», «бәет чыгару» дигән сүзләр бар. Бу — бәетләрнең язу килеп кергәнгә кадәр иҗат ителә башлавын күрсәтә.

Бәет — гарәп сүзе, *ике юллык шигырь* мәгънәсен аңлата. Кайбер галимнәр аны җырлана-сөйләнә торган **хикәят** дип йөртәләр. Бәетләр көйләп әйтелә. Шуңа күрә халык телендә аны **мөнәҗәт, җыру** дип тә атау бар. Бәетләр көйле, рифмалы булулары, ритмик төзелешләре, ике яки дүрт юлдан торулары белән җырларга охшаган. Ләкин бәет нинди дә булса бер сюжетка корылган була, һәм анда тормышта булган берәр вакыйганы сурәтләү төп максат итеп куела.

Билгеле булганча, татар халкының язма мәдәнияте борынгыдан килгән. Тарихи чыганакларда Болгар илендә IX—X гасырларда ук башлангыч мәктәпләр булуы әйтелә. Укый-яза белү киң таралган халыкта шул вакытта ук ил тормышын, яу-көрәшләрне тасвирлый торган эпик әсәрләр язма рәвештә теркәлә барган.

Бәетләр тарихи вакыйгаларга һәм шәхесләргә, авыр замана, ирексез хезмәт һәм хатын-кызларның михнәтле язмышына, шәхси фаҗигаләргә багышлана. Мәсәлән, безгә билгеле булган «Казан бәете» һәм «Сөембикә бәете»ндә Казанның

руслар тарафыннан алыну вакыйгасы сурәтләнгән. «Рус-француз сугышы», «Җиде кыз», «Урта Тигәнәле», «Ышна», «Сак-Сок» бәетләре шулай ук тормышта булган төрле хәлләргә нигезләнеп чыгарылган.

Бу жанрның төп сәнгатьчә алымы — бәян итү, хикәяләү, сөйләү, әйтү. Ул тормышта булган вакыйгаларны нәкъ шул вакытында ук тасвирлый, хис-кичерешләрнең иң киеренке вакытларында туа. Бәетнең бу үзенчәлеген Г. Тукай болай билгеләп: «Чү, аз гына бер нәрсә «шылт» иттеме, инде аның тугърысында иртәгә урамга бәетләр чыга».

Бәетләрдә сүзләрне иске әйтелештә куллану хәзерге заман әсәрләрендә дә саклана. Халык иҗаты әсәрләрендә, мәсәлән, *мин, син* сүзләре урынына *бән, сән; Казаннан* сүзен *Казандин* дип әйтүне очратырга мөмкин.

Бәетләрнең төзелеше шактый төзек, төгәл. Ул, гадәттә, «Тарих мең дә фәлән йөздә» кебек вакытны күрсәтә торган яки «Бисмиллаһи вә билләһи» һ. б. сүзләр белән башлана, тыңлаучыга нәрсә турында сүз барасы алдан әйтелеп куела. Бетем өлешендә авторы (күчерүчесе), исемен әйтеп, үзенә хәер-дога кылуны да үтенергә мөмкин.

«шылт» иттеме — нинди дә булса вакыйга булдымы

«Сак-Сок» бәете турында

«Сак-Сок» бәете бүгенге көндә халык арасында иң киң таралган бәетләрдән санала. Ул — халыкның иң яраткан әсәре. Иске кулъязмаларда, китап читләрендә, җыр-бәет, истәлек дәфтәрләрендә, халык телендә бу бәетнең дистәләрчә вариантлары саклана. Әсәр күп тапкырлар басылып та чыккан.

Бәеттә Сак һәм Сок дигән кошларга әйләнгән ике бала язмышы фаҗига, моң белән сурәтләнгән. Әсәрнең нигезендә «Ана каргышы төзәтеп булмас бәхетсезлекләргә китерә» дигән фикер ята. Әкият һәм риваятьләрдә киң таралган алым бу бәеттә дә үзенчәлекле файдаланыла: Сак белән Сок «кавышабыз дигәч, хәзер таң ата».

«Сак-Сок» бәете үзенә бер билгеле көй белән әйтелә. Хәзер дә аның үрнәгендә, аның шигъри калыбында яңа бәетләр чыгарыла. Элеккеге кайбер бәетләрне дә аның көенә башкара-

лар. Мәсәлән, «Сак-Сок» көенә мөнәҗәт көйлим, дип әйтүләрне ишетергә мөмкин.

«Сак-Сок» бәете башка бәетләргә хас булмаган хыялый сюжетка корылган. Әниләре, тимер укны рөхсәтсез алган өчен ачуланып, ике баласын каргый. Ана каргышы аркасында балалары, кошларга әйләнеп, кыргый урманда очып йөриләр. Бәетнең сюжеты бик ачык түгел. Г. Тукай сүзләре белән әйтсәк, «сюжетны иснәп кенә диярлек сизәргә мөмкин».

«Сак-Сок» бәетендә жанрның иң төп элементлары, иң шомартылган өлгеләре җыелган.

Аклы күлмәкне туя кимәдем,
Газиз әнкәмне туя күрмәдем.

Калган киемне алып куярсың,
Исеңә төшкәч, карап еларсың,—

кебек юлларны аерылышуга бәйле чыгарылган һәр бәеттә диярлек очратырга мөмкин.

САК-СОК

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен ишетәсе.

Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Әнкәй орышты тимер ук өчен,
Әнкәй орышты бигрәк юк өчен.

Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан,
Әнкәй каргады безне ачудан.

Самавыр куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды.

Яңа тунымны ботак ерткандыр,
Гомерем беткәнгә, нәфсем тарткандыр.

Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип,
Әнкәй каргады, Сак-Сок булсын, дип.

Кыйбла ягыннан җилләр исәдер,
Безнең ризыкны әнкәй кисәдер.

Бардык урманга, җыйдык карлыган,
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.

Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез туганчы тәкъдир язмышы.

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.

Су буйларында бик күп йөрдек без,
Сак-Сок булгачтын, дөнья гиздек без.

Кистем пар нарат яңа ызбага,
Ике күземдин канлы яшь ага.

Су буйларында бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә, өзелә үзәкләр.

Аклы күлмәкне туя кимәдем,
Газиз әнкәмне туя күрмәдем.

Бер ел тулганчы, кайтам дип йөрдем,
Бер ел тулгачтын, өметне өздем.

Урыныбыз урман, икебез туган,
Кавышу юк безгә, әнкәй каргаган.

Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.

Кояш чыкканда, кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.

Бардым урманга, кистем пар каен,
Газиз әнкәмне сагынам көн саен.

Мамык эшләпә алып кайтыгыз,
Әнкәйне күргәч, сәлам әйтегез.

Яңгыр явадыр, әнкәй, башыма,
Елап килдек без, әнкәй, каршыңа.

Әнкәй елыйдыр, ник каргадым, дип,
Сак-Сок йөридер, харап булдык, дип.

Бардык урманга, җиләкләр пешкәч,
Әнкәй елыйдыр, исенә төшкәч.

Кара карлыгач, сары сандугач,
Әнкәй, елама, үзең каргагач.

Болай булдык без: каргыш тәдбире,
Елама, әнкәй,— Ходай тәкъдире.

Калган киемне алып куярсың,
Исеңә төшкәч, карап еларсың.

Китап укырсың, гыйбрәт алырсың,
Кошлар үткәндә, карап калырсың.

Имезгән сөткә, әнкәй, өрсәнә[1],
Кыямәт көндә бәхил булсана.

Газиз әнкәем, бер сүз әйтәем,
Бәхиллек бирсәң, өйгә кайтаем.

Мамык эшләпә җилгә очырдым,
Ике баламны каргап очырдым.

Мендек ботакка, карадым як-якка,
Ике баламны каргадым юкка.

Җәйгән җәймәмнең калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.

Моңлы моңлансын, зарлы саргайсын,
Балаң очырдың, кемгә еларсың?

Мәдрәсә-мәсҗед, пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Анадан тугач, тәкъдир язмышы.

---

[1] Кайбер вариантларда бу сүз урынына *белсәнә, сусама, су салма* кебек сүзләр дә китерелә. Биредә «Сөтен имезгән ана каргышы кире кайтмый» дигән ышану чагылыш тапкан.

Идел буенда диңгез камышы,
Кара урманда Сак-Сок тавышы.

Сары күлмәгем һич тә кимәдем,
Өйдән чыкканда, сау бул, димәдем.

Җәй көннәрендә сайрый сандугач,
Әнкәй, елама, үзең каргагач.

Якты дөньяны күрми калабыз,
Каргады безне газиз анабыз.

Әткәй калдыргач, өйдә калдык без,
Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без.

Йокыга киткәч, бер төш күрдек без,
Җәй көннәрендә ялгыз йөрдек без.

Су буйларында балалы үрдәк,
Исемә төшкәч, өзеләдер үзәк.

Алты яшьләрдә бергә йөрдек без,
Җиде яшьләрдә Сак-Сок булдык без.

Ишегалдында җиктем пар кара ат,
Әнкәй каргагач, яралды канат.

Бардым урманга, сайрый сандугач,
Һушларым китте эзләп булмагач.

Күз яшьләремнең калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.

Әнкәй, токмачны үзең күп иттең,
Әткәй кайтканчы, безне юк иттең.

Әткәмез калды безнең мәчеттә,
Без тилмерәбез икебез читтә.

Яшел путамны урый белмәдем,
Өйдән чыкканда, сау бул, димәдем.

Әнкәй, кер юдың суның буенда,
Сак-Сок булыр дип юктыр уеңда.

Бардым урманга, бастым баланга,
Балам кычкыра кара урманда.

Ишегалдымда имән дугасы,
Әткәй, елама — әнкәй догасы.

Элекке көнне икәү уйнадык,
Әнкәй каргар, дип, без уйламадык.

Әнкәй каргады, әткәй, белдеңме?
Турыңнан очтык, әткәй, күрдеңме?

тимер ук — бер башы очлы итеп эшләнгән борынгы корал
нәфес — артык күпне өмет итү, комсызлык
кыйбла — көньяк, Мәккә шәһәренә караган як
кибән — ачык һавада саклау өчен салам яки печәннән салынган зур чүмәлә
кыямәт — *дини тәгълимат буенча:* ахырзаман җитеп, үлгән кешеләр терелгәч, Алла тарафыннан аларның хөкем ителә торган көне
тәдбир — уйлап эшләнгән чара, нәтиҗә
тәкъдир — язмыш, күрәчәк

Сораулар һәм биремнәр

1. Бәетнең нигезендә нинди вакыйга ята?
2. Бәеттә сурәтләнгән барлык күренешләр дә чынбарлыкка туры киләме?
3. Ананың каргышы балаларга нинди бәхетсезлек китергән?
4. Балалар үз гаепләрен таныйлармы? Аларның әти-әниләренә мөнәсәбәтен аңлатыгыз.
5. Бәетнең эчтәлеген үз сүзләрегез белән сөйләгез.
6. Сез тагын нинди бәетләр беләсез?
7. Бәетләр ничек укыла?
8. «Сак-Сок» бәетен көйләп укыгыз.

«Сөембикә бәете» турында

Сөембикә — Нугай морзасы Йосыф кызы. Аны Мәскәү тарафыннан Казанга хан итеп куелган Җангалигә кияүгә бирәләр. Ләкин алар арасында мәхәббәт хисе булмый. Мәскәү сәясәтен генә үткәрүдә һәм милләт мәнфәгатьләрен кайгыртмауда гаепләнеп, 1536 елда Җангали Казан бәкләре тарафын-

нан үтерелә. Хан булып, Казанга Сафагәрәй кайта. Сөембикә Сафагәрәйгә кияүгә чыга. Алар бик тату һәм яратышып яши башлыйлар. 1547 елда уллары туа. Аңа Үтәмешгәрәй дип исем кушалар. 1549 елда Сафагәрәй вафат була, Сөембикә баласы белән тол кала. Озакламый Үтәмешгәрәйне хан итеп игълан итәләр. Малай үсеп җиткәнче, дәүләт белән Сөембикә идарә итәргә тиеш була.

Казан феодаллары, аксөяк-морзалар, әле Мәскәү, әле Кырым яклы төркемнәргә бүленеп, Сөембикәгә каршы көрәшә башлыйлар. Казан ханлыгын саклап калу максатында, аны, улы белән бергә, Мәскәү карамагына тапшыралар. Бу вакыйгадан соң Йосыф бәк һәм Нугайның башка морзалары, Сөембикәне үзләренә кайтаруны сорап, Явыз Иванга берничә мәртәбә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин аны әтисенә кире кайтармыйлар, Касыйм ханы Шаһгалигә хатынлыкка бирәләр. Ә биш яшьлек улы Үтәмешгәрәйне, анасыннан аерып, Мәскәүдә калдыралар; чукындырып, исемен Александрга үзгәртәләр.

Халык арасында Сөембикә турында төрле риваятьләр йөри. Аларның берсендә Сөембикәнең, руслар кулына бирелмәс өчен, манарадан ташланып үлгәнлеге турында сөйләнә.

«Сөембикә бәете»ндә Сөембикә күп кайгы һәм хәсрәт кичергән гүзәл хатын-кыз буларак тасвирлана.

Әдәбиятта аның образына бик күп язучылар мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, рус язучылары тарафыннан XVIII гасырда берничә трагедия иҗат ителгән. Сөембикә язмышына М. Гафуриның «Сөембикәнең актык көне» шигыре багышланган. Шулай ук Р. Батулланың «Сөембикә», М. Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романнары — Сөембикә образына багышланган иң күләмле әсәрләр. Төрек язучысы Илгаз Ваһап Нәүрүзханның «Сөембикә» романы, татарчага тәрҗемә ителеп, 1992 елда дөнья күрде.

Казан шәһәренең иң абруйлы урынында — Кремльдә — Сөембикә исеме белән бәйле манара бар. Сөембикә манарасы шәһәребезнең эмблемасына әйләнде. Ул — милли архитектура үрнәкләренең иң күркәме һәм иң атаклысы. Шәһәребезгә килгән кунаклар аның мәһабәтлелегенә һәм күккә ашып торган матур эшләнешенә сокланалар. Хәзер аның башында алтын ай балкый. Ул 1990 елда куелды. Аны Шамил Сәфәров җитәкчелегендәге осталар ясады.

СӨЕМБИКӘ БӘЕТЕ

(Казанны алган көйгә)

Мең биш йөз унбиштә бу дөньяга килгәнмен,
Ата-ана дәүләтен китмәс диеп белгәнмен.

Ата-ана кулында бер кайгы да күрмәдем,
Бу кайгылар күрермен, дип, исәпләп тә йөрмәдем.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем яшь дәүләтем,
Сабый чагым, нурлы йөзем, морза кызы булган вакытым?

Унсигез яшьләрем тулган чакларымда,
Хан хатыны булдым мин ата-ана хакларында.

Кырымнан Казанга китерде тәкъдирем,
Казанның яшь ханы Җангали булды ирем.

Җангали хан мәкътүл бер залим кулыннан,
Бәндәгә казалар очрыйдыр юлыннан.

Ханбикә булгачдин, ике ел торгачдин,
Тол калдым кайгылы, хан дөнья куйгачдин.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан дәүләтем,
Сылу чагым, нурлы йөзем, хан бикәсе булган вакытым?

Кырымлы Сафагәрәй Казанга хан булды,
Өч хатыны булса да, дүртенчегә мине алды.

Дөньялар хафалы, замана буталды,
Казанга күрше падишаһлар күз салды.

Казан эче тынычсыз, дошман бары беленә,
Дәүләте бар кешеләр керә кеше теленә.

Сафагәрәй вакытында бик күп булды сугышлар,
Һәркайдан яу килгәчдин, авыр булды сулышлар.

Гомерем үтте ундүрт ел Сафагәрәй хан белән,
Казан шәһәре күңелсез юлда түккән кан белән.

Шәһәр тышында сугыш, эчендә тулган афәт,
Шул тынычсыз вакытта Сафагәрәем вафат.

Ике яшьлек угылым, күзем нуры, колыным,
Үтәмешгәрәем калды ятим, былбылым.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем яшь дәүләтем,
Үзем дә тол, угылым ятим, кайда минем тыныч вакытым?

Мәскәү ханы Казанны алмак була үзенә,
Казанлылар фетнә ача, карамыйлар сүзенә.

Мәскәү ханы үгетли картны, яшьне, егетне,
Бирелегез миңа, ди, тотармын җәбер итми.

Морзалар сүз аңламый, көчләре аз сугышка,
Ничә кабат сүз бозып, барды алар солыхка.

Солых шартын тагын да бу морзалар боздылар,
Нугай, кырым, казанлылар төрле җиргә туздылар.

Хан урынына хан булып торалмадым пан булып,
Гаҗизләндем морзаларга, йөрәгем, бәгърем кан булып.

Башкара алмыйм эшне, тыңлата алмыйм кешене,
Һәркайсысы белгән булып йөреттеләр эшне.

Хан кабере өстенә кордырдым таш манара,
Дидем: «Үзем үлсәм дә, исемем күп елга бара».

Манараны коргачдин, көнләштеләр халемә,
Мәскәүгә хат яздыра шул көндәшем залимә.

«Сугыш өчен Сөембикә манараны салды,— дип,
Тагы язган: — Кырымнан яңа гаскәр алды,— дип.

Миндә ул ният булмады, мин сугыш теләмәдем,
Морзаларның юк фикерен күземә дә элмәдем.

Мәскәү әйтә, сугышмагыз, мин Казанны алырмын,
Рәнҗемәгез, ахырында яхшы ук җәфа салырмын.

Шуны ишеткәч, Кырымга китәргә дә уйладым,
Күрәчәкләр булганга, кабул түгел теләгем.

Карыштылар морзалар, Мәскәү сүзен алмыйлар,
Каршылыкны мәскәүләр миннән диеп аңлыйлар.

Казан — Мәскәү арасында тагын бер сугыш булды,
Җиңелгәчтен казанлылар, солыхка киңәш кылды.

Мәскәү соңгы солыхны башкаларга яд кыйлган,
Мине Мәскәүгә озатуны солыхка бер шарт кыйлган.

Казандагы кенәзләр үзе тыныч булырга,
Һәркаюсы кул куйганнар мине әсир кылырга.

Әмер булды китәргә, көймәләргә җитәргә,
Күзләремдин нур китте, белмим нихәл итәргә.

Мине, тотып, ике адәм утырттылар арбага,
Тәхет, бәхет калдырып, көймә янына бармага.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан дәүләтем,
Күңелем моңлы, йөзем сары, күзем яшьле, әсир вакытым.

Күзем салдым халыкка, күбе җылап озата,
Кайсылары: «Мәскәү ханы рәхимле»,— дип юата.

Шәһәр тәмам гүлидер, җылау-сыктау тавышы,
Миңа төшкән кайгылар — морзаларның табышы.

Уйлап алдым: кыямәт купканмы әллә бүген, дип,
Тагы уйладым, җылаучылар минем кебек түгел, дип.

Барып җиткәчдин дәрьяга, кереттеләр көймәгә,
Газиз телләрем бәйләнде, белмим ни сүз димәгә.

Кайсы әйтәдер «әлвидаг», кайсы әйтәдер «әлфирак»,
Мин әйтәмен: «Бәхил булың, киттем инде бик ерак».

Халык калды җыгылып, һушсыз булып бирексә,
Көчле адәмнәр нишләми, булганнары иректә.

Волгига чыкканда, карадым мин калага,
Калды җылап Казаным, охшап үксез балага.

Дидем: «Мескен Казаным, төште таҗың башыңнан,
Калдың бүген дәүләтсез, чишмә агар яшеңдән.

Кайда калды шатлыгың, кайда сәнең байлыгың?
Күрер күзгә билгеле хәзер кол, гидайлыгың.

Бушап калды сараең, нурың китте үзеңдин»,—
Дип җылап, Казанны югалттым мин күземдин.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан дәүләтем,
Хансарайда торган идек, бүген булдык әсир, ятим.

Манарам күренде күп җирләргә җиткәнче,
Тагын да бер җыладым хәлләрем беткәнче.

Дидем: «Ярабби, манарам, белмисең, кайда барам!
Калдырдым инде сәни, тәкъдиргә юкдыр чарам.

Хан өстенә корылдың, таштандыр сәнең җисмең,
Җимерелгәнче йөрермез исемем белән һәм исмең».

Шулай сөйләп барганда, манарам да җугалды,
Җугалуга сәбәп шул: көймә бик күп юл алды.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан дәүләтем,
Күңелем моңлы, күзем яшьле, үзем әсир, угылым ятим.

Көймә китте кузгалып, карчыгадай кошны алып,
Миндәй гарип бичарадин гакылны, һушны алып.

Бара торгач, без җиттек Зөя дигән калага,
Килде андагы бояр, морза безне күреп калмага.

Барып җиткәчдин Зөягә, анда без өч көн тордык,
Чыкмадык без бер җиргә, көймә эчендә утырдык.

Андин киттек Мәскәүгә, күреп сәфәр михнәтен,
Әсир булып барабыз, күрми дөнья зиннәтен.

Күп заманнар баргачдин, Мәскәүгә барып җиттек,
Бу бәхетсез башларга ни була дип без көттек.

«Кызлар мәйданы» дигән бер урынга илттеләр,
Бераз карап торгачдин, безне йортка керттеләр.

Кергән йортка каравыл куйдылар бер ун кеше,
Чыгармыйлар, йөртмиләр һәм кертмиләр бер кеше.

Көн дә уза, төн дә уза, хәсрәтдин тәнем сыза,
Ике бояр килгән бер көн, берсе: «Айда!»— дип кул суза.

Әсир булгач ни чара? Кузгалдым мин, бичара,
Балам белән икебезне кая алар алып бара?

Барып кердек зур йортка, эчендә аның хансарай,
Күп кешеләр җыелган, барысы да безне карай.

Падишаһ та шунда үзе, миңа әйтә бер сүзне:
«Балаң монда асралыр, иргә бирәм мин сезне»,—

Диеп. Шунда баламны кулымдин да алдылар,
Әсирлектән янган идем, тагын утка салдылар.

Ишеттем мин баламны поплар алганнар диеп,
Гакылы да юк сабыйны диннән чыгарганнар дип.

Сөембикә атым, нугай затым, калды минем хан дәүләтем,
Күңелем моңлы, күзем яшьле, калдым ялгыз, әсир, ятим.

Мин киткәчдин, көндәшем, китте инде, дип, Сөембикә,
Үзенә ир кайгыртып, булмак булган ханбикә.

Халык белән киңәшеп, Астархандин хан алган,
Яшь кенә кенәз икән, исеме Ядегәр хан булган.

Көндәшем ханга барган, Казанны һәм тотам дип,
Дөнья әйткән: «Ашыкма әле, сәни дә утка атам»,— дип.

Шул елны ук мине дә падишаһ бирде бер ханга,
Касыймдагы Шаехгали, Казанга дошман җанга.

Мине алгач, сугышка әмер булды барырга,
Мәскәүләр белән бергә Казанны һәм алырга.

Сөембикә атым, нугай затым, кайтса да шул хан дәүләтем,
Казаным юк, күңелем моңлы, онытылмый һич хәсрәтем.

Шаехгалиләр барганлар, Казанны һәм алганлар,
Мине саткан морзаларның башын җиргә салганлар.

Ядегәр белән көндәшем тагы да кулга төшкән,
Мине яндырган утта үзе дә яхшы пешкән.

Гарип балам Үтәмеш тә алты яшенә җитте,
Фани дөньядан үтте, андин бер кайгым бетте.

Дөньяга килгән адәм кайгы күрмичә тормый,
Дөньяда шат йөргәннең дә тупракдыр ахыр урыны.

Сөембикә атым, нугай затым, күзем яшьле, юк рәхәтем,
Күрдем михнәт, чиктем газап, онытылмай һич хәсрәтем.

мәкътүл — үтерелде
залимә — мәрхәмәтсез хатын
дәрьяга — елгага
әлвидаг, әлфирак — хушлашу сүзләре
биректә — яр буенда
Волгига — Идел елгасына
гарип бичарадин — җәберләнгән, чарасыз калган мескен кешедән
падишаһ — Явыз Иван күз алдында тотыла

Сораулар һәм биремнәр

1. Бәеттән Сөембикәнең бала чагы, тормышы турындагы юлларны укыгыз.
2. Сөембикә ни өчен Казанга килә?
3. Ул нинди язмышка дучар була?
4. Сөембикә Казанны ни өчен калдырып китә?
5. Аның белән саубуллашуны халык ничек кичерә? Шул юлларны кабат укыгыз һәм үз сүзләрегез белән җавап бирегез.
6. Халкыбыз Сөембикәне ни өчен хөрмәтли, зурлый?
7. Бәетнең эчтәлеген үз сүзләрегез белән сөйләгез.
8. Тексттагы *торгачдин, килгәчдин, күздин, күргел, бармага* сүзләрен хәзерге телдә ничек кулланабыз?

Галиәсгар Камал
(1879—1933)

Галиәсгар Камал — егерменче йөз башы татар әдәбияты, мәдәнияте һәм сәнгате тарихында зур урын тоткан әдипләрнең берсе. Ул — татар театр сәнгатенә нигез салучы атаклы драматург.

Галиәсгар Камал 1879 елның 6 гыйнварында Казан шәһәрендә вак һөнәрче (мехчы) Галиәкбәр ага гаиләсендә туа.

Әдипнең беренче мәртәбә каләм тибрәтә башлавы Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку дәверенә туры килә. Монда ул шәкертләр белән кульязма журналлар чыгара башлый.

Г. Камал театр белән яшьтән кызыксына. Г. Ильяси, Ф. Халиди әсәрләрен яратып укый, Казан шәһәр театрына көндезге спектакльләргә йөри. Ниһаять, аның үзендә дә сәхнә әсәрләре язу теләге туа.

1898 елда ул «Бәхетсез егет» дигән беренче сәхнә әсәрен яза. Аннан соң төрекчәдән «Кызганыч бала» дигән пьеса тәрҗемә итә, «Өч бәдбәхет» драмасын яза һәм аларны бастырып та чыгара.

1905 елның 29 октябрендә Казанда беренче татар газетасы «Казан мөхбире» чыга. Г. Камал бу газетада иң күп катнашучыларның берсе була. «Азат», «Азат халык» газеталарын, «Яшен» сатирик журналын чыгаруда да Г. Камал зур эшчәнлек күрсәтә.

1906 елның 5 маенда Казанда беренче рәсми ачык спектакль уйнала. Галиәсгар Камалның төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Кызганыч бала» драмасы һәм Габдрахман Кәрамның тәрҗемә әсәре — «Гыйшык бәласе» комедиясе куела. Профес-

сиональ театр туу Г. Камалның иҗат дәртен тагын да арттыра. Аның 1907—1912 елларда язылган «Бәхетсез егет» (икенче варианты), «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Уйнаш», «Банкрот» һ. б. пьесалары — татар драматургиясе тарихында иң бөек нокталарны билгеләүче әсәрләр.

1929 елда ул «Хафизәләм иркәм» исемле комедиясен яза. «Күзсез мастерлар», «Өч тормыш» кебек пьесалары һәм күп кенә шигъри әсәрләре дөньяга чыга.

Г. Камал — оста тәрҗемәче дә. Ул Н. Гоголь, А. Островский, М. Горький, Мольер һәм башкаларның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Халкыбыз һәм хөкүмәтебез Г. Камалның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеген югары бәяли. Аңа Татарстанның халык драматургы дигән мактаулы исем бирелә.

Г. Камал 1933 елның 16 июнендә вафат була. Аның гәүдәсе Казандагы туганнар каберлегендә күмелгән.

рәсми — хөкүмәт тарафыннан расланган

«Беренче театр» комедиясе турында

Г. Камалның «Беренче театр» комедиясе 1908 елда Казанда «Гасыр» нәшриятында басыла. Шул ук елда сәхнәләштерелә дә.

Комедиянең төп темасы — кадимчеләрнең яңалыкка аяк чалулары, тормыш барышын туктатырга теләүләре. Язучы, Казан байлары тормышыннан бер вакыйганы алып, гомумиләштереп биргән.

Комедия Хәмзә байның кияве Вәли монологы белән башлана. Бу очраклы хәл түгел, чөнки Вәли — Хәмзә бай һәм аның кебекләрнең яшәү рәвешенә риза булмаучыларның берсе. Әсәрдә Хәмзә бай исә бөтен искелекне үзенә туплаган кире образ итеп бирелә. «Галиәсгар әфәнденең бу комедиясе,— дип яза Ф. Әмирхан,— нәкъ шул театр мәсьәләсенең кайнаган вакытында чыгуы белән бигрәк әһәмиятледер. Татарча театрларга каршы кешеләр үз кыланышларын шул ук татар театрына барып күрсеннәр!»

Әсәр ахырында Хәмзә бай көлкегә кала. Ул үзе кебек тискәре кешеләр белән, спектакльне булдырмас өчен, шәһәр буйлап чабып йөри. Ә үз өендә барысы да театрга киткәннәр.

Кызы Гафифә белән улы Хәбибрахман үзләре генә мондый кыю адым ясый алмаслар иде. Алар — этиләре Хәмзә бай тәрбиясендә үскән кешеләр. Ләкин өйдә кияү белән килен — чит гаиләләрдән килеп кушылган Вәли белән Факиһә бар. Вәли чыгышы белән өстен катлаудан түгел. Ул: «Без бит мужик! Безнең бабай сука сукалап үскән. Әти, чабата киеп, 12 яшендә калага килгән. Безнең шикелле кара икмәк ашап үскән кешегә кая инде ул ак сөякле булу?!» — ди. Шунлыктан татарча беренче спектакль куелган көнне аның өйдә утырып тормавы бәхәссез. Ул хатынын да театрга алып китә. Хәмзә байның килене Факиһә дә куркак ире Хәбибрахманны төрлечә юмалый-юмалый театрга алып бара. Байның кибетчесе Фатих, мәдрәсә шәкертләре һәм башкалар — барысы да театрга киткәннәр. Әсәрнең әһәмияте алдынгы фикерле яшьләрнең җиңүендә һәм искелекне яклаучыларның көлкегә калуында.

Г. Камал әйтүенчә, Хәмзә байның прототибы каенатасы була. Бу рольне ул чорда «Сәйяр» театр труппасының иң мәшһүр артисты Габдулла Кариев башкара.

кадимчеләр — искелек яклылар, яңалыкка каршы торучылар
сәйяр — сәяхәтче, дөнья гизүче

БЕРЕНЧЕ ТЕАТР

Комедия 1 пәрдәдә

УЙНАУЧЫЛАР:

Хәмзә бай — иске фикерле Казан бае; башында ак бүрек, яшел кәләпүш, өстендә намаз туны, аның эченнән бишмәт, аның эченнән кыска җиңле камзул кигән, чалбар балагын ак тасма белән бәйләгән.

Гафифә — Хәмзә байның кызы.

Вәли — Хәмзә байның кияве.

Хәбибрахман — Хәмзә байның улы, аңгыра.

Факиһә — Хәбибрахманның хатыны.

Биби — Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.

Фатих — Хәмзә байның кибетчесе.

Вакыйга Казанда, Хәмзә байның өендә бара.

Бай сымак бер өй. Ике якта икешәр ишек. Түрдә тәрәзәләр, тәрәзә арасында көзге. Стена буенда урындыклар. Сул тарафта бер

диван. Аның алдында өстәл. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә Вәли күренә; өстенә пальтосын кигән, кулына таяк тоткан, күңеле бик шат, өйнең бер башыннан бер башына кызу-кызу атлап йөри.

Вәли *(кычкырып)*. Гафифә! Гафифә!

Гафифә *(бүлмәдән сузыбрак)*. Әү!

Вәли. Буласыңмы инде?

Гафифә. Хәзер булам.

Вәли. Тизрәк бул! *(Халыкка таба карап.)* Гафифә дисәң Гафифә: бер җиргә бара башладың исә, кеше күрә дип коты чыга. Аның каршында ир кеше дигән сүз ерткыч җанвар дигән сүз белән икесе бертигез. Бары мин генә ул кадәр куркынычлы җанвар түгел. Башта миннән дә коты очты. Кияү булып кергәч, куркуыннан, куян шикелле, бер почмакка посып тик тора. Соңыннан, минем тарафтан шул яшенә җиткәнгә кадәр ата-анасыннан да ишетмәгән тәмле, татлы сүзләрне ишеткәч кенә, бераз җайланды. *(Ян ишеккә барып, ишеккә башын тыгып.)* Һи! Әле тиз генә буласың юк икән. Зинһар, тизрәк була күр! Әгәр каенатай кайтып керсә, аннан ары харап эш. Ничек итсә итәр, гомердә театрга җибәрмәс. *(Башын бүлмә ишегеннән алып, халыкка таба карап, куллары белән хатын-кыз битенә пудра сөрткән төсле итеп күрсәтеп, бераз көлебрәк.)* Бизәнә: мич акшарлаган шикелле итеп, битләрен буяп маташа. Шулай да булса, үзенә килешеп тора тагын. Уйлап карагыз, әгәр мин шулай итеп битләремне буйый торган булсам, һич килешмәс иде бит! Онга төшкән таракан төсле булыр идем. Безнең бер асрау бар, йөзе менә нәкъ чуенның ундүртенче кичәсе төсле кап-кара. Беркөнне шул асрау, абыстайлары өйдә юк чагында, барган да минем Гафифәнең пудырларын алып ягынган; бөтенләй менә, бигайниһи, бер ком гарәбенең битен акбурга буяган төсле булган. Көлешә-көлешә алҗып беттек. *(Бик җитди.)* Беләсезме? Ул бит пудыр күп кешегә килешми, хосусән, ирләргә бер дә килешми. Ә менә минем бер таныш егетем бар — Әхмәтҗан, ул һәр көнне өчәр мәртәбә сакалларын китәреп, пудырлар сөртеп йөри. Аңа килешә. Миңа бер дә килешми. Ул шул инде аксөяк нәселдән яратылган. Ә безнең нәрсә, без бит мужик! Безнең бабай сука сукалап үскән. Әти, чабата киеп, 12 яшендә калага килгән. Безнең шикелле кара икмәк ашап үскән кешегә кая инде ул ак сөякле булу?! Ак кына түгел, миңа карасы да килешми. Бервакыт хатын: «Бик матур була»,— дигәч, котырынып, шу-

шы мыегымны карага буяган идем. Ничә көннәргә кадәр кеше күзенә күренергә оялып яттым. Җитмәсә тагын, мыекка сөртәм дигәндә, битләремне буяп бетердем. Ә аның карасы тәннән һич китми икән... Тумыштан матур булып тумагач, спайланган булып маташу белән генә булмый инде ул. *(Ян ишеккә карый, төсләрен бозып.)* Ул нишләвең инде ул? Мин монда кайчаннан бирле, кайчан киенеп бетерә инде, дип көтеп торам.

Гафифә *(бүлмәдән)*. Җә, ярар ла, хәзер булам, пудыра матур төшмәгән.

Вәли. Тизрәк бул инде, зинһар! *(Башын бүлмәдән алып, ишекне ябып, халыкка таба карап.)* Менә сиңа кирәк булса, мин инде өстемә пальтоларымны кигәнгә бер сәгать булды. Ә ул әле һаман пудыр ягынып бетерә алмый; пудыр ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята. Әле ярый, көзге ямьсез күрсәтә дип, көзгене бәреп ватмаган. *(Уң як ишектән кулына поднос белән чынаяклар күтәреп чыгып, Биби узып бара.)*

Вәли *(Бибине күреп)*. Әй, Биби, тукта әле!

Биби *(борылып карап)*. Нәрсә дисең?

Вәли. Кара әле, ә!..

Биби. Карыйм ич инде!

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим, нинди нәрсәдер.

Вәли. Тфу, чорт! Сөйләп бетергәнне көт!

Биби. Я, көтәм.

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим!

Вәли *(ачуланып)*. Тыңлап тор, дим мин сиңа!

Биби. Тыңлыйм ич!

Вәли. Тыңласаң, шул: менә без хәзер театрга китәбез...

Биби. Кая?

Вәли. Театрга!

Биби. Нәрсә төятергә?

Вәли. Баш төятергә.

Биби. Нинди баш?!

Вәли. Атаң башы! Мин сиңа төятергә димим, театрга дим, аңладыңмы, театрга дим!

Биби. Я, аңладым инде, театрга, ул нинди җир соң?

Вәли. Анысы сиңа кирәк түгел. Без киткәч, каенатай кайтыр, ул сорар безне: «Кайда киттеләр?»— дип. Син аңа әйт: «Кодаларга киттеләр»,— дип. «Театрга киттеләр»,— дип әйтмә!

Б и б и. Сорамаса нишләрмен?

В ә л и. Тик торырсың!

Б и б и. Ярый. *(Кереп китә башлый.)*

В ә л и. Тукта әле! *(Биби туктый.)* Син, аңгыра нәрсә, рәтләп әйтә дә белмәссең әле.

Б и б и. Нишләп белмәскә!

В ә л и. Я, әйтеп кара әле, ничек дип әйтерсең икән.

Б и б и. «Вәли җизниләр театрга китмәделәр, кодаларга киттеләр»,— диярмен.

В ә л и *(ачуланып).* Иштең ишәк чумарын! Мин сиңа алай дип әйттеммени?

Б и б и. Соң ничек дидең?

В ә л и. Мин сиңа: «Театрга киттеләр»,— дип әйтмә, «Кодаларга киттеләр»,— дип әйт дидем.

Б и б и. Мин дә бит «киттеләр» димәдем.

В ә л и. Фу, җәфа икәнсең, кайдан башыма бәла алдым! Менә син яхшы тыңла: әгәр дә каенатай безне: «Кая киттеләр?» — дип сораса, «Кодаларга киттеләр»,— диген. Башка сүз әйтмә, бар, юлыңда бул!

Б и б и. Ярый. *(Кереп китә.)*

В ә л и *(үз-үзенә).* Менә бәла өстенә бәла. Мин үзем дә җүләр: миңа ни эшкә кирәк иде аңар театр дип сөйләп торырга?! Мин аңар дәрес әйтәмме? *(Ишектән Гафифә килеп чыга. Аңа карап.)* Нихәл, буласыңмы инде?

Г а ф и ф ә. Хәзер булам инде. Нәрсәгә шаулашасыз икән дип карарга гына чыккан идем.

В ә л и. Әнә шул, бар ич әле бер адәм имгәге Биби, шуңа сүз аңлата алмыйча аптырап беттем. «Без хәзер театрга барабыз»,— дигән идем, «Нәрсә төятергә?»— дип, миннән сорап ята.

Г а ф и ф ә. Ул һәрвакыт шулай. Һич аңламый ул. Мин аны беркөннәрне Гарифәләргә җибәрдем. Абыстай: «Гарифәнең алдырган кислотасы юк микән? Бик күңелләрем болганып тора. Үзебездә судысы бар барын да, ирләр өйдә вакытта кислота алдырырга онытылган, дип әйтте»,— дип сора дигән идем, барган да: «Абыстай, киез каталарын биреп торсыннар ла»,— дип сорап, миңа кислота урынына киез ката күтәреп кайткан. Гарифәдән шулкадәр оялдым, бөтенләй менә җир тишегенә керерлек булдым.

В ә л и. Я, ярый, аларын башка вакытта сөйләшербез, театрга барырга соңга калабыз, бар, тизрәк бул!

Г а ф и ф ә. Хәзер булам. Ә, ни, синнән шуны гына сорыйм дигән идем. Ул театрда кеше күп булыр микән?

В ә л и. Һу! Күп булмыймы соң! Беләсең бит, бүген мөселманча театрның беренче башлана торган көне. Шулай булгач инде, анда бөтен шәһәр халкы агылыр.

Г а ф и ф ә *(борыннарын җыерып, иркәләнгән бала кыяфәтендә).* Әй! Әем! Алай булгач, мин бармыйм ла, анда кеше күп булгач, мин оялам.

В ә л и *(үз-үзенә).* Менә сиңа кирәк булса! *(Алдына карап, башын бераз кашып.)* Ничек булыр икән соң? Юк, минемчә, әле бу көн кеше ул кадәр үк күп булмас. Кубесенең картлары җибәрмәс. Кайсыберсе кеше сөйләүдән куркып калыр.

Г а ф и ф ә *(янә әүвәлгечә).* Алай булгач, без дә бармыйк: юк, мин дә кеше сөйләүдән куркам. Әти белсә, ул да ачуланыр.

В ә л и *(бик тирән уйга калып, башын күтәреп, халыкка таба карап).* Уттан котылдым, инде суга төштем. Моннан инде ничек котылырга? *(Гафифәгә карап.)* Мин бит инде, анда барырга дип, билет та алып кайткан идем.

Г а ф и ф ә. Кайтсаң ни! Бармый калган булгач, акчаңны кире кайтарып алырсың.

В ә л и. Бер алган булгач, кире кайтармыйлар шул инде аны.

Г а ф и ф ә. Теләсәң ни эшлә, мин барырга куркам!

В ә л и. Анда ерткыч җанварлар юк, сине ашамаслар.

Г а ф и ф ә. Ашамасалар да, мин бармыйм, кирәкми.

В ә л и. Юк инде, бармый калырга ярамый, барабыз! Ул бит бик күңелле була. Үзеңнең дә көлә-көлә эчләрең катып бетәр.

Г а ф и ф ә. Андый көлкеләрне ат кәмитендә дә бик күп күргән инде. Монда да әллә нинди артык җире булмас, кирәкми, мин бармыйм.

В ә л и. Ихтыярың, теләсәң ни эшлә, барасың килмәсә, көчләмим, мин үзем генә барам.

Г а ф и ф ә. Ә, ярар менә, барыр идең бугай, кара син аны, анда ялгыз гына кызлар карарга бармакчы була. Җибәрәмме соң мин сине, Алла боерса, гомеремдә ялгыз җибәрмим!

В ә л и. Теләсәң ни эшлә, мин бармыйча калмыйм. Син бармыйсың икән, мин үзем генә тотам да барам! Хуш, сау бул, мин киттем. *(Чыга башлый.)*

Г а ф и ф ә *(тиз генә Вәлинең артыннан барып тотып).* Җә, җә, бетте. Мин юри генә әйттем. Әйдә, мин дә барам.

В ә л и *(кире кайтып)*. Ну, әйдә алайса, барсаң, тизрәк киен!

Г а ф и ф ә. Хәзер киенәм. *(Бүлмәгә таба бара башлый. Соңра янә борылып.)* Кара әле, анда өскә киенгән көенчә генә утыралармы?

В ә л и. Юк, салып утыралар.

Г а ф и ф ә. Әй! Алай булгач, бик читен икән. Кирәкми, бармыйбыз.

В ә л и. Бармыйбыз дип сөйләмә, мин барам, киттем алайса. *(Чыга башлый.)*

Г а ф и ф ә. Барам, барам!

В ә л и *(мыскыл итеп)*. «Барам, барам!» Ә үзе һаман терәлеп тора. *(Сәгатен чыгарып карап.)* Син, шулай итеп маташып, мине уеннан калдырмакчы була торгансыңдыр, ахры. Уен башланырга бары ярты гына сәгать калган.

Г а ф и ф ә. Мин хәзер булам. Өстемә күлмәк кенә киям.

В ә л и. Ну, бар, зинһар, тизрәк бул.

Г а ф и ф ә *(ишектән керә башлый да, янә борылып)*. Нинди күлмәгемне киим икән, асылынмы, җонынмы?

В ә л и *(үз-үзенә)*. Асыласың килсә, асыл инде. *(Гафифәгә.)* Зинһар, мине йөдәтмә. Эстәдең ни ки: асылмы, җонмы, сатинмы, батисмы, ситсымы — минем өчен бар да бер.

Г а ф и ф ә. Ярый алайса, мин зәңгәр асылымны киям. *(Китә башлый.)*

В ә л и. Әй, юк, тукта әле, зәңгәр асылыңны кимә, нинди булса да берәр җон күлмәгеңне ки. Сезнең андый чачаклы-чуклы карават чаршавы шикелле асыл күлмәкләрегез белән кешегә көлкегә калыр хәлем юк. Без анда бүләк багарга бармыйбыз, уен карарга барабыз.

Г а ф и ф ә. Алай булгач, нинди җон күлмәгемне киим?

В ә л и. Теләгәнеңне ки.

Г а ф и ф ә. Теге гармун итәкле кызыл җон күлмәгем ничек булыр?

В ә л и. Шәп булыр.

Г а ф и ф ә. Аның шул буе озын булган. Чәнчелеп беткән җөйче, шулкадәр әйттем: «Факиһәнеке төсле матур булсын, яхшы итеп тек»,— дип. Бозып кына бирде. Юкка гына дүрт тәңкә акча әрәм иттем. Моннан ары, Алла боерса, гомеремдә ул хатынга тектермәм.

В ә л и. Ярый, шулай итәрсең. Бар, тизрәк бул.

Г а ф и ф ә. Соң кайсын киим?

В ә л и. Башкасын.

Г а ф и ф ә. Теге, буйга буф бөргән сирый күлмәгемне киимме?

В ә л и. Ки.

Г а ф и ф ә. Ул да шул бик килешеп бетми, чабулары тар булган.

В ә л и. Алайса, бүтәнне ки.

Г а ф и ф ә. Ал җон күлмәгем ничек булыр?

В ә л и. Бик ал булыр.

Г а ф и ф ә. Кызылы?

В ә л и. Бик кызыл булыр.

Г а ф и ф ә. Яшеле?

В ә л и. Бик яшел.

Г а ф и ф ә. Соң ниндине киим?

В ә л и. Матурракны.

Г а ф и ф ә. Теге шикалат төсле, тоташ буйлы, бантиклы күлмәгемне кисәм ничек булыр?

В ә л и *(шатланган булып).* Һу! Менә, менә, әзли торгач таптың, ахры, бик һәйбәт булыр. Үзе шикалат төсле булгач, бигрәк шәп була инде ул. Чөнки шикалат бик тәмле нәрсә.

Г а ф и ф ә. Мин аны кияр идем киюен дә, аның шул җиңнәре сак җиң. Килешмәс. Үзең дә, ичмаса, бер кеше төсле чибәр күлмәклек алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә, киеп барырлык һичбер җүнле матур күлмәгем юк.

В ә л и. Соң бит аны хәзер генә тегеп булмый лабаса, уф Алла! Бар икән кылыну, ансы да ярамый, монсы да ярамый, белмим, боларга нәрсә генә ярый торгандыр, чәнчелеп бетегез шунда. Сезне көтеп, уеннан калыр хәлем юк. *(Чыгып китә башлый.)*

Г а ф и ф ә *(артыннан барып җитеп, Вәлинең җиңеннән тотып, ялынган рәвештә).* Җә инде! Ни эшләвең инде ул? Торасың да чыгып китәм дип куркыта башлыйсың. Мин сиңа бармыйм дип әйтмим ич! Әйткәч ни була соң инде? Мин синнән әллә нәрсә сорамыйм бит, бары тик нинди күлмәгемне киим дип кенә сорыйм.

В ә л и. Мин сиңа әйттем бит инде. Теләсәң нәрсә ки дип. Миңа дисәң, бөтенләй бернәрсә дә кимә.

Г а ф и ф ә. Соң шулай диген аны. Яхшылап кына сораганда, тотасың да ачулана башлыйсың. Алай булгач, ярый торган булса, мин бернәрсә дә кимим, шушы өстемдәге күлмәгем белән генә барам.

Вәли *(йөзләре яктырып)*. Һай, бәрәкалла! Бик яхшы булыр, бар. Зинһар, тизрәк. Өстеңә генә ки дә, хәзер китәбез. *(Гафифә ашыгып кереп китә.)* Уф Алла, җаным чыга язды. *(Ишеккә барып карап.)* Яңадан тагы бер-бер нәрсә тапкан булып чыга күрмәсен, ә, юк икән. *(Ишекне яба.)* Киенә икән, ахырында мең бәла белән көчкә җиңдем. Бу үзенә күрә инде кечкенә генә, бармак кадәр генә булса да бер революция булды. Ярый, ни булса да булды, минем максудым булды. *(Кулларын угалап.)* Их хозур! Хәзер театрга китәбез. *(Тагын ике кулының бармак очлары белән генә тотып, сүз арасында төрле шатланган һәм мәсхәрә кылган кыяфәтләргә кереп җырлый.)*

Бүген театр була, трат-та-та, трат-та-та!
Шатлыктан күңлем тула, трат-та-та, трат-та-та!
Картның кәефе бик китә, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Уйнаучыларны тетә, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Барам мин театрга, трат-та-та, трат-та-та!
Хатыным белән бергә, трат-та-та, трат-та-та!
Каенатай кайтып кергәч, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Безнең киткәнне күргәч, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Ачуланса да курыкмыйм, трат-та-та, трат-та-та!
Барыбер сүзен тотмыйм, трат-та-та, трат-та-та!
Кайтып кергәчтен тузар, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Бөтен кәефне бозар, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Бозса бозар кәефне, трат-та-та, трат-та-та!
Хәзергә мин кәефле, трат-та-та, трат-та-та!

Гафифә *(ишектән өстенә киенгән көенчә чыгып)*. Я, бар икән Ходаем, тагын нәрсә җүләрләнәсең инде? Әллә син дә кәмиттә паяз булмакчы буласыңмы?

Вәли. Әһә! Булдыңмы әле син, аппагым? Әйдә алайса, киттек инде, былбылым! *(Гафифәнең култыгыннан култыклап чыгып китәләр.)*

Сәхнә буш кала. Бераздан, бик кызуланып, уң як ишектән Факиһә килеп чыга.

Факиһә *(як-ягына карап)*. Монда да юк! Болар кая киткәннәр? *(Ишекне ачып кычкыра.)* Биби! Биби! *(Биби чыга.)* Син беләсеңме?..

Биби. Беләм!

Факиһә. Беләсең икән, әйт алайса: кая киттеләр җизниләр?

Биби. Алар, син сорасаң, ничек дип әйтергә икәнен миңа әйтмәделәр.

Ф а к и һ ә. Соң ничек дип кенә әйттеләр?

Б и б и. Абзый сораса, кодаларга киттеләр дип әйтерсең, диделәр.

Ф а к и һ ә. Ә башка кеше сораса?

Б и б и. Башка кеше кем сорасын? Фатих абый сораган иде дә, мин аңар әйтмәдем.

Ф а к и һ ә. Менә мин сорыйм.

Б и б и. Син башка кешемени?

Ф а к и һ ә. Я, әйт инде, кая киттеләр?

Б и б и. Әй лә, әйтмим!

Ф а к и һ ә. Театргамы?

Б и б и. Ә! Үзе дә белә икән. Аны сиңа кем әйтте?

Ф а к и һ ә. Я, бар. Алдыңа кара, эшеңне эшлә...

Б и б и керең китә.

Шул, шул, театрга киткәннәр. Мин үзем дә сизгән идем аны сизүен. Җизни ул безнеке шикелле җебегән авыз түгел. Исенә бер нәрсә төште исә, хәзер, шул минут ук эшли дә ала. Безнеке генә ул тегермән ташы шикелле, һич кузгатыр хәл юк. Тукта әле, мин дә алып бардырыйм әле. Кеше барган җирдән мин генә ни эшләп калып торырга соң? *(Бик кызуланып, сул як ишеккә кереп китә.)*

Сәхнә бераз буш тора. Бераздан, кычкырышып, Х ә б и б р а х м а н белән килеп чыгалар.

Х ә б и б р а х м а н *(кулларын селтәп.)* Бармыйм дигәч бармыйм инде! Иң әүвәл мин аның, ул театрның кайда икәнен белмим.

Ф а к и һ ә *(мыскыл итеп, бармакларын бөкләп санарга керешә).* Бу булды бер!

Х ә б и б р а х м а н. Икенчеләй, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.

Ф а к и һ ә. Ике, өч.

Х ә б и б р а х м а н. Анда кергәч тә, нинди урынга утырырга?

Ф а к и һ ә. Шуның белән була дүрт! Зинһар, ичмаса инде, эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетереп, кешене көлдермә. Кеше ишетсә: «Моның белгән нәрсәсе бар микән?» — ди башларлар. Кеше җаен тапканны, без генә табарбыз әле.

Х ә б и б р а х м а н. Кирәкми, бармыйбыз, мин куркам.

Ф а к и һ ә. Чү, чү, куркуыңнан җыгылып китә күрмә! Шулкадәр зур гәүдәң белән «куркам» дип әйтергә сиңа кешедән оят!

Хәбибрахман. Кирәкми, бармыйм!

Факиһә. Нинди бармаган да нинди нитмәгән! Кеше барган җирдән без генә калып торырга! Әйдә, әйдә, барабыз! Җизниләр әле алар үткән атнаны плашкига да чыктылар. Без анда да авызыбызны күтәреп калдык, кияве белән кызы барган булгач, эткәй дә бер сүз дә әйтә алмас. Әйдә, тотабыз да барабыз. Нәрсәгә соң без генә ул кадәр куркып торырга!

Хәбибрахман. Бармыйм дигәч бармыйм инде.

Факиһә *(юмаларга керешеп).* Җә инде дим! Барыйксана инде! Харап булган икән! Гомеремә бер мәртәбә бер җиргә барыйк дигәнмен икән инде, шуны да тыңламыйсың. Эткәйдән куркып торырга син кечкенә сабый бала түгел ич инде! *(Хәбибрахман эндәшми.)* Җә дим инде, нигә эндәшмисең? Орышса, кайткач бер орышыр да бетәр. Аның өчен сине ашый алмас бит ул. Әгәр дә бик каты дулый башласа, һич булмаганда, мин үзем аны көчләп алып бардым диярмен. Орышса, мине орышыр, сине орышмас.

Хәбибрахман *(башын кашып).* Белмим шул, ничек булыр икән? Минем үземнең дә бер күрәсем килә килүен ул театр дигән нәрсәне. Әле мин син җөдәтерсең дип әйтмәгән идем, Гайнулла җизнинең кияве Гаптерәхимнәр дә барабыз дигәннәр иде.

Факиһә. Соң алай булгач, тагын ни кирәк инде? Кеше бармый торган җирмени ул? Кеше баргач, бергә-бергә күңелле дә булыр. Әйдә, өстеңә киен дә, барабыз. Мин дә хәзер киенеп чыгам. *(Кызуланып, уң як ишеккә кереп китә.)*

Хәбибрахман *(ишеккә таба карап, үз-үзенә).* Мин әле барам дип әйтеп бетерергә дә өлгерә алмадым, ә ул киенергә дә кереп китте. Нишләргә икән инде, шулай ук барырга туры килер микәнни? Эти орышмас микән? Без чыгып киткәнче кайтып керсә генә ярар иде. Бармый калыр идек. Хатын ул этинең гадәте начар икәнне белми. Беркөнне Гали хаҗи Гаптерахманы белән чәйгә кергән өчен дә колагымны шулай итеп борып алды. *(Борып күрсәтә.)* Күзләремнән утлар күренде. Аны кешегә сөйләп йөреп булмый. «Эти колакны борды»,— дип, хатынга әйтсәң, хатын хәзер ул: «Һай, нәни бәби! Шул башың белән колагыңны бордырып торасыңмы?»— дип мыскыл итәргә тотына. *(Кесәсен капшап.)* Барабыз баруын да, әле кесәдә барырлык акча бар микән? *(Портмонетын алып, акчаларын өстәлгә бушатып саный.)* Унбиш тиен дә унбиш тиен — утыз тиен, тагын унбиш тиен, була кырык биш

тиен. Тагын биш тиен, булды илле тиен, илле тиен дә егерме тиен, була җитмеш тиен. Тагын илле тиен. *(Бармаклары белән исәпләргә керешеп.)* Йөз, йөз ун, йөз егерме, булды бер сум да егерме тиен. Бусы өч тәңкә, барысы була... *(Янәдән исәпләп.)* Ике, өч, дүрт сум да егерме тиен. *(Портмонетына сала.)* Өч тәңкәсенә билет алсак, каладыр бер сум егерме тиен. Анысы барырга-кайтырга булса; хәер, җитә икән җитүен, түлке бер дә барасы килми шул. Ичмаса, эти дә кайтмады. Әллә бармыйм микән? Ничек итеп бармый калырга? Ә, булды. Менә монда качып утырам да эти кайткач кына торып чыгам. *(Диван башына барып, посып утыра.)*

Ф а к и һ ә килеп чыга.

Ф а к и һ ә *(үз-үзенә)*. Әле һаман теге ужым бозавы киенеп чыга алмаган икән. Нишләп тора икән инде тагын? *(Сул як ишеккә кереп китә.)*

Х ә б и б р а х м а н *(башын бераз күтәреп карап, бик шатланып)*. Аллага шөкер, котылдым, күрмәде. Әти кайтыр инде.

Ф а к и һ ә *(ишектән чыга)*. Анда юк, әллә кая киткән, шундый чакларда, анасы кыйнамасын дип качкан балалар шикелле, кача торган гадәте бар иде, бер-бер җирдә качып тормыймы? *(Эзләргә тотына. Почмакта тора торган кресло артларын карый. Хәбибрахман бу вакытта, балалар шикелле, башын эчкә яшерә. Факиһә килеп күрә дә, акрын гына көлеп, диванның икенче башына барып, аягы белән идәнгә тибеп кычкыра.)* Һай, бәдбәхет! Күсе бар!

Х ә б и б р а х м а н. Һай! *(Сискәнеп сикереп тора.)*

Ф а к и һ ә *(мөстәһзиянә көлеп)*. Һа, һа, һа! Анда син бар идеңмени? Мин белмәдем. Ул кадәр куркытмаган булыр идем. Анда ни эшләп утырасың?

Х ә б и б р а х м а н *(ни әйтергә дә аптырап торып)*. Акчам төште. Шуны аладыр идем.

Ф а к и һ ә. Нинди акча?

Х ә б и б р а х м а н. Менә театрга барырга акча җитә микән дип санап торадыр идем дә, берсе төшеп китте.

Ф а к и һ ә. Шул гомердән бирле әле өстеңә киенмичә акча санап тордыңмы?

Х ә б и б р а х м а н. Мин хәзер киенәм. Башыма бүрек киям дә тунымны гына киям. *(Кереп китә.)*

Ф а к и һ ә *(кычкырып кала)*. Кара аны, анда да кәнәфи башына акчаңны төшермә, анда да күсе булыр. *(Көзге каршына

килеп, шәлләрен, калфакларын төзәтә башлап.) Ну, ир соң! Ир димәсәң, хәтере калырлык бар. *(Ишеккә карап.)* Биби! Биби!

Биби чыга.

Әткәй безне: «Кая киттеләр?»— дип сораса, «Кодаларга киттеләр»,— диген.

Биби. Ник, анда җизниләр киттеләр бит. Сез дә шунда барасызмыни?

Фәкиһә. Без театрга барабыз, әмма син шулай дип әйт.

Биби. Ярый, әйтермен. Бая җизни, син әйтә белмәссең дип, мине яңадан әйттереп карап маташа.

Фәкиһә. Әйтә белдеңме соң?

Биби. Ник белмәскә, белдем.

Фәкиһә. Я әле, тагын әйтеп кара. Безне кая киттеләр диярсең икән?

Биби. Әллә белмәс дип beләсеңме? Мин инде аны Фатих абыйдан күптән өйрәнеп куйдым. Театрга киттеләр диярмен.

Фәкиһә. Һи, аңгыра! Җебегән авыз! Мин сиңа шулай дип әйтергә куштыммыни?

Биби. Ник, үзең әйттең ич: «Җизниләр кодаларга киттеләр, сез дә шунда барасызмы?» —дигәч, «Юк, без театрга барабыз»,— дип.

Фәкиһә. Күп телеңә салынма. Яхшы тыңла. Әгәр дә әткәй сораса: «Кая киттеләр?» — дип, «Кодаларга киттеләр»,— диген.

Биби. Ярый, ярый, аңладым: «Икесе дә шунда киттеләр»,— диярмен.

Фәкиһә. Кая?

Биби. Кодаларга.

Фәкиһә. Бар, эшеңдә бул!

Биби кереп китә, Хәбибрахман тунының югары төймәсен төймәли-төймәли чыга.

Хәбибрахман. Әйдә, булдым.

Фәкиһә. Әйдә, әйдә, булсаң, тизрәк атла аягыңны. *(Ишектән чыкканда, Хәбибрахманның аркасыннан этә.)*

Хәбибрахман. Тукта! Төрткәләмә инде ул кадәр! Чыгам ич.

Чыгып китәләр. Сәхнә буш кала. Бераздан Фатих килеп керә.

Фатих *(як-ягына каранып)*. Абзый кая икән соң әле? Кеше бәйрәм итә дә итә, мин дә бераз бәйрәм итеп аласы иде.

Һәммә кеше йөри дә йөри, мин генә тик ябылып ятам, миңа ни бәйрәм юк, ни җомга юк. Бәйрәм булды исә, ишек төбе сакла. Көне буе байга килгән бер кешене өйгә алып кер дә чәй эчерт, җомга булды исә, ишегалдында утын яр да кар көрә! Юк инде, булмас болай итеп. Эһем, эһем. *(Тамак кыра.)* Әллә бөтенләй өйдә дә юкмы? *(Ишекне карана.)*

Биби. Эһем, эһем. *(Ишектән чыга.)* Нәрсәгә тамак кырып йөргән буласың?

Фатих. Абзый өйдәме?

Биби. Өйдә.

Фатих. Ни эшли?

Биби. Тире җыеп күн эшли.

Фатих. Я, шаярма әле, чынлап әйт әле, өйдәме?

Биби. Ни эшкә ул сиңа?

Фатих. Кирәк.

Биби. Әүвәле әйт ни эшкә икәнен, аннан соң әйтәм.

Фатих. Я, әйт инде, шаярма.

Биби. Нәрсә бирәсең, әйтәм.

Фатих *(шаяртып).* Әйтсәң, сине үземә хатынлыкка алырмын.

Биби. Һи, мәхәббәтсез!

Фатих. Мәхәббәтсез? Мин нишләп мәхәббәтсез булыйм? Кара бу мыекларны! *(Мыекларын борып күрсәтә.)* Кызларның калфак чугына яраклык.

Биби. Я, күп телеңә салынып торма монда, бар, чык!

Фатих. Ник, шулай ук мине яратмыйсыңмыни? Мин сине әле абзыйдан сорарга дип менгән идем, анда ялгыз гына күңелсез.

Биби *(боргаланып).* Һай, конарсыз!

Фатих. Кызларның шул булыр инде аларның, алар һәрвакыт шулай һавалы булалар. Кызлар алар, яшь чагындарак, патшага барам мин дип торалар да, ди, аннан ары, санатка дип әйтәләр, ди, ул да эләкмәгәч, актыгында, солдат булса да ярар дип әйтәләр, ди.

Биби. Я, я, бар, мыскыл итмә! Бар, чык! Абзый кайтыр, абыстай да хәзер менәр.

Фатих. Күптән син шуны әйтерләр, мин синнән баядан бирле: «Абзый өйдәме?» — дип сорыйм ич. Өйдә булмаса, хуш, сау бул. *(Чыгып китә.)*

Биби *(үз-үзенә).* Ялганлый торгандыр ла ул, мине алдар өчен генә, юри генә әйтә. *(Кереп китә.)*

Бераздан Х ә м з ә б а й кайтып керә.
Курмичә, ишек төбенә җәеп куйган паласка сөртенә.

Х ә м з ә *(кычкырып).* Гөнаһ шомлыклары! Аяк астына әллә нәрсә җәеп куйганнар. Мал кадерен белмиләр. Тыштан килеп кергәч, күзлек парлана да бер нәрсә дә күреп булмый. *(Күзлеген сөртә.)* Беркөн мәдрәсәгә кергәч тә, әчелектәге башмакларга сөртенеп, лаканга егылган идем. *(Ишек янындагы урындыкка утырып.)* Әй, кая, кайсыгыз бар анда? Аякны тартыгыз әле.

Б и б и килеп чыга.

Кая, кил, нәрсә терәлеп торасың, тарт аякны! *(Биби салдыра башлый.)* Чү, чү, чү, карап тарт! Мәсихемне бозма! Абыстаң кая? *(Биби киез итекнең берсен салдыра.)*

Б и б и. Аш өендә.

Х ә м з ә. Нишли анда?

Б и б и. Аш пешерә.

Х ә м з ә. Ник, килен кая?

Б и б и. Алар Хәбибрахман абый белән ни... ни... әй... кодаларга киттеләр.

Х ә м з ә. Ныграк тарт! Кулың чергән мәллә?

Биби, кинәттән тартып җибәреп, Хәмзәне егып төшерә.

Һай, бәдбәхет! Күзең чыккан нәрсә! Бар, кит, күземә күренмә!

Б и б и кереп китә, Хәмзә, мәшәкатьләнеп, аягын салып бетерә.

Башка кеше булса, мин аңар кирәген биргән булыр идем булуын, әллә ничек, кыз балага сугарга ул кадәр кул барып җитми. *(Тунын салып, чөйгә элеп куя.)* Бүген иртә белән чәч алучыга кергән идем, бөтенләй ишегеннән керер хәл юк. Җыен кызыл авыз кибетчеләр тулган. Байларына бөтенләй әйләнеп тә карамыйлар, чәч алучысы да һич санга сукмый: «Хаҗи, син әле башка көнне дә керерсең, син бай кеше, һәрвакытта да вакытың бар; болар бит бай кешесе, җомга көннән башка вакытта вакытлары булмый»,— дип, авызын җырып тик тора. *(Чалбар балагын җыеп бәйләп куйган тасмаларын чишә.)* Алары да шул кибетчеләр яклы. Аларга кибетчеләр яклы булмыйча ярыймы соң?! Кибетчеләр бит аларга унар, унбишәр тиенләп яудыралар. Аларга бай акчасы кызганычмыни... Биби, Биби!

Ишектән Б и б и чыга.

Б и б и. Нәрсә дисез, абзый?

Х ә м з ә. Бар әле, берәрсенә әйт әле, мәдрәсәдәге Коръән укый торган шәкертне чакырып чыксыннар. «Абзый чәч алырга чакыра»,— дисеннәр.

Б и б и. Нинди мәче алырга?

Х ә м з ә. Һай, аңгыра, җебегән нәрсә! Мин сиңа мәче алырга дидеммени? Чәч алырга дим!

Б и б и чыгып китә.

Бу кадәр аңгыра булырлар икән. Җыен аңгыра безгә җыелган. Беркөн Хәбибрахманга: «Бар, агач базарына Хисмәткә бар да аны тизрәк монда алып кайт»,— дип җибәргән идем, барган да бер зур кисмәк алып кайткан. Менә бу сакалымны шулар гына агартып бетерделәр инде. Әле ярый, хәзергә үзем исән әле. Үзем үлгәч, болар дөньяда ничек итеп көн күрерләр?

Б и б и ишектән килеп чыга да тик тора.

(Аңа карап.) Нихәл, нишләп терәлеп торасың анда?

Б и б и. Абзый, Миңнебай абзыйга әйткән идем: «Коръән укый торган шәкертне алып чык»,— дип, «Нинди шәкерт ул, мәдрәсәдәге шәкертләр алар бар да Коръән укыйлар, анда Әфтияк укучы юк»,— ди.

Х ә м з ә *(аяк тибеп)*. Һай, ахмаклар! Әрәмтамаклар! Бар, тизрәк чыгып әйт, мәчеттә Коръән укый торган шәкертне — Гайфулланы чакырып чыксын!

Б и б и. Икесен дә чакырсынмы?

Х ә м з ә. Нинди икесен дә?!

Б и б и. Коръән укучыны да, Гайфулланы да?

Х ә м з ә. Үләм инде мин сезнең белән, җәфаланып үләм! Аңгыра. Соң шул Коръән укучы шәкерт белән Гайфулла икесе дә бер ләбаса инде! Бар тизрәк! Гөнаһ шомлыгы!

Б и б и чыгып китә.

Менә инде син сөйләш алар белән. И Алла! И Алла! Ахры инде дөньяда акыллы кеше үк калмагандыр. Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, игә-чигә китерер хәл юк. Һәр көн шулай башымны катырып бетерәләр. Тукта инде, әүвәл тизрәк чәчемне алдырыйм да, аннан соң, тәһарәт алып, вирдләремне укырмын. *(Ишеккә таба борылып.)* Әй! Кая сез? Башымны чылатырга сабын, су бирегез. *(Ишектән кереп китә.)*

Бераздан, чынаяк, поднослар күтәреп, Б и б и керә.

Б и б и. Үзләре җүнләп йомыш куша белмиләр дә кешене орышалар. *(Чәй урыны әзерли, өстәлнең почмагына самавыр подносы, аның янына зәңгәр эмалированный пласкательный куя.)* Көне-төне эшлисең, эшлисең, аның өстенә тагын һәр көн орыш та талаш. Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда. Хәбибрахман абыйларның да, Гафифә апаларның да театрга киткәннәрен әйтәм. Мине генә орышмасын әле, аларны да орышсын.

Ишектән Х ә м з ә килеп чыга, башын тәмам сабын белән күперткән. Бер кулына яшел кәләпүшен, бер кулына күзлеген тоткан.

Х ә м з ә. Бар, миңа муенга салырга эскәтер китер!

Б и б и чыгып китә. Хәмзә, өстәл янына килеп, пласкательный янына кәләпүшен, аның янына күзлеген куя. Биби бер каралган кызыл эскәтер китереп бирә.

(Бибигә карап.) Кая, миңа урындык бир әле. *(Кызыл эскәтерне муенына бәйли. Биби урындыкны китереп бирә. Янә Бибигә карап.)* Бар әле, теге якта камут тартмасында минем плитувам бардыр, шуны монда китер.

Б и б и чыгып китә, Хәмзә урындыкка утыра.

Заманалар бозылды. Әле менә бүген теге урыс сымак нәрсәләр театр уйнап, динне мәсхәрә кылмакчы булып йөриләр икән. Шуны булдырмаска йөреп, бүген ясигъга бара алмый калдым. «Уйнатмагыз, рөхсәт юк!» — дип, Җамали үндергә әйткән идек, ул: «Минем эшем түгел, пристефкә үзенә әйтегез»,— диде. Пристефне өйдә туры китереп булмады, главага менгән идек, ул да алар яклы булырга кирәк: «Минем эшем түгел, сез палисәмистергә барыгыз»,— диде. Аңа барган идек, баксалга киткән. Губирнаторга да барган идек, бутишник: «Ул бу вакытта кеше кертми, иртәгә сәгать уникедә килегез»,— диде. Шулай итеп, ахрысы, бәдбәхетләрне туктатып булмады. Алла боерса, икенче вакыт уйнатмабыз әле, пристефне алдан ук күреп куярбыз.

Ишектән Б и б и килеп керә.

(Аңа карап.) Нихәл, булдымы?

Б и б и. Менә булды. *(Бритваны өстәлгә китереп куя.)* Коръән укучы шәкерт өйдә юк, ди, иптәшләре белән театрга киткән, ди.

Х ә м з ә *(ачуланып).* Ходай орган икән! Йөзләре генә кара булсын, бар, чакыр монда Фатихны!

Б и б и. Фатих абый ул син кайтканчы ук чыгып китте.

Х ә м з ә. Кая?

Б и б и. Шунда китте.

Х ә м з ә *(ачуы тагын да кабарып).* Кая шунда?

Б и б и. Шунда инде, театрга китте.

Х ә м з ә. Ә? Театрга? Кемнән сорап китте?

Б и б и. Берәүдән дә сорамады. Вәли кияүләр белән Хәбибрахманнар да киткәч, мин генә нишләп калыйм диде дә китте.

Х ә м з ә *(тәмам акаеп).* Ә? Ни дисең? Вәли кияү дә китте дисеңме?

Б и б и. Китте. *(Хәмзә урыныннан сикереп тора.)*

Х ә м з ә. Хәбибрахман да киттеме? *(Бибинең өстенә бара.)*

Б и б и *(кире чигенеп).* Китте.

Х ә м з ә *(яңадан өстенә барып).* Гафифә? Факиһә?!

Б и б и *(яңадан кире чигенеп).* Алар да киттеләр.

Хәмзә, кулларын йомарлап, иреннәрен тешләп, «эм-м-м-м!» дип, Бибинең өстенә килә башлый, Б и б и чыгып кача.

Х ә м з ә *(Биби чыгып киткәч, халыкка таба карап, кулларын сузып).* Я, әйтегез инде, зинһар, нишләтим инде боларны? *(Гайрәтләнеп.)* Юк! Боларны болай гына калдырырга ярамый, йөзе караларны! Барам да якаларыннан тотып, өстерәп алып кайтам. *(Тиз генә өстәл янына килә дә пласкательныйны алып кия. Аны ыргытып бәрә дә.)* Тфү, чурт! *(Кәләпүшен алып кия. Аны да тиз генә ала да.)* Һай, йөзе каралар икән! Акылымнан шаштырасыз инде! *(Тиз генә эскәтерне муеныннан тартып алып, башын сөртә-сөртә, киемнәргә таба бара.)* Мин сезгә бирим әле кирәгегезне! *(Өстенә кия башлый, кычкыра.)* Кая киез ката? Китерегез тизрәк, ә, менә монда икән! Йөзе караларны! *(Ашыгып-ашыгып кия.)* Бәдбәхетләрне, муены астына килгәннәрне!.. *(Чыгып китә.)*

П ә р д ә т ө ш ә.

бигайниһи — нәкъ, нәкъ үзе
эстәдең ни — теләсәң ни
бүләк багу — бүләк карау
максуд — максат
кәмиттә пияз (паяц) — клоун, шамакай
мөстәһзиянә — мыскыллап
конарсыз — ямьсез, килешсез
санат — *түрә* мәгънәсендә

мәсих — *дини йола буенча:* читек өстеннән су йөгертү (тәһарәт алганда)
вирд — дога
пласкательный — сабын күбеге ясый торган савыт

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрне рольләргә бүлеп укыгыз.
2. Комедиядә вакыйгалар ничек башланып китә?
3. Хәмзә бай гаиләсе турында сез нинди фикердә? Аларның һәрберсе турында тасвирлап сөйләгез.
4. Хәмзә бай ни өчен көлкегә кала? Аның турында язылган юлларны укыгыз.
5. Алга таба вакыйга ничек дәвам итәр дип уйлыйсыз?
6. Әсәрнең кайсы урыннары сезгә аеруча ошады? Ни өчен?

Комедия

Комедия — драма әсәренең бер төре. Ул иҗтимагый тормыштагы, кешедәге тискәре күренешләрдән көлеп языла һәм шуларны бетерергә омтыла.

Татар әдәбиятында комедия XIX йөз азакларында мәгърифәтчелек хәрәкәте йогынтысында искелектән, бозык әхлактан көлүче драма әсәре буларак барлыкка килә («Комедия Чистайда», 1895). Соңга таба Г. Камал, Г. Исхакый, С. Рәмиев, И. Богданов, Ш. Камал, К. Тинчурин һ. б. әдипләр иҗатында үстерелә.

Комедиядә мәзәкчел, сәер якларга игътибар ителә. Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», «Портфель» комедияләрендәге персонажлар үз гамәлләре белән үзләрен үзләре көлке хәлләргә куялар.

ТАТАР ТЕАТРЫ ТАРИХЫ

XIX гасырның икенче яртысында татар дөньясында җанлану башлана. Халык мәгарифе, матбугат, китап басу һәм милли театр турында кайгыртучы алдынгы карашлы фикер ияләре күтәрелеп чыга. Алар арасында күренекле мәгърифәтчеләрдән К. Насыйри, Ш. Мәрҗани һәм башкаларның хезмәтләре аеруча зур була.

1887 елда Г. Ильяси татар әдәбиятында беренче сәхнә әсәрен — «Бичара кыз» драмасын яза. Бер ел үткәч, Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» драмасы иҗат ителә. Болар бездә драматургиянең беренче карлыгачлары була.

XIX гасырның соңгы елларында драма әсәрләрен сәхнәгә куярга омтылыш көчәя. 1898 елның 24 декабрендә Татар укытучылар мәктәбе укучыларына Н. В. Гогольнең «Өйләнү» комедиясен куярга рөхсәт бирелә. Әле бу вакытта татар язучыларының әсәрләрен кую тыела.

1898 елда унтугыз яшьлек Галиәсгар «Бәхетсез егет» драмасын яза, һәм ул 1899 елда басылып та чыга. Шуннан соң бер-бер артлы башка әсәрләре дә дөнья күрә.

Төрле мәктәпләрдә укучы Казан яшьләре һәр шимбә саен әдәбият кичәләре уздыра башлыйлар. Анда төрле язучыларның әсәрләрен укыйлар, йорт спектакльләре куялар. Яшьләрнең беренче чыгышлары турында күренекле татар язучысы Ф. Әмирхан «Аң» журналында басылган мәкаләсендә: «Бу түгәрәкнең әүвәлге татарча уены Гафифә ханым Габидованың Первая гора урамындагы квартирасында булды, хәтеремдә ялгыш калмаган булса, уйналган әсәр «Кызганыч бала» иде...» — дип яза.

Татарча пьесалар аз булганлыктан, йорт спектакльләрен оештыручылар, башлыча, татар тормышына яраклаштырылган тәрҗемә әсәрләрен файдаланалар. Дөрес, мондый спектакльләр зур булмаган төркем кешеләр өчен уйнала, әмма ул әкренләп театр сөюче яшьләр һәм профессиональ труппалар үсүгә ярдәм итә.

Г. Тукай да халыкны алга, мәдәни үсешкә алып бара торган сәнгать кирәклеген яхшы аңлый. «Театр — безнең киләчәк көннәребез өчен файдалы вә өметле бер нәрсә»,— дип яза.

1906 елның 5 маенда Казанда беренче мәртәбә татарча ачык спектакль күрсәтелә. «Новый клуб» бинасында тамашачыларга Г. Камалның төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Кызганыч бала» драмасы һәм Г. Кәрамнең тәрҗемә әсәре — «Гыйшык бәласе» комедиясе тәкъдим ителә. Шул ук елның 22 декабрендә әлеге әсәрләр кабат куела. Бу көн тарихка татар театры туган көн буларак кереп кала. Ул татар укытучылары әзерли торган мәктәпнең ярлы укучылары файдасына куела.

Татар профессиональ театры оешу Ильяс Кудашев-Ашказарский исеме белән бәйле. Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул 1904 елда Оренбургка укытучы булып килә. 1907 елның 3 апрелендә аның җитәкчелегендәге труппа Ф. Халидинең «Морат Сәлимов» һәм А. Чеховның «Кыз сорау» әсәрләрен сәхнәгә чыгара. Болар Оренбургта татар телендә беренче спектакльләр була. Труппада хатын-кыз артистлар булмау сәбәпле, хатын-кыз рольләрен ирләргә уйнарга туры килә.

Аннары Ашказарский оештырган труппа Казанда, Мәкәрҗәдә (Түбән Новгородта) төрле спектакльләр куя. Труппага Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Фатыйма Шаһимәрдәнова кушыла. Хатын-кызлар өстәлгәч, хәл яхшыра, иҗат мөмкинлекләре арта.

Бу якларда куелган спектакльләрне караучылар арасында Җаектан (Уральскидан) килгән Миңлебай Хәйруллин, ягъни Габдулла Кариев та була. Спектакльләрдән соң ул, артистлар торган номерга барып, артист булырга теләге барлыгын белдерә. Шул көннән башлап, Г. Кариев бөтен гомерен татар театрына багышлый.

Труппа Мәкәрҗәдән Мәскәүгә килә. Анда очраган кыенлыкларга түзә алмыйча, И. Кудашев-Ашказарский труппаны ташлап китә. Труппа җитәкчесе булып Габдулла Кариев кала. Ул труппа 1907 елда «Мөсафир артистлар җәмгыяте» исеме белән Мәскәүдән Җаекка килә. Беренче татар профессиональ театр труппасының Җаектагы тормышы театр тарихында зур әһәмияткә ия. Бераз вакыттан соң әлеге труппа «Сәйяр» исеме белән йөри башлый.

Татар театрының репертуарын тудыруда Г. Камал зур эш башкара. Ул бер-бер артлы «Беренче театр», «Бүләк өчен»,

«Уйнаш», «Банкрот» кебек тирән эчтәлекле әсәрләрен иҗат итә.

Бераздан алдынгы карашлы зыялылар арасында Г. Камал белән Г. Кариев татар драматургиясе һәм театрының нигез ташын салучылар булып танылалар.

«Сәйяр» труппасы Идел буе шәһәрләрендә һәм Төркестанда була. Гомумән, ул татарлар яшәгән һәр төбәктә булырга өлгерә. Ләкин инде төрле төбәкләрдә яшәгән татар халкының үскәннән-үсә барган мәдәни ихтыяҗын «Сәйяр» труппасы гына канәгатьләндерә алмый башлый.

1912 елда, «Сәйяр» труппасы белән беррәттән, Уфада «Нур» труппасы оеша. Аны беренче татар хатын-кыз артисты Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская җитәкли.

1917 елда Сембердә (Ульяновскида) Бари Тарханов җитәкчелегендә «Ирек» исемле театр оеша.

Шулай итеп, татар театры туа һәм формалаша. 1920 елдан соң «Сәйяр» труппасы Мәскәүдән Казанга кайта һәм, «Аң» труппасы белән берләшеп, «Беренче татар үрнәк драма труппасы»н барлыкка китерә.

Октябрь борылышыннан соң татар театры тагын да киңрәк мәйданга чыга. 1922 елда театрның үзенә махсус бина салына. Артистларның белемен күтәрүгә, аларны укытуга җитди игътибар бирелә башлый. Казанда татар театр техникумы ачыла. Театрның үсеш юлын билгеләүдә баш режиссер Кәрим Тинчурин күп көч куя.

Сораулар

1. Бездә театр сәнгатенең шактый соң барлыкка килү сәбәпләре нәрсәдә дип уйлыйсыз?
2. Татар телендә спектакльләр кую өчен нинди әзерлек эшләре алып барыла?
3. Татар телендә беренче спектакль кайчан һәм кайда уйнала?
4. Беренче театр труппалары турында нәрсәләр беләгез?
5. Театр тарихында зур урын алган нинди артистларны беләсез?

Татар театрлары турында сөйләшү өчен сораулар һәм бирем

1. Татарстанда нинди театрлар бар?
2. Казандагы театрлар турында нәрсәләр беләсез?
3. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына кайчан нигез салынган?

4. Анда нинди спектакльләр караганыгыз бар?
5. Артистлардан кемнәрне беләсез?
6. Кайсы артистларның уйнавын аеруча яратасыз?
7. Иң югары дәүләт бүләкләренә лаек булган нинди артистларны беләсез?
8. Сезнеңчә, театрда режиссер хезмәте нидән гыйбарәт? Режиссерлардан кемнәрне беләсез?
9. Артистлар турында нинди китаплар укыганыгыз бар?
10. Яраткан артистыгыз турында сөйләгез.
11. «Театр — минем тормышым» дигән хезмәтне кем язган? Анда нәрсә турында сүз бара?

С. Гыйззәтуллина-Волжская

(1892—1974)

Милли театрыбызның оешуында һәм үсешендә беренче татар хатын-кыз артисты Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның өлеше аеруча зур. Ул — мөселман хатын-кызлары арасыннан театр сәхнәсенә чыккан батыр йөрәкле кызларның берсе.

Сәхипҗамал Гыйззәтуллина 1892 елда Казан шәһәрендә туа. Ул тормышта бик күп авырлыклар күрә. Кешеләрдә төрле кара эшләр башкара, әмма гел уку турында хыяллана. Бию мәктәбенә, рус театрына йөри.

1907 елда Казанга Ильяс Кудашев-Ашказарский җитәкләгән театр труппасы килә. Сәхипҗамал ул спектакльләрне бик яратып карый. Аннары үзендә дә сәхнәдә уйнап карау теләге туа. 14 яшьлек Сәхипҗамал сәхнәгә аяк баса. Беренче уйнаган роле «Кызганыч бала» драмасында Шәфика образы була.

Сәхипҗамал 1912 елда Уфада, «Сәйяр» артистлары Хәерниса Сәмитова, Зөләйха Богданова, Шакир Шамильский белән берлектә, икенче татар театр труппасы «Нур»ны оештыра. Аларга бер төркем яшьләр кушыла. Сәхипҗамал үзенең Идел буенда үсүе белән горурлана. Тәхәллүсен (псевдонимын) Волжская дип алуы шуны күрсәтә.

«Нур» труппасы, Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт», Г. Камалның «Бәхетсез егет», «Уйнаш», А. Островскийның «Яшенле яңгыр», Ф. Әмирханның «Тигезсезләр», Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер» кебек әсәрләрен сәхнәгә куя. Сәхипҗамал аларда зур осталык белән уйный. Бөек Тукай, Сәхипҗамалны кояш белән тиңләп, аңа мәдхия җырлый:

Күр, ничек, иртә кояш чыкса, җиһанга нур тула,
Һәр күңелләр нурланадыр чыкса Гыйззәтуллина.
Бу икәүгә Тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:
Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.

Замандашлары Сәхипҗамал Гыйззәтуллинаның бик акыллы, оста җитәкче булуын әйтәләр. Репетицияләрне ул үзе алып бара, артистларны өйрәтә һәм талантлы уены белән яшьләргә үрнәк күрсәтә. «Мин көчле рольләрне уйнарга ярата идем»,— ди Сәхипҗамал Волжская. Чыннан да, фаҗигале рольләрдә ул кабатланмас осталык күрсәтә. А. Островскийның «Яшенле яңгыр» драмасында Катерина образын Сәхипҗамал тамашачыны тетрәндерерлек итеп уйный.

Театр өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга 1926 елда Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә.

Татар сәхнәсендә зур хезмәт куйган әлеге сәхнә остасына багышлап, драматург Нәкый Исәнбәт «Гөлҗамал» драмасын яза. Бу әсәр 1963 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куела.

Сәхипҗамал Гыйззәтуллина 1974 елда Казан шәһәрендә вафат була.

Сораулар һәм бирем

1. Сәхипҗамал Гыйззәтуллина нинди хезмәтләре белән танылa?
2. Ул сәхнәгә кайчан аяк баса?
3. Сәхипҗамал нинди рольләрне яратып башкара?
4. Сәхипҗамалның сәхнә осталыгын Г. Тукай ничек бәяли?
5. Татар хатын-кыз артистларыннан сез тагын кемнәрне беләсез? Алар уйнаган рольләр турында сөйләшү оештырыгыз.

Габдулла Кариев
(1886—1920)

Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйруллин) — беренче татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе.

Ул 1886 елның 8 маенда Татарстанның хәзерге Норлат районы Күлбай-Мораса авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында ала. Миңлебай шулкадәр зирәк бала була, 12 яшендә Коръәнне яттан өйрәнә. Мондый зирәк баланың «мужик» исеме белән Миңлебай дип йөртелүе авыл мулласы Зарифка ошамый. Ул үзенең яраткан шәкертенә Габдулла (Алла колы) исеме бирә. Һәм Миңлебай халык арасында «Габдулла карый» дип йөртелә башлый.

1904 елда ул Җаек (Уральск) шәһәренә укырга китә. Монда Миңлебай, җырчы, сүз остасы, мәзәкче буларак, төрле әдәби кичәләрдә катнаша. Шушы чорда Габдулланың фамилиясе, *карый* сүзенә нигезләнеп, Кариев дип йөртелә башлый.

Җаекта Габдулла Кариев татар халык шагыйре Габдулла Тукай һәм күренекле җырчы, җәмәгать эшлеклесе Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин) белән очраша, һәм алар якын дуслар, фикердәшләр булып китәләр.

Габдулла Кариев тормышын тулысы белән татар халкының мәдәниятен, сәнгатен үстерүгә багышлый һәм милли театрның нигез ташын салучыларның берсе булып танула.

Артист Г. Камал әсәрләрендәге образларны аеруча яратып башкара. Ул әдәби әсәрдә сурәтләнгәннәр белән генә чикләнеп калмый, персонаж прототипларының психологиясен, гореф-гадәтләрен, үз-үзләрен тотышларын һәм сөйләшү үзенчәлекләрен өйрәнә. Шулар ярдәмендә җыелма образлар иҗат итә.

Мәсәлән, шундый образлардан Хәмзә («Беренче театр»), Әхмәтҗан («Бүләк өчен»), Сираҗетдин («Банкрот»), Шкафчы Әхмәтҗан («Безнең шәһәрнең серләре») һ. б. күрсәтергә мөмкин. Г. Кариев, репертуарны киңәйтү нияте белән, төрле язучыларга мөрәҗәгать итә. Ф. Әмирханның «Яшьләр» драмасын, азәрбайҗан язучысы П. Вәхиревнең «Мөсибәте Фәхретдин» әсәрен сәхнәгә куя. Үзе дә «Артист» исемле комедия яза.

1917—1918 елларда Г. Кариев җитәкләгән «Сәйяр» труппасы М. Горькийның «Мещаннар», А. Чеховның «Чия бакчасы», М. Фәйзинең «Галиябану» һәм башка әсәрләрен сәхнәләштерә.

Г. Кариев — халыкның талантлы, алдынгы фикерле улы. Ул театрны бөтен йөрәге белән ярата. Язучы Г. Ибраһимов аның турында: «Кариев өчен тормыш, дөнья, бәхет, сәгадәт юк, тик театр бар, шул театрны үстерү өчен, шуның белән көю бар иде»,— дип яза.

«Без шундый театр төзербез, аның исеме алтын хәрефләр белән язылыр»,— дип, бик еш кабатлый торган була Г. Кариев. Чынлап та, исемен алтын хәрефләр белән язарлык театр төзеп калдырды ул.

Кызганычка каршы, Г. Кариевка татар театрына бәйле барлык ниятләрен дә тормышка ашырырга насыйп булмый. Ул 1920 елның 28 гыйнварында Казанда тиф авыруыннан үлә. Аны күмү җеназасына Казанның меңнәрчә халкы катнаша. Иң якын дусларыннан К. Тинчурин кабер өстендә соңгы сүзен әйтә, ә Фәтхи Бурнаш дусты истәлегенә язылган шигырен укый.

карый — Коръәнне яттан белүче
сәгадәт — бәхет

КАРИ КАБЕРЕНӘ

Фәтхи Бурнаш

Әйләнә тормыш һаман тукталмыйча,
Тормый тарих бер сәгать тик язмыйча;
Шул сәхифәләр аңарда, кайсы ки
Калды бер тамчы кара кан таммыйча...

Әй туган, актар аңардан бер читен,
Күр укып шул мәңге онытылмас, авыр,
Кайгылы матәм көненең билгесен.
Сәҗдәгә кил, әй нәфасәт дөньясы!
Мондадыр татар театр кыйбласы;
Монда «Сәйяр»ның сөекле, мәгънәле
Әткәсе — даһи Кари Габдулласы.

матәм — кеше үлү яки иҗтимагый фаҗига сәбәпле кичерелә торган зур кайгы, хәсрәт
сәҗдә — кем дә булса берәү алдында хөрмәтләп баш ию
нәфасәт — нәфислек, матурлык

Сораулар һәм бирем

1. Габдулла Кариев кем ул? Аның сәнгатебездә тоткан урыны турында сөйләгез.
2. Ул нинди гаиләдә туа һәм тәрбияләнә?
3. Аның исеме, фамилиясе ни өчен үзгәрә?
4. Г. Кариев Җаекта кемнәр белән очраша?
5. Г. Камал белән Г. Кариев ни өчен дуслар булалар? Моны нинди мисаллар белән дәлилли аласыз?
6. Сезнеңчә, Г. Кариев нинди рольләрне яратып башкарган? Ни өчен?
7. Ф. Бурнаш Г. Кариевка нинди бәя бирә?

Гаяз Исхакый
(1878—1954)

Гаяз Исхакый 1878 елның 22 февралендә Казан губернасының Чистай өязе Яуширмә авылында Гыйлаҗетдин мулла гаиләсендә туа.

Әдәбиятка Гаяз шактый иртә килә. «Тәгаллемдә сәгадәт» исемле беренче әсәрен 17 яшендә яза. 1902 елда «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле хыялый-публицистик повестен тәгәлли. 1905 елгы революциягә кадәр үк инде ул дистәгә якын хикәя һәм повесть, ике пьеса, «Теләнче кызы» романының беренче кисәген тәмамлый һәм күбесен дөньяга чыгара.

1904 елда Казанга килеп, революцион хәрәкәткә кушылып китә. «Таң йолдызы» исемле газета чыгара башлый.

Г. Исхакый, хөкүмәткә каршы җинаятьтә гаепләнеп, 1906 елда кулга алына һәм Чистай төрмәсенә ябыла. Шунда «Зиндан» дигән автобиографик повестен яза. Аннары Архангел губернасына сөргенгә җибәрелә. Шушы авыр шартларда ул «Солдат» повестен, «Теләнче кызы» романының икенче кисәген, берничә пьеса яза. Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңае белән игълан ителгән амнистия нигезендә 1913 елда азат ителә.

Гаяз Исхакый 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли мәҗлестә катнаша. Ләкин ул милли мәсьәләнең хәл ителү рәвешен, гомумән, Совет властен кабул итә алмый һәм ватаныннан китәргә мәҗбүр була.

1928—1939 елларда, Берлинда яшәп, «Яңа милли юл» исемле журнал чыгара. 1935 елда Кытайда чыга башлаган

«Милли байрак» газетасы шулай ук Г. Исхакый тырышлыгы белән дөньяга чыга.

Сталинизм чоры башлану белән, Исхакый шәхес культын, аның үзе урнаштырган режимны матбугат аша рәхимсез утка тота.

Г. Исхакый — шулай ук татар театрының тууында, үсешендә зур урын тоткан шәхес. 1906 елның апрелендә аның «Өч хатын берлән тормыш», 1907 елда «Ике гашыйк» пьесасы сәхнәдә уйнала. «Алдым-бирдем» драмасы, татар сәхнә әсәрләреннән беренче буларак, 1914 елда Петербургта рус телендә басылып чыга. 1908—1912 елларда «Тартышу», «Мөгаллим», «Кыямәт», «Җәмгыять», «Зөләйха» кебек пьесалары дөнья күрә. Аның әсәрләрендә һәр милләт, үз телен, мәдəниятен, гореф-гадәтләрен саклап, үзенә үзе хуҗа булып, мөстәкыйль яшәргә тиеш дигән фикер ята.

Талантлы прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакыйның әсәрләре озак еллар буе бикләп тотылса һәм эшчәнлеге бозып аңлатылса да, дөреслек җиңде, Г. Исхакый акланды. Аның бай тарихлы иҗаты укучыларга кире кайтты.

1991 елда Татарстан Язучылар берлеге Гаяз Исхакый исемендәге премия булдырды.

Әдип 1954 елда 76 яшендә вафат була һәм Төркиянең Истанбул шәһәрендә күмелә.

тәгаллемдә сәгадәт — укуда бәхет
инкыйраз — бетү, юкка чыгу

«Сөннәтче бабай» повесте турында

Повесть 1911 елда Төркиянең Истанбул шәһәрендә язылган. Беренче мәртәбә 1912 елда сигез томлык әсәрләр җыентыгының икенче томында «Шәкерт абый» хикәясе белән берлектә басылып чыккан. Автор үзе әсәрне хикәя дип атый.

«Сөннәтче бабай» — чын мәгънәсендә милли һәм халыкчан әсәр. Ул татар авылының үзенә генә хас гореф-гадәтләрен, хис һәм тойгыларын, яшәү рәвешен белеп язылган. Сөннәтче бабай — татар авылы өчен генә характерлы образ.

Сөннәтче бабайның җаныннан артык күргән пәкесе — аның шәҗәрәсе. Автор шуңа зур мәгънә биргән.

СӨННӘТЧЕ БАБАЙ

(өзек)

Авылның картлары, ир уртасылары, яшьләре — һәммәсе дә үзләрен белә башлаганнан бирле аны Сөннәтче бабай дип таныйлар, Сөннәтче бабай дип йөриләр иде. Угыллары, кызлары җиткән карчыклар да яңа төшкән яшь килен чакларда аны Сөннәтче бабай итеп таныганнар, алар да, бу көнге яшь киленнәр кеби, урак өстендә кызу-кызу урак урганда да, көз көннәрендә, төшмәенчә башны әйләндерә торган гөбе язганда да, бәйрәм алдында ашыга-ашыга өй юганда да, егълаган угылларын туктатыр өчен, «Сөннәтче бабай килә!» дип куркыталар иде.

Аның яшен белгән кеше юк иде. Яше күпме, дип уйлаган кеше дә юк иде. Һәм дә, әллә ничек, бөтен авыл халкы шул Сөннәтче бабай берлән яше арасында мөнәсәбәт барлыгын уйлый алмый иде. «Сөннәтче бабай сиксән яшендә, туксан яшендә» дигән сүз аларның колагына ят килер кеби.

Сөннәтче бабай — сөннәтче бабай иде. Ул, авылның өч сайлануында да староста булып торып, хаҗга барып кайткан Ашаяк Шәрәфи бабайның да сөннәтче бабае булган кеби, авыл хәзрәтенең, тимер юллар, пароходлар берлән үтеп барып, Казан шәһәрендә укый торган мәхдүменең дә сөннәтче бабасы иде. Авылның бу ел төшкән яшь киленнәренә дә ялгыз калып уйлап ятканда яисә, эштән соң каенанасыннан яшеренеп, иске чүпрәкләрдән искеләр әзерләгәндә дә, угылы булуыны уйлап бетерүе берлән, Сөннәтче бабай хәтеренә төшә, угылы булуы берлән сөннәт ясаучы Сөннәтче бабайдан һич аерылмый иде.

Кечкенә кызлар, курчак уйнаганда, курчакларның туе иттереп, кодалар, кодагыйлар чакырып маташканда, иске чүпрәкләрдән ямьсез генә иттереп, һәрвакыт бер курчакны «Сөннәтче бабай» атыйлар, «сөннәт туйлары ясап», аның исеменнән әллә никадәр сүзләр сөйләнәләр, ир балаларны егълаттыралар иде. Бөтен авыл, «сөннәт» дигән сүзне ишеткәндә, шул картаеп, искереп беткән Сөннәтче бабайны хәтеренә китерә, сөннәт туе хакында сүз ишетсә, аның кайда булганын да уйламаенча, мотлакан: «Сөннәтче бабай булган»,— дип утыртып куя иде.

Аның яше югалган кеби, исеме дә югалган иде. Көлдергечрәк картлар, эшләр бетеп кырдан кергәч, җомга көннәрне кояш җылысында җыелышып, сөйләшеп ятканда: «Сөннәтче бабайның метрикәсен кәҗә ашаган икән. Аның исеме югалгач, Газраил фәрештә аны онытканн икән дә, шуның өчен авылда ике зур холерада ул исән калган икән»,— диләр иде. Газраилнең онытуы дөрес булса булыр, ләкин Сөннәтче бабайның исеме югалган икән хәбәре ялган иде. Аның исеме бар иде... Исеме генә түгел, аның бөтен нәселен язган, аның бабаларының бабаларын язган «сөннәтче» шәҗәрәсе бар иде...

Авылның кырыеннан сан буенча икенче исәпләнә торган Сөннәтче бабайның йорты да, дөресен әйткәндә, өе дә, үзе кеби, бөтен авылның өйләреннән аерым иде. Ул, авылның сатучысы Әхмәдинең кызылга буяган өенә охшамаган кеби, авылның иң фәкыйрьләреннән исәпләнә торган капка каравылчысы Садрыйныкына да охшамаган иде. Ул — Сөннәтче бабайның өе иде. Бөтен җире, бөтен төсе Сөннәтче бабайга охшаган иде. Авыл тарихын белми торган вакытта такта берлән ябылган түбәсе, вакыт үтә-үтә каралып бетеп, анда-монда кәкрәеп торулары берлән Сөннәтче бабайның битенә охшый иде. Түбәсенең кырыйларына солы, бодай, алабута катышыннан үскән үләннәр дә, берсе анда таба, берсе монда таба карап, Сөннәтче бабайның рәтләп таралмаган сакалын хәтергә китерә иде. Өйнең сулга да, уңга да таба кәкрәйгән диварлары Сөннәтче бабайның төрле тарафка таба бөкрәйгән аркасын искә төшерә иде. Аның пыяласыннан күп рамлы тәрәзәләре үзенең яшәргән пыялалары берлән бабайның һәрвакыт яшьле күзләренә бик охшый иде. Өйнең берәм-берәм агачларын таратудан саклап тора торган, өстән сылаган күк балчык та Сөннәтче бабайның да шул картайган тәнен бер кеше иттереп җыеп йөртү вазифасын кыйла торган киемнәренә төсе-нисе берлән дә бик охшаган иде. Монда һәрнәрсә Сөннәтче бабайга охшаган. Сөннәтче бабай үзе дә һәрнәрсәгә охшаган иде. Кем белсен, бәлки Сөннәтче бабай, чыннан да, шул өйнең балчыгы берлән бер балчыктан яратылгандыр. «Мал иясенә охшамаса, харам була»,— диләр. Аның дөреслеген белмим, ләкин мал иясенә охшамаса, мал берлән иясе арасында аерма бетә. Менә монда да кай җирдә Сөннәтче бабайның үзе башлануы, кай җирдә аның әйберенең чиге булуы әллә кайчан хәтер-

лəрдəн себерелгəн иде; əллə кайчан бу чик баганалары авып беткəн иде. Дөресе генə, Сөннəтче бабай шул Сөннəтче бабай үзе генə түгел иде: ул шул киемнəре берлəн, шул буе берлəн, шул үткен чалгы пəкесе берлəн, шул əллə ничə кат кəгазьгə төргəн череге берлəн бергə Сөннəтче бабай иде. Бөтен авыл халкы шуны шулай уйлый, бөтен авыл халкы шуның шулай икəнлегенə ышана иде. Шуның өчен авылдагы ике зур утта да Сөннəтче бабайның йорты янмый калуын да Сөннəтче бабайдан аерым бер эш иттереп сөйлəнмилəр. Сөннəтче бабайның өе янмый калды, аны ут оныттты, фəлəн дə төгəн димилəр иде. «Газраил дəфтəреннəн югалды»га шуларның һəммəсен бергə кертəлəр иде.

Сөннəтче бабайның «сөннəтче бабай»лыгы моның берлəн генə тəмам булмый иде. Аның тагын берничə кисəге, кəбестə теле белəн сөйлəсəң, тагын берничə яфрагы бар иде. Аның өенең алдында юкə агачлар берлəн бастырып тоттырган кечкенə бакчасы да, бер караганда, һавалангандай, күкрəеген чыгарып, кукраеп тора кеби, бер караганда, картайганнан арып, билен тота алмыйча бөкрəеп торган кеби күренгəн милəш агачы да бар иде. Көзгə таба аның кып-кызыл милəш сабаклары кызыл ахак кебек салынып, сөялеп, яшь кызларның муенын, кулын, колагын бизəкли торган төймəлəр, алкалар кебек, Сөннəтче бабайның өен бизи иде. Аның искелектəн туеп беткəн йөзенə көлəчлек биреп, битенə кызыл йөгертə иде. Сөннəтче бабай, шул үзе берлəн картайган милəш агачының телен белгəн кебек, һəр көн иртə берлəн чыгып, агачка таба карый, һəр көнне аның берлəн сөйлəшергə тотына:

— Нихəл, суык булмадымы? Кырау төшмəдеме? Чəчəклəреңне өшетмəдеңме? — дип сорый иде.

Милəш тə, шуны гына көткəн кебек, офицеры алдында басып тора торган солдатның офицерының сəламенə каршы кычкырып: «Исəнлегеңне телим!» дигəн кебек, əллə кайдан килгəн җил белəн шаулап җавап бирə. Сөннəтче бабай да, аның сыгылып-сыгылып килə торган ботакларын, чəчəклəрен тотып карап, туңмаганына, өшемəгəненə ышанып, агачның тамырларын карарга, «Җире корымадымы? Су кирəкмиме?» — дип, туфракны кулы белəн изəргə тотына иде. Ул күп вакыт, су сибəргəме, юкмы, дип уйлап тора-тора да: «Майдан ботка бозылмас», — дип, чилəкне күтəреп, артындагы инешкə төшə дə, анда үзе ясаган басмадан су алып менеп, милəшнең

төбенә сибә иде. Аннан соң салыныбрак төшкән ботакларны бер-бер җеп берлән бәйләп куя, иелгәнрәкләрен агачлар берлән терәтә, миләш вакытында урамга якынракларын бакчага таба борып куя иде. Ләкин монысы кирәкмәс бер эш кенә, Сөннәтче бабайның картлыгыннан килгән артык бер саклану гына иде. Аның миләшләре ерактан караганда малайларны никадәр кызыктырса да, урамның теге ягыннан үтеп барганда ук, үзенең әчеле-төчеле тәме берлән никадәр аларның авызыннан су агызса да, килеп басып алырга берсенең дә көче җитми иде. Түбән оч, Югары оч бакчаларында кыярга рәхәт йөзе күрсәтми торган Гата малае Касыйм да, юлаучы Камалиның күршеләрендә йомыркаларына көн күрсәтми торган ирдәүкә кызы Мәрфуга да шул миләшләргә таба тугъры килә алмый иде. «Сөннәтче бабай» дигән сүз аларның күңеленә әллә нинди бер курку төшерә, аларның күз алдына шул Сөннәтче бабайны, карт Сөннәтче бабайны пәкесе, череге берлән китереп бастыра: аның авызыннан Сөннәтче бабай һич сөйләми торган бер тавышта «Кисеп алырмын!» дигән сүзне ишеттерә иде. Шул «кисеп алырмын»нан Касыйм куркып кача, никадәр ирдәүкә булса да, киселәчәк артык бернәрсәсе дә булмаган Мәрфуга да якын килми иде.

Миләштән башка да бабайның байлыгы юк түгел иде: аның өй артында канау белән әйләндереп алган, суга кадәр сузылган йорты бар иде. Читтән караганда никадәр кечкенә төсле күренсә дә, бу йортның бер почмагы уҗым кыры, бер почмагы сабан ашлыгы кыры, суга якын җире печәнлеккә бүленгәнгә, башка — урта җире шалкан, кыяр, кәбестә, чөгендер, борчак, бәрәңге түтәлләрен дә эченә ала иде. Шул ферма, урам ягыннан кечкенә генә җилкапка берлән авылга чыккан кеби, пөхтә генә такта ишек, тар гына, матур гына басма белән суга таба да сузылган иде. Шул су ягындагы ишектән Сөннәтче бабай түтәлләрен, ашлыгын сугара, урам ягындагы капкадан шул ашлыкларны чит дөньяга чыгара, географиячә әйтсәк, чит мәмләкәтләргә җибәрә иде. Җәйнең һәр вакытында аның шул бакчасы һәрвакыт ямь-яшел тора, илдәге корылык аның арышын саргайтмый, җәйге эсселек аның карабодаен көйдерми иде. Һәр елны кояшка карап тора торган каш җирендә аның бодае уңа; уйсу җиргә чәчкән солысы, кара туткыллы булып, гөрләп үсә; карабодае, миләш кебек, сабаклары белән тулы була; арышы, сары ука кебек, башын күтәрә алмаенча сузылып ята. Аның кыяры, шалканы, кишере

хакында сөйләмә дә инде — алар бөтен авылның авызыннан суын агыза, бөтен авылны кызыктыра иде.

Сөннәтче бабайның кош-корты да юк түгел иде. Ләкин болары, ни өчендер, Сөннәтче бабайныкы дип сөйләнмәенчә, аның карчыгы Гөлйөзем әбинең исеме берлән йөри иде. Мәсәлән, аның бүрекле тавыгы, кызыл әтәче «Гөлйөзем әби тавыгы», «Гөлйөзем әби әтәче» дип йөртелә; аның зур җилемле, һавалы мөгезле, көтүнең иң артыннан килә торган кәҗәсе дә «Гөлйөзем әби кәҗәсе» дип сөйләнә иде.

Бу тавыклар, әтәчләр, кәҗәләр — һәммәсе дә Сөннәтче бабай кебек карт булсалар да, Сөннәтче бабай күрше картларыннан аерылган кеби, алар да күрше тавыкларыннан, әтәчләреннән аерылсалар да, һәммәсе дә холыклары, табигатьләре берлән Сөннәтче бабайга бик охшасалар да, күрше-колан, ни өчендер, бу мәсьәләдә Сөннәтче бабайның хакын кабул итмәенчә, Гөлйөзем әбигә нисбәт биргәннәр иде. Кем белсен, өй, бакча, миләш Сөннәтче бабайга никадәр охшаса, тавык, әтәч, кәҗә, бәлки, Гөлйөзем әбигә шулкадәр охшагандыр. Шулай дигәч тә, сез Гөлйөзем әби берлән Сөннәтче бабай арасында аерма бар иде: берсе кара туткыллы, берсе сарырак; берсе каты табигатьле, берсе йомшак; берсе матур, берсе ямьсез иде, дип, бер хата фикер чыгармагыз. Боларның төсләрендә, йөзләрендә, кыланышларында, табигатьләрендә дә һич аерма юк иде. Дөресе генә, болар хәзер ике кеше түгел, икедән кушып ясалган бер кеше иде. Боларның берсен күреп, икенчесен күрмәгән кеше, иттифакый күрмәгәнен икенче авылда яисә кара урманның ялтыраган аланында җиләк җыйганда күрсә, мотлакан, моның кем икәнлеген таныячак иде.

сөннәт — ирлек әгъзасының чисталыгын саклау өчен ясала торган операция
мәхдүм — мулла улы
кодалар, кодагыйлар — өйләнешүче егет белән кызның әти-әниләре, туганлык атамасы
мотлакан — һичшиксез
көлдергечрәк — шаянрак
харам — хәрәм, үз көче белән табылмаган
хәтерләрдән себерелгән — онытылган
ахак — кыйммәтле таш, бизәү, бизәнү әйбере
ирдәүкә — үзен ирләрчә тотарга яратучы, ир табигатьле хатын-кыз
иттифакый — очраклы рәвештә

Сораулар һәм бирем

1. Сөннәтче бабай кем ул?
2. Сөннәтче бабайны авыл халкы ни өчен хөрмәтли?
3. Автор аның портретын ничек сурәтли?
4. Сөннәтче бабай бакчасында нәрсәләр үстерә?
5. Сөннәтче бабайның хуҗалыгында нәрсәләр бар?
6. Гөлйөзем әби турында нәрсәләр белдегез?
7. Сөннәтче бабай һәм аның карчыгының яшәү рәвеше турында сөйләгез.
8. Мөселманча, дини йолалар буенча яшәүнең кайсы яклары сездә хөрмәт уятты?
9. Сезнеңчә, авторның сурәтләү алымында үзенчәлек бармы?

Гомәр Бәширов

(1901—1999)

Татарстан Республикасының халык язучысы Гомәр Бәширов 1901 елның 7 гыйнварында Татарстанның хәзерге Арча районы Яңасала авылында крестьян гаиләсендә туа. Җиде яшендә аны остабикәгә, аннары авыл мәдрәсәсенә бирәләр, шунда ул укырга-язарга өйрәнә.

Әтисе яңалыкны аңлаучы кеше була. Кичләрен аларның гаиләсе китаплар укырга бик ярата. Ә кечкенә Гомәр аларны бик бирелеп тыңлый. «Таһир-Зөһрә» китабын, «Сак-Сок» бәетен, «Кыйссаи Йосыф» поэмасын, «Әбүгалисина» китабын, Каюм Насыйри әсәрләрен кат-кат укыйлар алар.

Яңасала тирәсенең матур табигате бала күңелендә тирән эз калдыра. Тормышта шулай бит: авыл малае, кыш булса, чана шуа, кар тавында ауный; җәй җитте исә, су коена, болынга китә, урманнарны гизә. «Урманга чикләвеккә, җиләккә йөрүләр, чабаталык юкә алып кайтулар, ат ашатырга куна барулар, инде тагын да зуррак булгач, печән чабарга, көлтәгә йөрүләр — һәммәсе дә мине табигатькә тагын да якынайтты»,— дип яза Гомәр Бәширов үзенең бер истәлегендә.

1919 елда Гомәр Урта Бирәзә мәктәбендә укытучы булып эшли. Ләкин аңа озак укытырга туры килми, 1920 елда гражданнар сугышына китә. Аннан кайткач, махсус курсларда белем алганнан соң, 1924 елдан башлап, халык судьясы булып эшли.

1932 елда Гомәр Бәширов «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында эшли башлый. Шул еллардан башлап, әдәбият, иҗат дөньясына чума.

1937 елда аның гражданнар сугышы күренешләрен тасвирлаган «Сиваш» повесте дөнья күрә.

«Намус» романы Гомәр Бәшировны дөнья мәйданына алып чыга. Аның бу гүзәл әсәре дистәләгән телләргә тәрҗемә ителә һәм укучылар тарафыннан яратып укыла. Роман өчен Гомәр агага 1951 елда СССР Дәүләт премиясе бирелә. Композитор Нәҗип Җиһанов шушы әсәргә «Намус» операсын (Әхмәт Исхак либреттосы) иҗат итә.

Язучы «Туган ягым — яшел бишек» автобиографик повестенда татар авылының күркәм традицияләрен, гореф-гадәтләрен тулы бер күренеш итеп күз алдына китереп бастыра. Шул рухта тәрбияләнгән һәм көн иткән саф әхлаклы ата-бабаларыбызның истә калырдай образларын иҗат итә.

«Җидегән чишмә» — бүгенге көн, безнең замандашларыбыз турындагы роман. Әсәрдә урман-кырларны, җир-суны, кош-корт һәм җәнлекләрне, гомумән, бөтен табигатьне саклау мәсьәләсе куелган. Яшь егет Гайнан образы — Г. Бәшировның язучы буларак зур уңышы.

Г. Бәширов татар халык иҗатын җыюга, аны тикшерүгә дә күп көч куя. Шушы нигездә аның «Туксан тугыз мәзәк», «Мең дә бер мәзәк» җыентыклары басылып чыга.

Күпкырлы иҗади хезмәтләре өчен Гомәр Бәшировка Татарстан Республикасының халык язучысы исеме бирелә.

Гомәр Бәширов 1999 елның 7 маенда Казан шәһәрендә вафат була.

ТУГАН ЯГЫМ — ЯШЕЛ БИШЕК

(өзекләр)

Эзләр

(кереш)

Ел саен диярлек мин авылыма кайтып киләм. Кайтам да үземнең бала чак, үсмер чак эзеннән, бергә уйнап үскән иптәшләрем, туганнарым, яраткан кешеләрем эзеннән йөрим. Тау астындагы чишмә суларын татып карыйм, урманнарга сугылам, «диңгез күзе»н карап узам. Элек пар нарат үсеп утырган тау битенә җиткәч, һәр кайтуда, туктап: «Бикәби, син кайда?» — дип дәшәсем килә. Янәшәдәге иске зират каеннары моңа каршы, җилгә башларын игәләп: «Күптән монда инде Бикәбиең, күптән»,— дип шаулап куялар.

Малай чакта куна йөргән аланнарга, үзем печән чапкан болыннарга, иген кырларына барып чыгам. Шунда минем яшьлек дусларым, кадерле кешеләрем аерата юксындыра башлыйлар. Күңелне тынычландыру өчен генә булса да: «И-һи-и! Хәкимҗан, Нимҗан, Әхәт абый, Әхмәт?!» — дип аваз салам. «Күптән үк юк шул инде алар,— дип җавап бирә авылдашларым.— Әхәт абыең акларга каршы сугышта Сарапул тирәсендә вафат. Хәкимҗан туганың ком чүлендә барган сугышларда һәлак булды. Нимҗан дисәң, ул бичара Бөек Ватан сугышында үлеп калды».

Беләм мин боларны, беләм. Ләкин минем, барыннан да бигрәк, замандашларымның игелекле эзләрен күрәсем килә.

Әмма як-ягыма җентекләбрәк, игътибар беләнрәк карасам, ни күрәм, бар икән бит аларның эзләре, игелекле гамәлләр дәвам итә икән!

Бу әсәр нигездә бер авыл тормышыннан алып язылган. Яңасала зур авыл түгел. Шулай да ул Казан ханлыгы заманыннан бирле үк яшәп килгән бик борынгы авылларның берсе булганлыктан, җирендә-суында, тормыш-көнкүрешендә, риваятьләрендә халкыбыз тарихыннан хәтсез күп кадерле эзләр саклый алган. Ул эзләрдә халкыбызның асыл сыйфатлары чагыла. Алар, тапкыр һәм зирәк сүз булып, гүзәллеккә сокланучы үткен күз нуры яисә игелекле гореф-гадәтләр, тырышлык һәм эшчәнлек рәвешендә әледән-әле балкып чыгалар.

Бу кыйммәтле рухи хәзинәбезнең бер өлешен генә булса да әсәремә теркәп калуым белән мин үземне бәхетле саныйм.

Җирән кашка сагышы

VI

Ул вакытта инде апай да, эшләрен бетереп, шул ук лампа яктысына килә. Ул киергесенең бер башын сәкегә куйган да, икенче башын тез өсләренә җайлап, алсу төсле ситсыга чынаяк өстеме, нәрсәме чигәргә тотына. Көндез тәрәзә янында минем аның шул алсу чүпрәккә карандаш белән тырышып-тырышып чәчәк бизәкләре төшергәнен карап торганым бар. Менә хәзер апай, тамбур энәләрен шул карандаш эзләреннән йөртеп, дебеттән яшел, зәңгәр, шәмәхә төсле чәчәкләр чигә.

Апайның кечкенә генә коңгырт бармаклары, бик килешле булып, тегеләй дә болай уйнап кына тора, энәләре бер батырган саен шарт та шорт килә, бармагындагы көмеш балдагы очкын чәчрәткәндәй җелт-җелт итә. Күзләре озын кара керфекләре астында бөтенләй йомылып беткән шикелле. Чебен эзләре шикелле генә шул нечкә юлларны ничек күрә икән соң ул? Дебетенең күзәнәкләре ничек төшеп калмый да ничек чәчәген бозып җибәрми икән?

Ул яз көне, башын да күтәрмичә, айлар буе киндерләр, чүпләмле сөлгеләр суга, кыш буе намазлыклар, өстәл япкычлары, кульяулыклар чигә, һәммәбезгә дә пирчәткәләр, оекбашлар бәйләп бирә. Мин аны, азрак усал булса да, кызганып куям. Иптәш кызлары күрше авылларга утырмага барганда, аулак өйләргә йөргәндә, менә шулай бер ирек ачмыйча, бөкресен чыгарып, көне-төне чигү чигеп утыру бик туйдыргандыр шикелле тоела башлый. Кайчакларда әни дә әйтә:

— Утырма көн-төн чүпләнеп! Күзеңне бетерерсең, сукыр калырсың! — ди.

Апай киергесенә иелгән килеш бераз шулай чигеп утыра да, бөкрәеп килгән аркасын турайтып, әнигә карап ала.

— Үзең сандык малын мулрак хәстәрләргә кушасың ич. Өс-башка да кирәк.

— Хәере белән игеннәр уңып китсә...

— Ул ике имананың игене ни дә, үзе ни! Сатарга түгел, ашарга да такы-токы гына.

— Шулай инде. Өй тулы иманасыз да җирсез.

— Шул шул менә. Барысына да әти ничек җиткерсен? Үзең беләсең ич...

Әни белә инде ул, белә. Икмәк салган саен әти аның колагына тукып кына тора:

— Эре иләктән илә онны, күп тотма!

Безнең өйдә әти белән абыйның гына җире бар. Хатын кешеләргә җир бирмиләр, ә мин, җир өләшкәч туганлыктан, бөтенләй җирсез калганмын. Җирсез-иманасыз. Әти миңа карап авыр сулап алгалый. Бәлки, иманасыз булганга кызгануыдыр? Иманасыз...

Кайчагында шулай, җир азлыгы турында сүз чыккач, әти дә әйтеп куйгалый:

— Их! Бер генә атна элегрәк, җир өләшкәнче тусаң ни була соң?— ди.

Иманасыз-җирсез... Әти шул турыда сүз кузгатканда, миңа бик уңайсыз булып китә. Кеше алдында күлмәксез-ыштансыз утырган шикелле...

Тик бүген апайның болай беркемгә дә сүз катмыйча, күтәрелеп карамыйча, мыштым гына утыруы бүтәннән булган икән...

Әни орчыгын берничә мәртәбә зырылдатып алуга, апай аңа әллә ничек кенә итеп ым какты. Әни бераз тынып торганнан соң, үзеннән-үзе теленә килгәндәй, ничектер шома гына итеп, күрше Ибраһим абзыйларның Кибәхуҗага кунакка китүләре турында әйтеп куйды. Кияүдәге кызлары бала тапкан икән дә, шуңа бәби ашы илтә киткәннәр.

Әни күз кырые белән генә әтигә карап алды, бармак очына төкергәләп, орчыгын тагын берәр зырылдатты:

— Баягынак Мәликә аулак өй сакларга Өммикамалны да чакыра кергән иде дә. Иптәш булыр дип...

Әти кеше, кайвакытларны әнинең нигә шулай якын юлны ерак итеп, боргалап-сыргалап маташуын сизеп алуга, сүзен тыңлап та бетермәстән, кырт кисә торган иде:

— Йөрисе түгел! — дип.

Бу юлы алай итмәде, апайга ничектер ягымлырак карап куйды. Әтинең күңелен нәрсә йомшартты икән? Апайның «Кертмәсәң дә җылап үлмәм әле!» дигән сыман, сер бирмичә, үзенә күрә бер тәкәбберләнеп утыруымы? Әллә бик кыен чакларда апайдан үзенең дә акча алып торуы исенә төштеме? Ни әйтсәң дә, начар түгел бит. Аңа салынып ятмый. Үз өс-башын үзе карый.

Ни булса да булгандыр, әмма бу юлы әтинең тавышы кырыс ишетелмәде:

— Ярар, керсен...— диде.

Апай кеше әле шуннан соң да, ашыкмаган кыяфәт белән, беравык тын утырды.

Бераздан аны әни үзе кыстый башлады:

— Бар инде, кер! Кара аны, узынасы түгел! Иртә белән яктырганны көтеп ятма, эш күп,— диде.

Абый әллә кайчан ук әзер иде инде. Ул катыргы тышлы бер-ике калын китапны янына куйган да кыяр-кыймас кына әтигә карап алгалый. Әти нәрсә укырга куша бит. Бәлки, ул аңа мәдрәсәдә укыган сабагын тыңлатыр, я, бәлкем, мулла абзыйлар шикелле, кычкырып Коръән укырга кушар. Каян беләсең...

Бу юлы әти аңа китапның зәңгәр тышлысын укырга кушты.

Әни лампаның филтәсен күтәрә төште, яулыгын артка чөеп бәйләде дә колак тирәсендәге чәч бөртекләрен арткарак сыпырып җибәрде.

Нәрсә укуларын аңламасам да, мондый кичәләр миңа бик күңелле тоела иде. Тышта суык, өй бүрәнәләре шарт та шорт килә. Ә без менә шулай, бәйрәм алды кичәсе итеп, җылы өйдә, якты лампа тирәсендә рәхәтләнеп китап укып утырабыз.

Әнинең мичкә төшкән күләгәсен карап утыру китап тыңлауга караганда да кызыграк. Әни үзе мич стенасында әллә нинди озын муенлы сәер хайванга атланган бик дәү кеше булып күренә. Аның тәкә башы хәтле орчыгы, үзеннән-үзе айкалып-чайкалып, әле ишеккә таба атыла, әле сәкегә таба. Утыра торгач, ул шәүләләр бер дә чын түгелдер, әллә нинди күз буяудыр, я әкияттәге кебек тылсымдыр дип уйлый башлыйсың.

Утыра торгач, абыйның көйләп-көйләп китап укуы яңадан колакка килеп керә. Ул аз гына атына биреп укый да укый. Өй эченә моңарчы ишетелмәгән әллә нинди сәп-сәер ят сүзләр сибелә башлый. Дәгел дип куя, булгай ди, сүз арасында һөд-һөд, дөл-дөл, аргамак, фиргавен дип җибәрә, тагын әллә ниләр тезеп китә.

Ул сүзләр бер колакка кереп алдылармы, һич онытыласылары килмичә, авыз эчендә әвәләнә башлыйлар: һөд-һөд, дөл-дөл...

Мин шунда, иртәгә урамга чыккач, ачуны китергән малайларның авызына китап сүзләре белән чәпәргә дип уйлап куйдым.

Озын сыйраклы икән, дөл-дөл кушасың. Ябык икән, аны-сын аргамак дип үртисең. Аңгырарак булса, һөд-һөд булып китә...

Кайбер кызык хәлләр, төштәге шикелле, өзек-төтек кенә минем колакка да чалына башлады. Бик тә матур бер егет булган, тагын каяндыр шунда бик чибәр бер патша хатыны килеп керә. Аннары шулар тирәсендә бакчалар, чәчәкләр, тәмле җимешләр, асыл кошлар да бик күп. Әтисе теге матур малаен бик яраткан. Тик абыйлары, нишләптер, аны коега ташлап киткәннәр.

Орчыгын алдына куеп бирелеп тыңлый торгач, кайвакытларны әнинең озынча ак бите, кояш төшкәндәй, ярырып

китә, тагын да матурлана, күзләре, елмаеп, бик күңелле карый башлыйлар. Әмма гел алай гына булмый. Картның матур улы үлү кайгысыннан сукыр калган урынына җиткәч, әни уһылдап куя:

— И мескен. Ник тилмертәләр инде? Шундый кансыз, миһербансыз бәндәләр дә булыр икән дөньяда.

Әтинең бите һаман шул коеп куйган төсле, әмма ара-тирә я бармаклары селкенгәләп куя, я йодрыгы йомарланып килә.

Бу миңа бик тә гаҗәп тоела. Әниләр тыңлый торган шул сүзләр кәгазьдә ничек чыгалар икән?

Абыйның иңбашы аркылы, борынымны сузып, шул сүзләрнең чыккан урыннарын эзләргә тотындым. Җентекләбрәк карый башлагач, китап бите өстендә кәкре-бөкре, сукыр черки хәтле генә кара бөҗәкләр күренде. Озаграк карап торсаң, алар селкенгән шикелле тоела башлый.

Шушы кәмитне әле бер күзне, әле икенчесен каплап карап кына торганда, абый «шалт» иттереп маңгайга чиертте. Алай да булмагач, әти күлмәк итәгеннән тартты.

— Тик кенә утырасыңмы син, юкмы? Кыбырсык, юеш борын!

Минем үпкәлисем килә башлады: карап торган өчен генә нигә шулкадәр ачуланырга?

Әни янына килеп бераз гына утырган идем, башым, яман да авыраеп, үзеннән-үзе аска таба тарта, күзләрем түзә алмаслык булып йомыла башлады. Син аны тырышып-тырышып ачасың, ә ул яңадан йомыла.

Шунда мин аркамда әнинең җылы кулын сизәм, колак төбендә аның күгәрчен гөрләгәндәй йомшак сүзен ишетәм:

— Карасана, күрмиләр дә торам икән ләбаса! Килеп үк җиткәннәр икән бит! Бүген бик күп эшләде шул бу дәү кеше, таулар шуды, кичләр утырды...

Озак та үтми, мин башым-аягым белән татлы йокыга чумам.

киерге — чигү чиккәндә, тукыманы тарттырып куя торган җайланма

дебет — йоннан яки мамыктан эрләп эшләнгән чигү җебе

утырма — хатын-кызларның туганнарында кул эше белән озаклап кунак булу йоласы

тәкәббер — үзен зурга санаучан, масаючан

кыбырсык — тиктормас, хәрәкәтчән, тынгысыз

Сораулар һәм биремнәр

1. Кичен гаилә нәрсә белән шөгыльләнә?
2. Кызлар кичләрен нинди һөнәргә өйрәнәләр һәм аны ничек башкаралар? Шул урыннарны табып укыгыз.
3. Сез нинди кул эшләре беләсез? Аларга кайда өйрәнергә мөмкин?
4. Гаиләнең китаплар яратуы һәм аларны бергәләп укулары турындагы урыннарны табыгыз һәм бу турыда фикер алышыгыз.
5. Сез кичләрен гаиләгез белән китаплар укыйсызмы? Ял көннәрен ничек үткәрәсез?
6. Бүлекне тулысынча укыгыз. Үз сүзләрегез белән эчтәлеген сөйләгез.
7. Сезгә бу бүлектә аеруча кайсы юллар тәэсир итте?

Орлык чыккан көн

III

Әти алдан чәчеп бара, мин аның артыннан тырмалап барам. Әлеге шул бер күзе «өшегән» кара бия, башын чайкыйчайкый, бәкәленнән туфрак ерып атлый. Ат артыннан, җир өстенә буйдан-буйга дымсу эз калдырып, тимер тешле агач тырма сөйрәлә. Берничә адым гына арткарак калып, кортлар чүпли-чүпли, бик зур эш кыргандай түшләрен киереп, каргалар бара.

Ындыр артыннан Ышна елгасына кадәр бөтен тирә-як сабанчылар белән тулган. Кайсы сукалап маташа, кайсы тырмалый. Төрле якта сабаннар челтери, ара-тирә атлар пошкырып куя. Әле уңда, әле сулда бары сабан ашлыгы чәчкәндә генә әйтелә торган үзенә бертөрле ат куу, ачулану, орышу, сызгыру тавышлары ишетелеп тора:

— Әйдә, малкай! На, на, на!

— Карасана, һәйт!

— Фит, фит, наян, атлабрак!

Сука белән җир ертучы агайлар тагын да үзенчәрәк. Бераз гына читкә тайпылдымы, илереп атларына җикеренәләр:

— Ягалай! Үләт себергере!

— Буразна!

Урман бөтенләй үк яшелләнеп җитмәгән әле. Аңа күгелҗем төс кенә кергән. Тик каен күбрәк булган урыннар гына бераз яшелләнеп килә. Тавышлар тынып торган арада ул яктан, тонык кына булып, күкеләр кычкырганы ишетелә. Олы кешеләр әйтә, күке тавышы ишетелә башлагач, аю да арт са-

нын суга манчып ала, ди. Шуннан соң безгә дә су коена башларга ярый икән.

Шушы йөз төрле авазның һәммәсе өстенә сабанның сайрар кошлары — тургайлар тавышы яңгырый.

Безнең җир башына, пар ат җиккән сабан сөйрәтеп, Әхмәт килеп туктады. Ул быел яздан көзгә кадәр Бикбулатларга хезмәтче булып ялланган. Ашау байдан. Сеңлесе белән энесенә көз кәне берәр күлмәк, үзенә бишмәтлек алып бирәсе икән.

Әхмәт кулын кашы өстенә куеп күккә текәлде. Аның сипкелле бите бик сөйкемле булып балкый, күзләре кысылып килгән. Әйтерсең дөньяда аннан да бәхетлерәк беркем дә юк. Шулай тыңлады да:

— Әллә бөтен басудагы тургай сезнең җирегез өстенә җыелган инде!— диде.

— Юк, һәр агайның баш түбәсендә икешәр, өчәр тургай эленеп тора бугай,— дидем.

— Их, ничек кенә әйтеп бирәләр, ә! Менә шулар шикелле моңлы итеп җырлый белсәң, ә?

— Син болай да матур җырлыйсың. Ишеткән бер хатын-кыз җыламыйча түзә алмый.

— Ә боларны менә җылатмасалар да тыңлавы рәхәт. Белсәң иде, нәрсә дип сайрый икән алар?

Тургайлар сайрый-сайрый күтәрелеп төклетура хәтле генә булып калдылар. Ә шулай да тавышлары баш очында гына яңгырый иде. Миңа алар кояшның яктылыгына да, көннең матурлыгына да куаналар, менә бу кешеләрнең шулай тырышып-тырышып җир сөреп ятулары да аларның күңеленә хуш килә шикелле иде.

Безгә бик тә рәхәт иде. Тик шунда Бикбулат үзе килеп җитте.

— Нәрсә син терәлеп каттың? — дип кычкырды.— Эшеңне кем эшләр?!

Җир башыннан әти тавышы ишетелде:

— Нәрсә карыйсың? Кая кереп барасың?

Әлеге шул юньсез кара бия! Кырын-кырын атлый торгач чыга да китә эздән. Дилбегәне болгый-болгый кычкырып җибәрдем:

— На, на! Менә салырмын берне сырт буйлап!

Бераздан әти икенче җиргә китеп барды.

— Төшкә тикле өч катлап бетерергә кирәк! — диде.

Хәзер инде җир башыннан узучылар минем үземә дәшәләр иде:

— Алла куәт бирсен!

Минем дә үземне хәзер олы сымаграк тотасым килә. Тырма артыннан атлый биреп:

— Исән бул! — дип узам.

Зуррак малайлар минем алдыма олыларча киндер алъяпкыч ябып чыгуыма, ат артыннан дилбегә каккалап, сызгыргалап баруыма елмаебрак узалар. Усалраклары, синең атыңа таба кулы белән күрсәтеп, нидер булган кыяфәт белән, бик каты кычкырырга тотына:

— Әнә, әнә! Төште, төшеп калды!

Шуңа алданып атыңны туктатсаң, җитмәсә тагын:

— Кая? Нәрсә? — дип тә сорасаң, бөтен басуга көлкегә каласың. Алар шундук авызларын ерып көлә башлыйлар:

— Ябалак, байгыш! Күрмисеңмени? Кара бияңнең тизәге! — дип кычкыралар.

Әти теге җирдән әйләнеп кайткач, як-ягына карана-карана, җирнең түбән башына төшеп китте. Акрын гына ул бара, аның артыннан тырмалап мин барам. Әллә күрә минем ничек тырышуымны, әллә юк.

Безнекенә башташ икенче бер өлешкә төшеп җиткәч, әти, башын чайкап, телен чартлатырга тотынды:

— Әй-әй-әй! Кем эше булды бу?

Бу җирне күптән түгел генә Минзай дигән малай тырмалап киткән иде. Ул үзе бот буе гына булса да, кулыннан килмәгәне юк. Бик шәп гармун уйный, кубыз чиертеп кызлар биетә. Балавызлаган җепне, карындыкка тартып, ике йорт арасына суза да иптәш малайлары белән шуннан гына сөйләшә.

Менә шул Минзай тырмалаган җиргә күзе төшкәч, әтинең чырае яктырып китте:

— Кара син малай актыгын, ә! — диде, сакал очын сыйпаштыргалап, тигез генә булып тезелеп киткән тырма эзләренә соклангандай, җир башында арлы-бирле йөргәли башлады.— Һе! Эшен китергән бу! Мамык иткән бу җирне! Кара син, ә! Ник бер генә кисәкле балчык калсын! Менә уңа инде монда иген!.. Тәгаен!..

Минзай җире, бер башыннан икенче башына кадәр бик тигез итеп пөхтәләп, тарак белән тарап чыкканга охшый иде.

Мин тиз генә җиремә борылып карадым. Шунда миңа бик тә күңелсез булып китте. Җир өстендә ат башы тикле кан-

тарлар турсаеп тора. Тырма бөтенләй сәлам бирмичә чи калдырып узган урыннар да бар. Менә тамаша! Ничек күренмичә калганнар диген син!

Әти Минзайны һаман мактый да мактый:

— Менә бу эш тек эш инде! Тырма эзләрен буйдан-буйга ничек кенә тездергән! Бур җебе белән сызганмыни! Җир башын кара син, җир башын! Машина белән чикмән якасы каеган шикелле! Шундый да матур иттергән!

Үзем тырмалаган җир торган саен сөйкемсезрәк булып күренә башлады. Минем хәзер үз җиремә карыйсым да килми иде. Шушы кара шайтан аркасында гына инде бу! Ул йөрде өшегән күзен акайтып, тегендә дә монда боргаланып!

Әмма никадәр генә атка сылтамасам да, күңелнең бер төше үземнең дә гаеп барлыгын сиздереп тора. Көнчелек тә кытыклый башлады. Сүзем сүз! Барыбер Минзайныкы шикелле итеп тырмалап куям! Барыбер!

Төштән соң шулай тырмаладым да.

Дөрес, әти минем эшне алай ук үтереп мактамады. Аның җир башыннан мыек астыннан гына елмаеп узуы да миңа бик җиткән иде.

Ул көнне кич йокларга яткач, күз алдында, алай да болай да килеп, гел тырмалаган җир әйләнеп торды. Тырма үрлекырлы сикерә, тырма артыннан очсыз-кырыйсыз вак балчык тасмасы, тип-тигез тырма эзләре агылып бара иде.

төклетура — бал җыючы корт
карындык — эре хайваннар карынының стеналарын тәшкил иткән юка, нык яры (элек көнкүрештә пыяла урынына да кулланылган)
тәгаен — һичшиксез

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу бүлектә язгы чәчү эшләре ничек тасвирлана?
2. Хәзерге чорда басуда язгы кыр эшләре ничек башкарыла?
3. Автор табигать күренешен ничек тасвирлаган, шул урыннарны табып укыгыз. Тургай сайраулары аның күңелендә нинди хисләр уята?
4. Малайның хезмәте әтисе тарафыннан ничек бәяләнә? Сез әти-әниләрегезгә нинди эшләрдә булышасыз? Шул турыда сөйләгез.
5. *Тирәләп кату, күз төшү, кытыклый башлау* фразеологик әйтелмәләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.

Кунак кызлар килде утырмага

I

Югары очка да килгән кунак кыз, Түбән очка да. Әти Казанга солы белән киткәч, безгә дә килеп төште. Ник дисәң, гадәте шулай. Көз ахырында аның үзенең бик сөйкемле бер вакыты бар.

Атналар буе вак иләктән иләгәндәй, тәтәсләп торып үзәккә үткән, кибәннәрнең янтауларына яшел ямаулыклар үстергән бетмәс-төкәнмәс көзге яңгырлар туктаган. Әниләр елмаюы кебек ягымлы җылы көннәре, көмеш тоҗымнары, салкын төннәре белән әбиләр чуагы да узып киткән. Төнлә белән өй түбәләренә, капка башларына — бөтен җиргә җем-җем иткән ап-ак кырау төшә, агачларга бәс бәйләнә. Көзге пычракта бозылып калган урамнар, юллар, бөтен казылмалары, кисенте һәм чокырлары белән, бер төн эчендә шакыраеп каталар. Урамнан узган арбаның дөбердәве бөтен авылны яңгырата.

Бөтен дөнья боеккан. Келәт кәрнизендә, кызыл тәпиләрен корсак асларына яшереп, күгәрченнәр бөрешеп утыра. Агач ботакларындагы кабарынкы йонлы мескен чыпчыклар төшенке тавыш белән:

— Суык-суык, суык-суык! — дип зарланалар. Менә тагын берәр атна уза. Кояш көн саен соңгарак калып чыга башлый. Югарырак күтәрелергә иренеп, түбәннән генә әйләнә дә тизрәк төшеп китәргә ашыга. Көннәр тагын да суытарак төшеп, инешләргә боз ката. Картлар, бишмәт өстеннән билләрен буып, бияләй кияләр дә, озын таякларга таянып, уҗым басуына чыгып керәләр.

— Ат аягы батарлык түгел инде, катырган,— диләр.— Уҗымның тамыры өзелмәс. Әйдә, ку мал-туарны уҗымга!

Хәзер инде «арба да түгел, чана да түгел». Арба җиксәң — тәгәрәме, чана җиксәң —шумый.

Менә беркөнне иртән торып чыгасың — бөтен дөнья ап-ак! Йомшак кар өстенә каз-үрдәк тармаклы-җәпләкәле беренче эзләрен салып киткән. Кич-иртә урамнан шыгырт та шыгырт аяк тавышлары ишетелә башлый.

Менә кайчан кузгала төрле өмәләр: каз өмәсе, сүс өмәсе, тула өмәсе. Шул вакытка турылап, күрше авыллардан кунак кызлары килә. Байга да килә, ярлыга да. Кунактан кунакка гына, бәлештән коймакка гына йөреп, өч-дүрт көннән үк китеп баручылар да, быелгы шикелле корылык булган елларны

якты чырай, сөтле чәйгә дә риза булып, унар, унбишәр көн утыручылар да булгалый. Кунак кыз дигәндә, бары бергә, югы уртак, ничек туры килсә дә гаеп ителми.

Безнең кунак кызыбыз яшь кенә иде әле. Чәче Яңасала кызларыныкы кебек кара я коңгырт түгел, бодай саламы төсле. Бите дә түгәрәк түгел, ак та, озынчарак та, күзләре дә күк төсле. Сөрмә тартмый, иннек-кершән сөртми. Иреннәре болай да бөрлегән төсле, бит урталары, баг алмасыдай, үзеннән-үзе алсуланып тора. Исле сабын белән бик матурлап битен юып, чаршау артында чәчен тарап үрә дә, мәрҗәннәрен асып, көмеш балдакларын киеп, чулпыларын чылтыратып, тик йөри бөтен өйне балкытып.

Беренче көнне иртән торып, коймагын ашап, чәен эчкәннән соң, тәрәзә янынарак утырды да кунак кыз, урамнан узучы яшь-җилбәзәккә күз аткалап, пирчәткә бәйли башлады. Шунда өйдәгеләр белән тәмле генә әңгәмә куерып китте. Ике якның да нәсел-нәсәбе, әби-бабайлардан башлап яңа туган сабыйларгача, бөтенесе телгә алынды.

Инде иген-тарулар дип әйтеп әйткәндә, анысының куанырлыгы юк икән. Арыш белән борай, бик үк дан булмасалар да, ачка үтерерлек үк түгел. Әмма бодай белән солы бер дә куандырмаган. Борчак орлыгын гына кайтарган, карабодайны инде анысын әйтәсе дә юк: чәчәктә утырганда ук эссе куырган. Шулай итеп шул, бәйрәм-сәйрәм, кунак-төшем булганда, Кибәхуҗа кешесенә газиз кунакларны карабодай коймаклары белән сыйлаулар быелга насыйп булмыйрак тора икән әле.

Бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтеп, гел айкалып кына тора дөньялары. Әле игеннәр уңмый, әле терлек үләте килеп баса. Каян алырга, нишләргә? Ярты авыл тегүгә чыгып китә. Кайсыберсе, очын очка ялгый алмыйча, башын ташка орырдай булып йөри-йөри дә, тәрәзәләренә такта кадаклап, бөтенләй әллә кай җәһәннәмгә олага. Я күмергә анда, я Себергә. Тик әйтәләр бит: «Кая гына барсаң да, кара сакалың үзеңнән калмый»,— дип... Менә шулай инде Кибәхуҗа хәлләре, тәтәй генәм...

Таллыклар арасыннан чылтырап аккан инеш кебек, ашыкмыйча гына, тирбәлә-тирбәлә генә аккан бу озын-озак әңгәмә берзаман тына. Кунак кызыбыз, көн урталары җиткәндә, битен яңадан юып, киенеп-ясанырга тотына. Озак та үтми, ул я апай, я әни белән, зур урамнан буй-сын күрсәтеп,

туган-тумачаларга чәйгә барып кайта. Я берәрсе аны каз өмәсенә дәшә.

Ул килгәннән бирле абый яңа күлмәк, яңа чалбарларын киеп, гел елмаеп кына йөри. Карап торганым бар: чыгар-чыкмас мыек сыман нәрсәсен ничә тапкыр көзге алдында сыпыргалап карады.

Кунак кыз килгәннән бирле ишек белән капкага да тынгылык юк, һич кенә ябылып тормыйлар. Кичкә керсәң, тәрәзә тирәсендә гел кыштыр-мыштыр егетләр кайнаша.

Инде кояш бераз гына кичкә авыштымы, китә киенү-ясану, кичке су китерүләргә хәстәрләнү. Бер кереп, бер чыгып, тыз да быз күрше кызлары кайнаша башлый. Кузгала пышылдаулар, чыркылдаулар, китә дәртләнеп нидер көтү, нидер өмет итү, киңәш-табыш итү.

— Кайсы күлмәгеңне киясең? Башыңа нәрсә ябасың?

— Карале, кызлар! Ак катамны кисәм килешерме әллә карасын киимме?

Шул арада, бер-берсенең колакларына үрелеп, нидер пышылдап алалар, нәрсәгәдер ымлап, берсенә-берсе күз кысалар. Ул да булмый, кесәләреннән ат күзе тикле генә көзгеләрен чыгарып, матурлана башлыйлар...

III

Казларны, юып, келәт киштәсенә менгереп элгәннән соң, кызлар эре көмеш чәчәкләр төшерелгән яшел, зәңгәр чиләкләр белән чишмәгә су алырга төшәләр. Китә шуннан су ташу! Дүрт тапкыр да, биш тә, әллә ничә дә төшәләр. Өйдәге савытлар тулгач, мунча казанына, ул да тулгач, ат улакларына, сыер тагаракларына ташыйлар. Анда да салыр урын калмагач, күршедәге карчык-корыны, өлкәнрәк яшьтәге җиңгиләрне су белән күмәләр.

Күпер төбендәге егетләр һаман уйный да җырлый. Яннарыннан узган саен кызларга берәр шаян сүз әйтеп я булмаса күз кысып, каш сикертеп калалар.

Менә кызлар, бер кулларын көянтәләренә салган килеш биеп кенә атлап, берсе артыннан берсе таудан менеп киләләр. Күкрәкләрен киерә төшкәннәр, нечкә билләрен боргалап, сыгылдыргалап, иңбашларын сизелер-сизелмәс кенә биетеп менәләр. Шундый җиңел итеп, шундый өздереп атлыйлар, аяклары җиргә дә тими. Әйтерсең иңбашларында буш чиләк-

ләр генә; шундый оетып юргалыйлар, чиләкләрендәге суның ичмасам тамчысы гына да селкенми.

Кызлар, яулык читләрен тешләп, битләрен аз гына каплаган сыман булып узсалар да, аларның да күзләре уйнаклый. Сәхипҗамал шикелле чаяраклары үзләре дә каш сикертеп алалар. Кайсы кашын сикертә, ничек сикертә — аның да рәте бар икән. Уң кашын сикертсә, «Ярый, уйлап карыйсы булыр» дию икән. Инде иреннәрен кысып, сул кашын сикерттеме, анысыннан рәхим-шәфкать көтмә, ди. «Саруымны кайнатып, аяк арасында буталып йөрисе юк!» дигәне була икән.

Тауны менеп җитәрәк, туктыйлар. Күпер төбендәге егетләргә карый-карый, бер-берсенә шыпырт сүзләр әйтәләр дә чырык-чырык көлешеп алалар.

— Тагын төшәбезме әллә? — ди кунак кыз.

Әллә ничәсе берьюлы:

— Төшәбез, төшәбез! — диешәләр.

Мин тавышсыз-өнсез торган Хәкимҗанның янтавына төртеп алам:

— Синеңчә, кайсысы бигрәк тә матур?

Күрәсең, берсен генә әйтсә, бүтәннәрен кимсетү шикелле тоеладыр, ул бераз башын чайкап тора.

— Барысы да матур, һәммәсе дә...

кибән янтавы — кибән кырые

тоҗым — үрмәкүч пәрәвезенең көз көннәрендә һавада очып йөри торган бик нечкә җепселе

әбиләр чуагы — көзнең җылы, матур көннәре

сөрмә — чәч, каш, керфек каралта торган буяу

баг алмасыдай — *монда:* бик чибәр

мәрҗән — муенга тага торган бизәнү әйбере

чулпы — чәч толымына кушып үрелә торган тәңкәләр

Сораулар һәм бирем

1. Бу бүлекләрдә табигать үзгәрүгә бәйләнешле нинди йолалар турында сүз бара?
2. Авылда каз өмәләре ничек үтә? Сезнең каз өмәсендә катнашканыгыз бармы?
3. Шул чордагы яшьләр тормышын чагылдырган урыннарны табып укыгыз. Ни өчен яшьләр тәртипле һәм уен-җырга сәләтле булып үскәннәр?
4. Сез нинди йолалар беләсез? Мәктәптә татар халкының гореф-гадәтләренә, йолаларына багышланган кичәләр үткәргәнегез бармы?

Китап җене кагылган малай

V

Карлар эреп, юллар өзелә башлаган вакыт иде, базарга атка атланып кына китәргә туры килде. Юл буе борчылып бардым: «Ай-һай, бу пычракта чана сөйрәп йөрерме икән китапчы абзый?!»

Миңа бераз оят та, шул ук вакытта китапны алып киткәндәгегә караганда, бераз җиңелрәк тә иде. Үз кулым белән илтеп бирәм бит! Бу инде һич урлау түгел, юк! Китапчы абзыйга ниләр әйтермен икән?

— Мин бер китабыңны алып торган идем,— диярмен.

Абзый кеше шаккатар:

— Ничек алып тордың? — дияр.— Укып карарга дип алдыңмы?

Мин инде абзыйның орышуына да, шелтәсенә дә риза идем. Тик рәнҗемәсен, бәхилләсен генә!

— Әйе, әйе, укып чыктым инде мин аны, абзый! — диярмен.— Малайларга да укып күрсәттем. Зерә дә әйбәт китап. Үзе кызык, үзе гыйбрәтле.

Пычрак дип тормаган, китапчы агай килгән иде, рәхмәт төшкере. Мин аның кызыл бәс тышлы тунын, озын гәүдәсен ерактан ук күрдем. Ул бу юлы да базар уртасындагы әлеге кибет янына туктаган. Тик бүген нигәдер аның тирәсенә халык күп җыелган булып чыкты. Агайларның кайсылары аркаларына капчык, кайберләре берничә кием чабата аскан, култык астына манылган киндер я берәр төенчек кыстырган. Һәммәсе дә, башларын сузып, китапчы сөйләгәнне тыңлыйлар.

Хәнәфи абзыйда бүген китап сату кайгысы юк иде шикелле. Аның чырае шултикле кайгылы, әйтерсең менә хәзер елап җибәрер шикелле. Ул, намазга оегандагы кебек, кулларын кушырган, басынкы тавышы ара-тирә калтыранып киткәли.

— Безнең як тумасы иде бит, мәрхүмкәй, үзебезнең як егете. Менә шушы урамнардан ничә кәррә узганы бар. Әле Кырлайга кайтып китәр иде, әле Өчилегә. Ничә мәртәбәләр Казанның китап кибетендә очраштык. Күргән саен әйтер иде мәрхүм: «Ташы мәгърифәтне авылга, Хәнәфи абзый, кашыклап кына булса да ташы. Күп тамчыдан күл булыр»,— дияр иде. Хәзер менә язган китаплары белән баскан эзләре генә калды.

Әле генә килеп кушылган кайбер агайлар, үзара пышылдап, күршеләреннән сорашырга керештеләр:

— Кемне әйтә үзе, кем үлгән?

Хәнәфи абзый бу пышылдауларны ишетеп төшендереп бирде:

— Габдулла Тукаев вафат, шигырьләр язучы. Кем генә белмәс икән аны? Ул гомер буе халык өчен янып-көеп яшәде. Безнең ише кагылган-сугылганнар турында өзелеп-өзелеп күз яшьләре белән әллә ничә китап язып калдырды. Менә нинди шигырьләр чыгарды ул:

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый.
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

Аның язганнары халыкның күңеленә сары май булып төште. Изге җан иде ул безнең Габдуллабыз. Әйдәгез, җәмәгать, аның рухына бер дога кылыйк! Авыр туфрагы җиңел булсын!..

Китапчыны төрле яктан әйләндереп алган агайлар, дәррәү чүгәләп, ихлас күңелдән дога кылырга тотындылар. Минем тамак төбен нидер кытыклый башлады. «Сабыйларның догалары кабул була икән» дигәнне күп ишеткәнем бар иде. Догам күккә менеп җитәчәгенә чын күңелдән ышанып, кулларымны күтәрдем. Ләкин никадәр тырышсам да, доганың гарәпчә сүзләрен исемә төшерә алмадым, күңелдән генә үзебезчә теләргә керештем: «Ярабби, Габдулла абыйны көлле азаплардан азат ит. Ярабби, аның һәммәки гөнаһларын ярлыка, үзен мәңге җәннәтле ит. Амин!»

Агайлар, ачык кабер яныннан киткәндәй, тирән кайгы баскан хәлдә, башларын иеп китә торалар, алар урынына бүтәннәре килә. Хәнәфи абзый аларга да шул ук хәбәрне әйтеп кайгысын белдерә, ара-тирә чанасыннан китап алып берәр шигырь дә укып күрсәтә иде.

— Йөрәк ялкыннары кабынып дөрли генә башлагач, сүнде китте бичара. Шундый яшь чагында ук дөнья куяр дип кем генә уйлаган? Әле былтыр гына Хөсәен үлгәч, менә нинди усал итеп язган иде бит:

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?!
Без аны кайдан белик, мескен үлеп аңлатмагач?

Агайлар, чабата башларына карап, кайгы йотып торалар. Кайберләренең керфек төпләре юешләнә, кайберсе, нәрсәдер уңайсызлагандай, тамак кырып куя. Миңа алар бүгенге

базардан җилкәләренә йорт кирәкләре генә түгел, зур кайгы да күтәреп кайталар шикелле тоела.

Шунда кычкырып җибәрә яздым. Менә сиңа тамаша! Миннән ерак та түгел, Ямаширмәнең теге зимагуры белән читекче кыз Мазлума торалар. Исәнләшергә дип кулымны сузарга белмим, исәнләшмичә генә калырга да белмим. Әмма чырайлары шундый кайгылы иде, мин аларны борчымаска булдым.

Гыймай абыйның өстендә Сафа абый тегеп биргән шевиот бишмәт, башында шул элекке малорус дигән озын бүрек. Аягына күн итек киеп, биленә билбау урап җибәргәч, ул хәзер авылның ярыйсы гына көн күрүче йортлы-җирле хуҗа кешесенә охшый калган.

Ничек була соң әле бу? Читкә китеп югалды дигәннәр иде. Кайчан кайтты икән? Мазлума нигә аның белән? Әллә югыйсә... Гыймай абыйга кияүгә чыкмакчымы? Аннары китапчыда зимагурның нинди йомышы булсын икән? Алай дисәң, аңа күзе төшүгә, китапчының йөзе, якын кешесен очраткандагы кебек, үзгәреп китте. Хәнәфи абзый, «Менә шулай инде эшләр!» дигәндәй, хәсрәтле күзләрен җиргә текәде.

Шулвакыт кинәт кенә теге безгә имана җыярга килгән, саргылт сакалын патшаныкы кебек итеп төзәттергән урәтник килеп чыкты:

— Нәрсә бар монда, ә? Нәрсәгә җыелган бу толпа?—дип кычкырды.

Китапчы агай, аны күрүгә, кулларын йөзенә китереп дога укырга тотынды. Гыймай, урәтникнең колагына пышылдап:

— Знаш, ваш бгарудий,— диде,— Казан город татарский святой помирал. Ми наш магометанский бог малитва читайт. Паминка значит, паминка.

Урәтник, ышаныргамы, юкмы дигәндәй, бер зимагурга, бер чүгәләп дога кылып торган халыкка карап торды да тагын сорап куйды:

— Святой говоришь? Какой?

— Большой, большой! — Гыймай абый шунда ук уч төбен ачып, аңа бармагы белән язып та күрсәтте: — Книга писал. Много, много.

Миңа ничектер урәтник зимагурның русчаны юри шулай бозып әйтүен дә, изге кеше үлде дип күз буяр өчен генә сөйләвен дә яхшы белә, тик нилектәндер белмәмешкә генә салыша кебек тоелды. Ул Гыймайга сөзеп карады да кулын селтәп китеп барды:

— Ну, валяй, валяй!..

Мин, бу «вәләй»нең нәрсә икәнен аңламасам да, начар сүз булмаска тиешлеген чамаладым.

Мазлума апай, теге кара тешле убырлы карчык кулыннан ычкынып качып кайтканнан соң, туган авылында бераз гына торган да, тырыша торгач, Иж-Бубидагы кызлар мәдрәсәсенә укырга кергән. Анда зур галимнәр төрле яклардан җыелган татар кызларын мөгаллимә булырга укыталар икән.

— Их, менә кайда икән ул гыйлем, менә кайда безнең ишеләрнең күзен ачалар! — ди Мазлума. Тик патша түрәләре татар кызларының укымышлы кеше булуларына каршы торалар икән. Килгәннәр дә мәктәпне пыран-заран китереп туздырып ташлаганнар. Менә хәзергә анда укучылар «күздән югалып» торырга тиеш икән. Менә тагын бу якларга кайткан. Еларга җитешеп сөйли Мазлума.

— Ай энем,— ди.— Габдулла абый да әнә шул кысынкылыкны күтәрә алмаган. Кая барсаң да бер кояш, күбәләктәй газиз җанга көч. Кайчан гына муеннары асларына килер?

Мин юл буе иләс-миләс хәлдә кайттым. Базарчы агайларның, иң газиз кешеләрен күмгәндәге кебек, авыр кайгыга батулары юл буе күз алдымнан китмәде. Мин узган авыллардагы мескенләнеп утырган тәбәнәк өйләрне дә шул ук хәсрәт баскан иде. Зираттагы шәрә каеннарның җилдә ыжылдавы да әлеге көзге җил турындагы йөрәкне пешереп ала торган әрнүле сүзләрне искә төшерде.

Әле берәр ай гына элек Әбүгалисина белән ничек җенләнгән булсам, хәзер шулай ук, алны-ялны белмичә, тоташтан Тукай шигырьләрен укый башладым. Аның сүзләре нәкъ кирәк вакытында, күктән иңгән кебек, ничектер, үзеннән-үзе күңелгә килеп керә башлады. Әллә ничек кенә искә килә дә, яраткан җыруың шикелле, үзеннән-үзе көйләнә. Күбәләк яисә карлыгач күзгә чалындымы, аның шигырьләре искә төшә. Берәр агайның сука артыннан икегә бөгелеп атлавын күрдеңме, тагын аның шигырен хәтерлисең. Үзебезнең бакча башына я тыкрыкка чыккач, авыл өстенә, чишмәләргә күз төштеме, тагын аның шигырьләре телгә килә.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән...

шаккату — бик нык гаҗәпләнү, хәйран калу
рәнҗү — хәтер калу, үпкәләү
гыйбрәтле — сабак булырлык, уйланырга мәҗбүр итә торган
безнең як тумасы — безнең як кешесе
кәррә — мәртәбә, тапкыр
көлле — барлык, һәммә

Сораулар һәм биремнәр

1. Гомәр базарга ни өчен килә һәм нинди вакыйгага очрый?
2. Хәнәфи абзый кем ул? Ул Тукайның нинди сүзләрен исенә төшерә? Шул юлларны табып укыгыз.
3. Тукайның үлеме халыкка ничек тәэсир итә?
4. Бөек шагыйрьнең шигырьләре булачак язучыга ничек ярдәм итә?
5. Әсәрне тулысынча укыгыз.

Повесть

Повесть — эпик төрнең бер жанры яки хикәяләп язылган әдәби әсәрнең бер төре.

Повестьта вакыйгалар, нигездә, туры сызык буенча үстерелә, бер-берсенә ялганган төрле вакыйгалар сурәтләнә. Герой тормышының бөтен бер чоры яктыртыла, аның тирәсендә башка персонажлар да хәрәкәт итә.

Повесть тормышны хикәягә караганда катлаулырак итеп чагылдыра. Татар әдәбиятында повестьны **озын хикәя** дип тә йөртәләр. (М. Әмирнең «Агыйдел», Г. Исхакыйның «Көз» әсәрләре.)

Повестьта хикәяләү «мин» исеменнән дә алып барылырга мөмкин. Автобиографик повестьлар да була. Мәсәлән: Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», Ф. Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» әсәрләре.

ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ

Гомәр Бәширов шигыре *Сара Садыйкова музыкасы*

Җидегән чишмәләрдә җиде улак, җиде улак,
Челтер-челтер ага көмеш су.
Көмеш сулар ага, кошлар сайрый,
Шул чакларда бигрәк,
Шул чакларда бигрәк ямансу.

Җидегән чишмәләргә йөзек салдым, йөзек салдым,
Җидегән йолдыз күреп калсын дип.
Җанкай-җанаш алсын да куансын,
Вәгъдәләрем булып,
Вәгъдәләрем булып калсын дип.
Җидегән чишмәләрнең талы бөгелә, талы бөгелә
Иртән искән җәйге җилләргә.
Сез каласыз инде, без китәбез,
Без китәбез ерак,
Без китәбез ерак илләргә!..

Бирем

Җырны өйрәнегез.

«Туган ягым» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Кешенең туган җире каян башлана?
2. Сез үзегезнең туган ягыгыз турында нәрсәләр беләсез?
3. Туган ягыгыз табигатен күзәткәнегез бармы? Ул сезгә ничек тәэсир итә?
4. Туган халкыбызның нинди гореф-гадәтләрен беләсез? Итагатьле, тәртипле, үз милләтен яратучы булып үсүдә гореф-гадәтләрнең әһәмияте бармы? Мисаллар китереп сөйләгез.
5. Гомәр Бәшировның бу повесте ни өчен «Туган ягым — яшел бишек» дип атала?
6. Туган якка багышланган тагын нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

Бирем

«Туган ягым — яшел бишек» дигән темага хикәя төзеп языгыз.

Васил Маликов
(1924—1992)

Васил Маликов 1924 елның 19 октябрендә Татарстанның Актаныш районы Иске Кормаш авылында туа. 1942 елда Казанда һөнәр училищесын тәмамлаганнан соң, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1948—1953 елларда Казан сәнгать училищесында укый. Училищеда уку елларында ук Садри Ахун җитәкчелегендә сыннар ясау (скульптура) белән шөгыльләнә башлый. Казанда Мәңгелек ут янындагы монумент В. Маликов тарафыннан ясалган. Бу монумент шәһәребезнең күрке булып тора. Васил Маликов үзенең бөтен осталыгын портрет жанрында күрсәтә. М. Вахитов, М. Җәлил һәм башка милли каһарманнарга эшләнгән һәйкәлләр — шуның ачык мисалы. Рәссамның берничә әсәре фронт истәлекләренә бәйле рәвештә бирелгән. «Хәтерендәме, иптәш?», «Соңгысы» кебек хезмәтләре аның иҗади кызыксынуының күпкырлы булуына ышандыра. «Соңгысы» әсәре 1980 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Рәссамга иҗаттагы уңышлары өчен РСФСРның атказанган, Татарстанның халык рәссамы дигән мактаулы исемнәр бирелә.

В. Маликов 1992 елның 11 октябрендә Казан шәһәрендә вафат була.

Сораулар

1. Васил Маликов кем ул? Аның иҗаты турында нәрсәләр белдегез?
2. Васил Маликов иҗат иткән нинди һәйкәлләрне беләсез?
3. Татар скульпторларыннан тагын кемнәрне беләсез?

Кави Нәҗми

(1901—1957)

1901 елның 15 декабре. Горький өлкәсенең Петрякс районы Красный Остров авылында бер ир бала дөньяга килә. Аңа Кави дип исем кушалар. Һибәт абзый матур хыялларга чума. Ир малай бит, бер имана җир арта дигән сүз. Ләкин яңа туган балага тиешле җир генә авыр тормышны җиңеләйтә алмый. Һибәт абзый, гаиләсен алып, чит җирләргә китәргә мәҗбүр була. Алар Актүбә шәһәрендә яши башлыйлар.

Монда Кави алтыеллык рус-татар мәктәбендә укый. Җәйге айларда тамак ялына төрле эшләрдә эшли.

Кави Нәҗми яшьтән үк Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал кебек күренекле язучыларның әсәрләре белән таныша. Шулар йогынтысында 1912 елда «Күз» исемле беренче шигырен яза, рус шагыйре А. Кольцовның «Урман» шигырен татарчага тәрҗемә итә.

1919 елда Кави Сембердәге (хәзерге Ульяновскидагы) педагогия курсларына укырга керә. Курсларны тәмамлагач, матбугат эшләрендә катнаша башлый. Тиздән гражданнар сугышына китә һәм ак интервентларга каршы көрәшә.

1923 елда Мәскәү Югары хәрби педагогия институтын тәмамлый. Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбендә сәяси фәннәр укыта. 1926—1933 елларда Казанда чыга торган «Кызылармеец» газетасында редактор булып эшли.

Бу елларда язучы күп кенә хикәяләр, повестьлар яза. Аның әсәрләре Октябрь борылышына кадәрге тормышны һәм революцион хәрәкәтне («Миңлебикә кодагыйның кайгысы», «Кайтты»), гражданнар сугышы чоры вакыйгаларын

(«Чыныгу», «Иң соңгысы», «Шобага», «Яр буенда учаклар»), крестьяннарның колхозларга берләшүен («Якты сукмак», «Кояшлы яңгыр») чагылдыралар.

1932 елда Кави Нәҗми Татарстан Язучылар берлеген оештыру комитетына сайлана. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында редактор булып эшли. Бөтенсоюз совет язучыларының беренче съездында катнаша һәм татар матур әдәбияты турында доклад ясый. Съездда аны СССР Язучылар берлеге идарәсенә әгъза итеп сайлыйлар.

1941—1945 елларда ул Татарстан радиокомитетында эшли. Бөтен иҗат сәләтен фашизмны җиңү эшенә багышлый.

1949 елда Кави Нәҗми Казан эшчеләренең революцион көрәшкә катнашуларын сурәтләгән «Язгы җилләр» романын бастырып чыгара. Бу китап, шул чор татар прозасының күренекле әсәрләреннән берсе буларак, СССР Дәүләт премиясенә лаек була.

К. Нәҗми — гомере буе язучылык хезмәтен иҗтимагыйсәяси һәм дәүләт эшләре белән бергә бәйләп барган әдип. Шушы хезмәтләре өчен хөкүмәтебез аны орден һәм медальләр белән бүләкләде.

Кави Нәҗми 1957 елның 24 мартында Казан шәһәрендә вафат була.

МИҢЛЕБИКӘ КОДАГЫЙНЫҢ КАЙГЫСЫ

(өзекләр)

1910 елның кышы үтеп, яз җитте. Эссе көннәр башланды. Хисамидан һаман хәбәр юк. Миңлебикәнең тормышы ут эчендә, куркыныч төшләр уртасында уза. Көннәрдән бер көнне ул старостага бара, киңәшләшеп карый. Староста бер генә юанычлы сүз дә әйтмәгәч, писарь Сәйдәшевкә бер каз илтеп:

— Шәһәргә бар! — дигән киңәшне алып кайта.

Миңлебикә үзенең яшь чакларын шәһәрдә уздырганга күрә, бу киңәш аның күңеленә кереп утыра. Ләкин иң элек, кыш көне төргәк илтеп биргән Юкәтау Васильевына барып, аңарга да үзенең уен әйтмәкче була. Эзли, эзли, таба алмый. Юкәтаудагы фельдшер очрап, Васильевның полициядән качып йөрүен, бик шикле кеше икәнлеген сөйли дә:

— Үзең карчык кеше... Үзең фетнәчеләр артыннан йөрисең. Әгәр дә сау башыңны авыру ясыйсың килмәсә, аны эзләмә. Алар яхшылыкка илтмәсләр,— ди.

Шуннан соң гына, авылга кайтып, Хәерниса янында өй сакларга дип ахирәтен, Хәйрибә исемле тол карчыкны калдыра да шәһәргә юнәлә.

Шәһәр ерак. Шәһәр зур.

Бик күп бусагаларны, бик озын урамнарны таптый торгач, Миңлебикә әби окружной суд йортына барып керде. Күя ашап бетергән шәленең бер почмагын бөтәрли-бөтәрли үзе белән бергә алып барган тылмач шәкерт аркылы шундагы адвокатларның берсенә үтенечен сөйләп бирде. Башта Миңлебикәнең күзенә бик ягымлы күренгән бу адвокат көмеш савытыннан кыйбатлы папиросын чыгарып, авызына капты да төтенен Миңлебикә өстенә җибәрде:

— Хәлегез җитәрмедер, юкмыдыр, монда эш биш йөз тәңкәсез барып чыкмас,— диде.

Шәһәргә алып килгән бөтен акчасы биш тәңкәдән артмаган Миңлебикә өчен мондый сумманы ишетү таяк белән башка суккандай булды.

— Кайда инде ул безнең ише хәерчеләргә биш йөз тәңкә! Андый акчалар кулда булса, Хисами да төрмәгә эләкмәс иде.

Адвокат, әбидән эш чыкмаслыгын сиздемедер шунда, күршедәге бүлмәләрнең берсенә кереп югалды. Шул арада тагын берәү күренде. Бусы алтын төймәле мундирдан. Тылмач итеп яллаган шәкертнең: «Сез окружной судта эшләмисезме?» — диюенә каршы: — «Әйе, ни йомыш?..» — диде. Йомышның нәрсәдә икәнен әйткәч, башын гына чайкады. Булмаса, төрмәгә барып Хисами белән күрешергә рөхсәт кәгазе бирелсә икән, дип ялваргач:

— Бирелмәс!— диде дә шул арада ишектән кергән яшь кенә бер кызга башын иеп, култыклап алды, һәм алар чыркылдаша-чыркылдаша югарыга менеп киттеләр.

Миңлебикә шул сыны белән катып калды. Аның башында төрле сукмакларга бүленеп йөгергән уйлар төркеме үзара тиңләшеп, көчләрен чагыштырып уздылар.

— Төрмә үзенең серләрен читкә чыгарырга яратмый торгандыр шул. Төрмә йөз еллар буенча үз эченә җыелган шомлы күренешләрне, канлы хәбәрләрне ныклап сакларга күптән өйрәнгәндер шул...

— Шулай да... кайсы вакытны сораучысына карап яки юатырга, яки кырт кисеп «үтерелде» дип әйтергә, яки «чит шәһәргә күчерелде» дип алдарга мөмкин бит. Нигә минә

хәзер шулай итмәскә? Миңлебикә өч җавапның өчесенә дә риза, чыгарга да әйтергә иде:

— Син, карчык, кайгырма! Улыңны чыгарырлар. Патшаның баласы туса икән, дип теләктә тор. Аның баласы тугач ук, манифест чыга. Шуннан соң патша Хисамины төрмәдән чыгарырга кушар. Ә хәзер авылыңа кайт та өеңне җыештыр!

— Син, карчык, монда йөрмә дә, сорама да. Улыңны үткән атнада ук астылар.

— Улың бу төрмәдә түгел шул. Аны фәлән шәһәргә күчерделәр, барсаң, бәлки, очратырсың...

Миңлебикә бу өч төрле җавапның кайсын булса да алып китәргә тели. Тик бер генә минутка Хисамины күрәсе иде. Ишеккә юнәлгән бер яшь кенә егеттән дә шул турыда сорады. Анысы да шул ук җавапны әйтте:

— Рөхсәт юк! Не полагается!

Шуннан соң гына аптырауның соңгы чигенә җиткән Миңлебикә әлеге тылмач шәкерткә:

— Мә инде, булмаса, улымның рухына ясин укырсың,— дип, егерме ике тиен акча бирде дә соңыннан шулай диюенә үкенә-үкенә урамга чыкты.

Тагын аның алдыннан шоп-шома юргалар, чуар киемнәр, күп маллы кибетләр, чуар киемле кешеләрне төягән трамвай вагоннары агарга тотынды. Бу тизлектән, бу өзлексез йөрешләрдән аның уйлары бөтенләй чыгырыннан чыктылар. Юлда клиндер сатучы бер хатын очрап, бәйләменә ун тиен сорады. Миңлебикә, һичбер исәпләмичә-нитмичә, нәрсә эшләгәнен үзе дә аңламыйча, клиндерне алды. Бугаз төбенә төйнәлгән төеннәрнең катылыгыннан, күздән тамган яшьләрнең ачылыгыннан арчыла алмыйча, елау аралаш юл буенча клиндер кимереп барды да капка төбендәге эскәмиягә утырды. Күз алдына атасының кайчандыр шушы шәһәрдә күн заводында эшләвен, ярминкәгә барып, таш курчак алуларын тезеп уздыргач, тагын кузгалды.

Кешенең башы бер әйләнсә әйләнә икән. Һичбер нәрсәнең рәтен-чиратын табар хәл юк. Миңлебикә белән дә шулай. Йөри-йөри дә я вокзалга, я базарга барып чыга.

Базардагы ниндидер бер карт белән сөйләшә башлагач, монда якында гына Мещанский урамда окружной суд мулласының барлыгы беленде. Мулла үзе төрмәдәге агай-эне халкына кәлимәишәһадәт укыта икән. Бу хәбәрне ишеткән төнне Миңлебикә йоклый алмады. Йөрәге яртылаш тыныч-

ланса да, шул мулланы тизрәк күрергә теләү тойгысы бөтен гәүдәгә китте.

— Әгәр дә ул табылса...

— Әгәр дә аның абыстаен күрсә... Мин бит ул абыстайның аяк астында туфрак булырга да риза...— дигән уйлар, бәхет кошы эзләгәндәге ашкыну бөтен ми ятьмәләрен урап чыктылар.

Абыстай белән ничек күрешү, күпме садака бирү, ничек итеп сөйләшү, хәзрәтнең үзенә шул хәлләрне аңлатып кәгазь яздыргач, ул кәгазьне шәлнең кайсы почмагына төенләү, улы Хисами белән кочаклашып күрешү турында төн буенча план корды да шул планның киңлегенә, барып чыгардай булуына куана-куана таң аттырды. Иртә белән:

— Намазга торганнардыр инде. Хәзер үк кузгалганда да ярар. Хәзрәт үзе сәгать җиделәрдә мәчеттән кайтса, таман гына була, үзеңә тапшырдым, Ходаем...— дип, урамга чыкты.

Сораулар һәм бирем

1. Миңлебикә шәһәргә ни өчен бара?
2. Шәһәр аны ничек каршылый?
3. Сез ничек уйлыйсыз, Миңлебикәнең окружной суд мулласына булган өметләре акланырмы? Ни өчен?
4. «Тагын аның алдыннан, шоп-шома юргалар, чуар киемнәр, күп маллы кибетләр, чуар киемле кешеләрне төягән трамвай вагоннары агарга тотынды» дигән җөмләдәге күренешне үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

VII

Урамнарда рәтләп кеше йөргәне күренми. Тик дворниклар гына, бөтен тирә-якны тузанга батырып, капка алларын себерәләр. Яхшы фаэтоннарның да, трамвайларның да тавышы ишетелми.

Миңлебикә озак барды, көтелгән күрешүдән йөрәге ярылырдай булды.

Менә яшел түбәле, ике этажлы таш йорт. Әллә нинди ялтыравык челтәр белән бизәлгән сары капканың уң ягында — әлеге карт әйткән матур ишек... Әнә шул ишеккә беркетелгән ап-ак сөяк төймә... «Бисмилла» әйтеп, баш бармак белән басарга да, аннан тәнгә таза гына, көр генә, ачык чырайлы гына абыстай килеп чыгар. Кулында тәсбих булыр, аягында чәмчәле, бизәкле читек. Башында кәшемир яулык.

Үзе бик йомшак тел белән, вәкарь белән генә сөйләшер. Садаканы алгач, озак кына итеп Хуҗа Әхмәт Ясәвигә багышлап, дога кылыр һәм:

— Бик исән-сау гына йөрисеңме? Бала-чагаларың бик сәламәт кенәме? Кичә әле мулла, Корымсала Миңлебикәсенең улын япканнар икән, дип сөйләшкәч, шулхәтле кызгандым инде. Шулхәтле ялындым инде. Әйтмәгән сүзем калмады. Син бер дә кайгырма. Кая әле бишмәтеңне салып утыр. Тиздән үзе дә кайтыр. Хәзер аш хәстәрлим. Ачыккансыңдыр. Шуннан бергәләп Хисами янына китәрбез,— дип әйтер төсле тоелды.

Миңлебикә әнә шулай уйлады. Шулай уйлап, өч мәртәбә «бисмилла» әйтеп, түгәрәк кнопканы уң кулының баш бармагы белән әкрен генә басты. Йөрәге тагын да ныграк тибәргә тотынды. Ләкин җавап юк. Бер ярты сәгать үткәнмедер, юкмыдыр, әллә теге яңлыш әйтте микән, дип шиккә калса да, тагын кнопканы басты. Тагын җавап юк.

— Әллә басарга түгел микән?.. Туктале, тартып карарга кирәк ишекне!— дип, тырнагының очын кертеп, тартмакчы булды. Тартылмады. Шуннан соң бер-бер артлы ишекнең үзен дөбердәтергә тотынгач кына, югарыда ишек ачылганы ишетелеп, кемдер йокы аралаш ачулы тавыш белән мыгырданып кычкырды:

— Хту там? Нәмәстә кирәк? Мулла спит...

— Мин бу... әйе... Хәзрәт абзый мәчеттән кайтмады микән, дигән идем.

— Юк, юк. Барганы да юк... Кайтканы да юк,— дип, бик нык шакылдатып ишекне япты.

Миңлебикә көтәргә дип баскыч төбенә утырды. Утырды да:

— Болар коткармаса, кем коткарыр... Хисами өчен елапелап гафу сорармын башта. Аннары садака бирермен. Яки элек садака биреп, аннары гафу сорармын. Боларда гына инде өметем...— дип уйга батты.

Эченнән бөтен белгән догаларын кабатлады. Менә бервакытны зур капканы ачтылар да, бик яхшы экипажга җигелгән ат тотып, кучер чыкты. Парадный ишек төбенә туктады. Озакламыйча югарыда тагын ишек шыгырдап, берәү, тамагын кыра-кыра, баскычтан төшә башлады. Миңлебикә, урыныннан торып:

— Бу кем булыр икән?— дип, бохар чапаны кигән, башына чалма чорнаган, кулында таяк, аягында читек-кәвеш булган хәзрәтне күз алдына китереп бастырды...

Парадный ишек зыңгылдап ачылды. Ләкин аннан: «Ишекне бикләргә онытма! Жулик бик күбәйгән, ди, ишеттеңме... Жуликлар бик күбәйгән, ди... Газизәне уятма, йокласын. Ул болай да кичәге танца вечереннан сәгать дүрттә генә кайтты»,— дип, куян тизлеге белән шыгырт-шыгырт килеп чыгып та китте.

...Шулай итеп, соңгы өмет тә җимерелде. Муллага, түрәләргә текәлгән соңгы ышаныч та җыерчыклы бит буйлап тәгәрәүче ачы күз яшьләре белән бергә йотылды...

Сораулар һәм биремнәр

1. Миңлебикә окружной мулланы ничек күз алдына китерә?
2. Ишек ачылып, өстән ишетелгән тавыш Миңлебикәнең фикерен үзгәртәме? Ул тавыш сезгә ничек тәэсир итте?
3. Мулланың тышкы кыяфәтен сурәтләгез. Ишек ябучыга әйтелгән сүзләрен искә төшерегез. Аның балалары турында нәрсә әйтә аласыз?
4. Сезнеңчә, бу мулла үз милләтен якларммы? Авыл кешесенең ышанычын акларммы?
5. Соңгы ике җөмләгә нигезләнеп, нәрсә әйтә аласыз? Миңлебикәдә мулла һәм түрәләргә ышаныч калырмы?

ХӘЯТ АПА

(кыскартып алынды)

Таң йолдызы Казан өстендә
Якты күзен кысып елмайды
Һәм, Иделгә чумган чабак төсле,
Кинәт кенә сүнде,
Югалды.

Сәгать алты.
Хәят апаның
Сменасы бүген җидедә.
Иртәнге чәй тагын ялгыз үтте,
Улы да юк янда, ире дә.

Улы Камил күптән чик буенда.
Быел менә июнь аенда
Ире китте —
Җәйге отпускасын
Үткәрергә Камил янында.

Нинди бәхет шундый семьяң булу,
Нинди рәхәт шулай яшәве!
Очып кына барып яннарына,
Карыйсы иде хәзер өчәвен.

Шушы тойгы белән дәртләнеп,
Канатланып йөргән чагында,—
Ниткән хәл бу?..
Радио хәбәр итә...
Берәр атна үткәч,
Шул ук хәбәр
Кабатлана аның хатында:

«Хәят җаным, миңа ачуланма:
Кайта алмам, бәлки, тиз генә.
Адәм каны эчеп котырган
Дошман керде илнең чигенә.

Камилләрнең погранзаставасын
Каушатмады ләкин бу һөҗүм.
Аңар булышучы партизаннар
Отрядына кердем мин үзем.

Намус өчен,
Халык бәхете өчен,
Безнең белән бергә,
Бер постта,
Кулга корал алып, безнең килен —
Наталья да керде сугышка.

Почтальоннар, бәлки, килә алмас,
Сугышабыз шундый урында.
Шуны нык бел:
Кайда сугышсам да,
Син булырсың минем уемда...»

Ире белән бергә,
Бер үк цехта
Ул үткәрә эшләп гомерен,
Күрше станокта һәрвакытта
Күреп килә Хәят үз ирен.

Ә бүген—
Буш аның станогы...
Отпускадан кайтып җитәр дип
Уйлаганнар, ахры,
Нык ышанып,
Бозылмас дип бүген ул тәртип...

Менә бу станок —
Иптәшемнең сөйгән станы.
Бөек Ватан сугышы беткәнче,
Үземнеке саныйм мин аны.

Шул сүз белән Хәят эш башлады.
Бер-бер артлы ике станок
Тигез ритм белән ходка китте.
Секундка да хәзер туктау юк.

Тәгәрмәчләр кызу әйләнәләр,—
Ашыктырып һәрбер минутта.
Безнең заводларның ярдәм көчен
Җиткерергә тизрәк фронтка...

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу поэмада сүз кем турында бара?
2. Вакыйга кайсы чорга карый?
3. Хәят апаның ире кая китә? Нинди хәлләргә очрый?
4. Хәят апа нинди уйлар кичерә?
5. Ул тылда нинди батырлык эшли? Шул юлларны табып укыгыз.
6. Әсәрнең эчтәлеген үз сүзләрегез белән сөйләгез.

Солтан Габәши

(1891—1942)

Солтан Хәсән улы Габәши 1891 елның 1 маенда элекке Казан губернасы Сулабаш авылында (хәзерге Биектау районы) туа. Габәши кечкенә вакытында ук кубызда, гармунда халык көйләрен уйнарга өйрәнә. Гаиләләре белән Уфага күчеп килгәч, үзлегеннән фортепьянода уйный башлый. Бу турыда искә алып, Габәши: «Ул вакытта мин музыка белән бернинди максат куймыйча, болай гына шөгыльләнә идем»,— дип яза. Шулай булуга карамастан бу вакытта алган белеме аңа музыка дөньясына кереп китәргә юл ача, ә соңга табарак инде ул бөтен тормышын музыка эшчәнлегенә багышлый. 1909 елдан әдәбимузыкаль кичәләрдә, татар музыкасы концертларында катнаша башлый, пианист-аккомпаниатор буларак чыгышлар ясый. Мәктәпләрдә дәресләр алып бара. Әкренләп, үзендә дә көйләр язып карау теләге туа.

1915—1919 елларда фортепьяно өчен кечкенә пьесалар («Вальс», «Пикник» һ. б.) һәм татар драма труппасының берничә спектакленә («Таһир-Зөһрә», «Зөләйха») музыкалар яза. Болар — аның иң беренче әсәрләре.

1922—1926 елларда ул Казан музыка техникумы мөдире урынбасары булып эшли, музыка теориясеннән укыта. Татарстан районнарына фольклор экспедицияләренә чыга һәм татар, башкорт халык көйләреннән җыентыклар төзи.

Габәши тәрҗемә эшләре белән дә шөгыльләнә. Итальян теленнән «Чио-Чио-сан» (Д. Пуччини) операсының либреттосын тәрҗемә итә. Татар музыкасы мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләре белән матбугатта чыгышлар ясый.

С. Габәшинең «Бүз егет» пьесасына язган көйләре, тынлы оркестр өчен иҗат иткән «Татар маршы», «Яңалиф маршы» — игътибарга лаеклы әсәрләр. Композиторның «Кәккүк» романсы — шулай ук халык мәхәббәтен казанган әсәрләрнең берсе.

«Сания» һәм «Эшче» опералары белән Габәши музыка сәнгате үсешенә зур өлеш кертте.

«Эшче» операсы (М. Гафури сүзләре) беренче тапкыр 1930 елда сәхнәгә куела. Әсәрдә Нигъмәтнең авыр язмышы, эшчеләрнең алтын приискасындагы хезмәте, тормыш кыенлыклары, революцион хәрәкәт һәм аның корал көче белән бастырылуы күрсәтелә, һәр вакыйга, шул чор күренешләренә нигезләнеп, махсус музыка белән бара.

Солтан Габәши музыка өлкәсендә Татарстанда гына түгел, Башкортстанда да күп эшләде. 1930 елда ул Уфада башкорт сәнгате техникумында музыка теориясеннән һәм хордан укыта. Музыка теориясе буенча башкорт телендә дәреслек төзи. Х. Ибраһимов, М. Вәлиев, А. Ключарев әсәрләрен һәм башкорт халык җырларын туплап, җыентык чыгара.

Солтан Габәши — Башкортстан Композиторлар берлеген оештыручыларның берсе.

Ул, татар һәм башкорт музыкаль фольклорын башлап җыючы, халык арасында күп тавышлы хор белән җырлауны пропагандалаучы һәм опера тудыру эшен башлап җибәрүче буларак, күп хезмәт күрсәтте. Татар музыкасы профессиональ үсешенең башлангыч этапларында аның хезмәте зур әһәмияткә ия.

Солтан Габәши 1942 елның 8 гыйнварында Башкортстанның Борай районы Чалкак авылына сөргенгә җибәрелгән җирдә вафат була.

Сораулар һәм бирем

1. Солтан Габәши татар музыка сәнгате тарихында нинди урын тота?
2. Аның тормышы һәм иҗаты турында нәрсәләр белдегез?
3. Ул беренче тапкыр нинди опералар тудыруда катнаша?
4. Татар операларын иҗат итүче композиторлардан тагын кемнәрне беләсез?
5. Солтан Габәшинең бер әсәрен тыңлагыз, фикер алышыгыз.

Опера

Опера — музыка һәм җыр белән башкарыла торган сәхнә әсәре.

Сезнең опера тыңлаганыгыз бардыр, мөгаен.

...Утлары балкып торган зиннәтле зал бәйрәм рухы тудыра. Менә акрынлап яктылык тоныклана... гөжләү тына.

Сәхнә алдындагы түбән урында оркестр урнашкан. Оркестрдан башка опера булмый: ул җырчыларга һәм хорга җырлау өчен мөмкинлек барлыкка китерә, музыкаль күренешләр тудыра. Оркестрның пәрдә ачылганчы уйнаган музыкасы *увертюра, кереш* дип атала. Увертюра тамашачыларны тыңланачак әсәрне кабул итәргә әзерли. Анда, гадәттә, операның төп көйләре яңгырый. Шулай итеп, увертюра кешедә билгеле бер халәт тудыра, һәм, пәрдә ачылып киткәндә, кеше үзен башка дөньяда дип хис итә. Матур декорацияләр операда бара торган вакыйгаларның урынын күз алдына китерергә ярдәм итә. Декорацияләрне, актерлар өчен киемнәрне рәссамнар иҗат итә. Опера артистлары рольләрне драма артистлары кебек үк уйныйлар. Тик опера геройлары хис-кичерешләрен арияләр, җырлар аша белдерәләр. Әгәр берничә катнашучы бергә җырласа, бу — ансамбль була. Опера хоры да спектакльдә бик әһәмиятле роль уйный.

Сораулар

1. Нәрсә ул опера?
2. Опера геройлары хис-кичерешләрен ничек белдерәләр?
3. Сезнең нинди опералар тыңлаганыгыз бар?

Муса Җәлил
(1906—1944)

Татар халкының бөек улы, каһарман шагыйрь Муса Җәлил 1906 елның 15 февралендә хәзерге Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында туа. 1913 елда Мостафа абзый, гаиләсен алып, Оренбургка күчә. Монда Муса Тукай, Дәрдемәнд, Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша. Шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр яза башлый. Аның беренче шигырьләре «Кечкенә Җәлил» имзасы белән басыла.

1922 елда Муса Казанга килә. Башта «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, 1923 елда татар рабфагында укый башлый. Шул елларда ул «Бибкәй кыз», «Каз канаты» исемле пьесаларын яза. Бу пьесалар Казан, Уфа шәһәрләрендә куела, 1925 елда «Барабыз» исемле беренче шигырьләр китабы чыга. «Иптәшкә» дигән шигырь җыентыгы (1928) Җәлилне шул заманның алдынгы шагыйрьләре рәтенә бастыра.

1927 елдан ул Мәскәүдә яши башлый. 1932 елга кадәр башта «Кечкенә иптәшләр», соңыннан «Октябрь баласы» исемле балалар журналларының җаваплы редакторы була. 1927—1931 елларда Мәскәү университетының әдәбият бүлегендә укый.

1935 елда Муса Җәлил Мәскәүдә Татар опера студиясендә әдәби бүлек мөдире булып эшли башлый. Студия Татар опера театры өчен җырчылар, композиторлар әзерли. Студияне тәмамлаучылар Казанга кайткач, Татар опера һәм балет театры ачыла. Муса Җәлил дә, шул театрның әдәби бүлек мөдире булып, Казанга кайта. 1939 елда Мусаны Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе итеп сайлыйлар.

Мәскәүдә яшәгән елларда шагыйрь «Хат ташучы» поэмасын, «Алтынчәч», «Илдар» либреттоларын яза. Композитор Нәҗип Җиһанов бу либреттоларга опералар иҗат итә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Муса Җәлил, беренчеләрдән булып, сугышка китә. Сугышта да каләмен кулыннан төшерми. 1943 елда аның «Тупчы анты» дигән җыентыгы басылып чыга.

1942 ел. Июнь. Шагыйрь Волхов фронтында. Каты сугышлар вакытында аларның часте чолганышта кала, М. Җәлил яралы хәлендә дошман кулына эләгә.

Фашистларның үлем лагере. Сорау алу һәм җәзалаулар. Шомлы үлем шәүләсе. Ләкин Җәлилнең рухы сынмый, ул көрәшне туктатмый. Шигырьләр яза. Иптәшләренең рухын күтәрә, аларны көрәшкә өнди. Гитлерчылар әсирләрне туган илләренә каршы сугышырга димлиләр һәм «ирекле легионнар» төзү белән шөгыльләнәләр. Ләкин аларның өметләре акланмый. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре, легионерлар арасында аңлату эшләре алып барып, немецларның коткысын фаш итә.

Муса Җәлил һәм аның иптәшләре гитлерчыларга каршы кораллы восстание әзерлиләр. Ләкин араларына үтеп кергән бер хыянәтче аларның бу планнарын фашистларга ача. Мусаны һәм аның көрәштәшләрен төрмәгә ябалар. Тоткынлыкта язган шигырьләрен Җәлил 2 блокнотка туплый. Бер блокнотын Берлин төрмәсеннән Габбас Шәрипов исемле бер тоткын, ә икенчесен Моабит төрмәсендә бергә утырган бельгияле Андре Тиммерманс алып чыга.

1944 елның февралендә фашистларның хәрби суды Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә.

Муса Җәлилнең исемен халкыбыз мәңгеләштерде. Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет театры Муса Җәлил исемен йөртә. Шагыйрьгә Казанда һәйкәл куелды. «Җәлил» операсы театр сәхнәсеннән төшми. Мусага багышлап, язучылар, шагыйрьләр, драматурглар — романнар, поэмалар, сәхнә әсәрләре; композиторлар — җырлар, симфонияләр; рәссамнар картиналар иҗат итәләр.

Муса Җәлилнең тиңдәшсез батырлыгы югары бәяләнә. 1956 елның 2 февралендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1957 елда «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясе белән бүләкләнә.

БЕР ҮГЕТ

(Кешелек турында)

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.

Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.

Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!

Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк эзен күрсеннәр.
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр.

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең маяк булып
Үзеңнән соң килгән буынга.

Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне игътибар белән сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Чын кеше нинди булырга тиеш? Шул турыда язылган юлларны укыгыз.
3. Сез көчле кеше дип кемне саныйсыз? Шигырь юлларында бу ничек чагыла?

4. Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас,—
дигән юлларны ничек аңлыйсыз? Шул турыда тормыштан да мисаллар китереп сөйләгез.
5. Шигырьдә нинди тел-сурәтләү чаралары кулланылган?

бәдәнле — гәүдәле
түмгәк — җир өстендәге кечкенә калкулык (кочка)

ИМӘН

Юл чатында ялгыз гына
Үсеп утыра бер карт имән.
Тирә-ягы яшел чирәм,
Ботаклары җиргә тигән.

Таң җилләре җилфер-җилфер
Җилфердәтә яфракларын.
Имән җырлый, искә төшереп
Шаулап үскән яшь чакларын.

Мең ел элек кемдер монда
Җир казыган, тир тамызган.
Һәм беренче кат имәннең
Яшәү иртәсен кабызган.

Кем дә белми ул кешене,
Игенчеме, бакчачымы,
Яшеллек һәм хәят сөйгән
Батыр хезмәт патшасымы?

Кем булса да, туфрагында
Җир саклаган аның тирен.
Һәм карт имән гомере белән
Бүләкләгән бу эш ирен.

Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы — моңлы җырчы —
Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны.
Кавыштыра айлы кичтә
Яшерен утта янганнарны.

Юл күрсәтә адашканга
Имән кышкы бураннарда.
Җәен татлы дымын эчерә
Кырда урак урганнарга.

Бәхетле син, ерак илдәш,
Хезмәтеңә мин баш иям.
Һәйкәл булып яшьлегеңә,
Үскән монда бу карт имән.

Җирдә кеше торса торсын,
Эзе калсын тирән булып.
Үзе үлсә, эше калсын
Мең яшәрлек имән булып.

яшел чуклы юрган — *монда:* имән яфраклары
кавыштыра — күрештерә, очраштыра

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьдән кешенең тормыш максатын билгеләгән юлларны табып укыгыз.
2. Кешенең яшен шагыйрь нәрсә белән чагыштыра? Ни өчен имән агачын сайлый?
3. Бу шигыре белән автор нәрсә әйтергә тели?
4. Соңгы юлларның мәгънәсен ничек аңладыгыз?
5. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз, эчтәлеген сөйләгез.
6. Шигырьне ятлагыз.

КАТЫЙЛЬГӘ

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә;
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.
Меңен түгел, бары йөзен генә
Юк итәлдем синең сыңарның.
Һәм халкымнан, кайткач, шуның өчен
Мин тезләнеп гафу сорармын.

катыйль — палач
аягүрә — аякка баскан килеш

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Эчтәлеген сөйләгез.
2. Шагыйрь бу шигырен кемгә мөрәҗәгать итеп язган?
3. Куркусыз, батыр шагыйрь сезнең күз алдыгызга ничек булып килеп баса?
4. Шагыйрь ни өчен халкыннан гафу сорамакчы була?

ҖЫРЛАРЫМ

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе.
Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю —
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антыма.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны торткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

тойгы — уй, хис
керсез — саф, чиста
кабызу — яндыру
түбән ләззәт — *монда:* үзең өчен генә яшәү

Сорау һәм биремнәр

1. Дошманга каршы Муса Җәлил утлы корал белән генә түгел, шигырьләре белән дә көрәшә. Шул юлларны табып укыгыз һәм күчереп языгыз.
2. Шагыйрь *җыр* сүзенә нинди мәгънәләр салган?
3. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз һәм әчтәлеген сөйләгез.

Мәрьям Рахманкулова

(1901—1990)

Халык җырларын оста башкаручы җырчы, опера артисты Мәрьям Рахманкулова 40 елдан артык гомерен татар музыкасын үстерүгә багышлый. Аның бөтен тормышы, иҗат юлы — халык белән бергә яшәүнең, халыкка фидакарь хезмәт итүнең матур үрнәге.

Мәрьям Рахманкулова 1901 елның 23 ноябрендә Казанда туа. Рахманкуловларның күп балалы гаиләсендә музыка коралларында уйнау, бергәләп җырлау гадәти күренеш була. Мәрьямнең абыйсы Солтан мандолинада уйнаганда, аңа энеләре һәм сеңелләре дә кушыла — берсе скрипкага, икенчесе мандолинага, өченчесе гармун тавышына охшатып көйли башлый. Әйтерсең өйдә оркестр уйный. Бу йортка Габдулла Тукай да бик еш килә. Мәрьям аның шигырьләрен яттан укый, аңа «Зиләйлүк», «Анам кабере», «Туган тел» шигырьләрен көйләп, җырлап күрсәтә. Ул гомере буе Тукай шәхесен һәм аның иҗатын яратып яши.

Габдулла Тукай, халык иҗатының искиткеч кыйммәтле хәзинә булуын әйтеп, болай дип яза: «Халык җырлары бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале мирастыр... Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бер нәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска, иҗтиһат итәргә кирәк». Мәрьям Рахманкулова шагыйрьнең бу сүзләрен үзенә васыять итә.

М. Рахманкулова, әле бик яшь, бала гына булуына карамастан, алдынгы яшьләрнең әдәбият һәм музыка кичәләренә

җырларга чакырыла башлый. Зәңгәр күзле, сары чәчле, ак йөзле яшь кызның «Тәфтиләү», «Кара урман», «Тәзкирә», «Салкын чишмә» көйләрен җырлавы күпләрне сокландыра. Әнисе Мәрьямне кызлар мәктәбенә бирә. Кызлар мәктәбе мөдире Фатыйха Аитова тырыш, зирәк, акыллы укучы Мәрьямгә бик тиз игътибар итә, киләчәктә аны үз мәктәбенең мөгаллимәсе итәргә җыена. Ләкин Фатыйха Аитовага Мәрьямнең төрле кичәләрдә җырлавы әдәпсезлек булып тоела. Шуны сәбәп итеп, кызны мәктәптән читләштерә. Мәстүрә апаның күп тапкырлар ялварып үтенүләреннән соң гына Мәрьямгә яңадан мәктәпкә йөрергә рөхсәт ителә. Фатыйха ханым аның халык алдына чыгып җырлавын катгый тыя, кичләрен рус гимназиясе курсларына йөрергә куша. Мәрьям ике җирдә укый, өйдә калфак, каләпүшләр чигә. Ләкин күңеле һаман җырга, моңга тартыла. 1916 елның көзендә ул кызлар мәктәбеннән бөтенләйгә китә, яңадан җырлый башлый. Шушы елдан башлап, аның тормышы музыкага багышлана.

1930 елда М. Рахманкулова Мәскәүдә үткәрелгән сәнгать бәйрәмендә катнаша. Бу бәйрәмдә аның җырлавын беренче мәртәбә пластинкага язалар. Ул анда татар халык көйләрен һәм «Наемщик» музыкаль драмасыннан Гөлйөзем ариясен башкара.

1934—1938 елларда М. Рахманкулова Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый. Монда аның талантының моңарчы күрелмәгән тагын бер ягы — музыка язу сәләте ачыла. Ул композиция буенча да дәресләр ала, музыкаль әсәрләр иҗат итә башлый.

1939 елның 17 июне. Бу көн татар халкының мәдәният тарихына Татар опера һәм балет театры ачылу көне булып керде.

Шушы көннән башлап, М. Рахманкулова татар операсының җыр башкару белән уенны бергә оста бәйли белгән күренекле артисты булып танылa. Ул Нәҗип Җиһановның Әхмәт Фәйзи либреттосына язган «Качкын» операсында — Бикә, Муса Җәлил белән зур иҗади дуслыкта язылган «Алтынчәч»тә — Тугзак, Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендә — Җиһан, француз композиторы Ж. Бизеның «Кармен» операсында төп рольне — ирек сөючән, ялкынлы чегән кызы Карменны башкара.

Артист нинди генә образны гәүдәләндермәсен, аның геройларына уртак бер сыйфат: ягымлылык, эчке җылылык, зур кешелеклелек хас.

Татарстанның халык артисты Мәрьям Рахманкулованың татар музыка сәнгате өлкәсендә күрсәткән уңышлары халык ихтирамына һәм дәүләт бүләкләренә лаек була.

Мәрьям Рахманкулова 1990 елның 9 февралендә Казан шәһәрендә вафат була.

Зәйнәп Хәйруллинадан

Сораулар һәм бирем

1. Мәрьям Рахманкулованың җырчы булып китүенә кемнәр йогынты ясый?
2. Аның тормышында Г. Тукай нинди урын тота? Халык җырлары турында Тукай нәрсә дип әйткән? Шул юлларны табып укыгыз.
3. Мәрьям Рахманкулова тарафыннан зур осталык белән иҗат ителгән нинди образларны беләсез?
4. Мәрьям Рахманкулова белән бер чорда татар операсында эшләгән нинди артистларны һәм алар турында нәрсәләр беләсез?
5. Хәзерге татар опера җырчыларыннан кемнәрне беләсез? Алар башкаруында нинди арияләр исегездә калды?

Галия Кайбицкая
(1906—1993)

Галия Кайбицкая[1] (Төхфәтуллина) — татар музыка сәнгатен үстерүгә, татар опера сәнгатенә нигез салуга күп көч куйган күренекле шәхесләрнең берсе.

Ул 1906 елның 24 маенда Җаекта Мотыйгулла ахун гаиләсендә туа. Алдынгы фикерле Мотыйгулла үз балаларына һәм мәдрәсә шәкертләренә биергә, шигырь сөйләргә, җырларга рөхсәт бирә. Галия дә бик яшьли әтисеннән татарча һәм русча укырга-язарга өйрәнә.

Г. Тукай, Г. Кариев еш кына Галиянең абыйсы Камил Мотыйгый янына килеп йөриләр. Булачак җырчы шул рәвешле кечкенәдән мәшһүр шәхесләр белән аралашып үсә.

Галиянең әнисе Гыйззинас апа утыз елдан артык ире Мотыйгулла ахун салган мәдрәсәдә хатын-кызлар укыта. Ул, татар дөньясында беренче булып, татар хатын-кызлары хорын оештыра. Кечкенә Галия шул хорның танылган башкаручысына әверелә. Ә инде 1921 елда унбиш яшьлек Галия кече абыйсы Әдһәм һәм Камил Мотыйгыйның улы Хәмит оештырган татар театр труппасы спектакльләрендә катнаша башлый.

---

[1] Г. Кайбицкаяның әтисе Мотыйгулла тумышы белән Татарстанның Кече Кайбыч авылыннан була. Шуңа күрә Галия үзенә «Кайбицкая» тәхәллүсен ала.

Казан театр техникумында уку чорында Галия танылган драматург һәм режиссер Кәрим Тинчурин, композитор Салих Сәйдәшев, артист Ситдыйк Айдаровлар белән таныша. Алар кызның беренче остазлары булалар.

Г. Кайбицкая беренче мәртәбә Татар дәүләт академия театрында М. Фәйзинең «Галиябану» драмасыннан Галиябану ролен башкара. Соңга таба «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Наемщик», «Кандыр буе» музыкаль әсәрләрендә осталыгын арттыра.

Драматург Кәрим Тинчурин, композитор Салих Сәйдәшев һәм Галия Кайбицкая арасындагы дуслык искиткеч матур образлар тудыруга ярдәм итә. Сәйдәшев белән Кайбицкая мәңгелек иҗади дуслар булып китәләр.

1926 елда Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» спектаклен карагач, шагыйрь Һ. Такташ Г. Кайбицкаяның уйнавы турында: «Татар сәхнәсендә тагын бер йолдыз калыкты»,— ди. М. Җәлил дә, аның уенына сокланып, шигырь яза.

Еллар уза. Татар сәхнәсендә дә опера һәм балетка юл ачыла. 1934 елда П. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында Татар опера студиясе оеша. Шул ук елны Галия Кайбицкая, Салих Сәйдәшев, Ситдыйк Айдаров, Мәрьям Рахманкулова, Халидә Зәбирова, Усман Әлмиев, Мөнирә Булатова, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи һәм башкалар Мәскәүгә укырга китәләр. Г. Кайбицкая анда шагыйрь Муса Җәлил һәм рус операсы мәктәбе педагоглары белән таныша. 1938 елның 22 декабрендә, барлык фәннәрдән дә «биш»ле куелган таныклык алып, зур иҗат планнары белән Казанга кайта.

Г. Кайбицкая Н. Җиһановның «Качкын», М. Мозаффаровның «Галиябану», Д. Россининың «Фигаро туе» операларында үзәк партияләрне башкара. Опера театры ачылган көннән 1958 елга кадәр туктаусыз җырлап, «Севилья чәчтарашы»нда Розина, «Фауст»та Маргарита, «Риголетто»да Джильда, «Травиата»да Виолетта образларын иҗат итә.

Мәдәният өлкәсендә зур хезмәт күрсәтеп, халык мәхәббәтен казанган Галия Кайбицкаяга хөкүмәтебез 1939 елда Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исем бирә.

Г. Кайбицкая 1993 елның маенда Казан шәһәрендә вафат була.

Сораулар

1. Кайбицкаяның бала чагы кайда һәм нинди шартларда үтә? Ул кемнәр белән аралашып үсә?
2. Г. Кайбицкаяның гаиләсе турында нәрсәләр белдегез?
3. Җыр сәнгатенә, музыкага мәхәббәт тәрбияләүдә кемнәрнең тәэсире булган?
4. Артистның беренче остазлары кемнәр?
5. Ул нинди спектакльләрдә уйный?
6. М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында үзәк партияләрне башкаручы тагын нинди артистларны беләсез?

Харис Якупов

(1919 елда туган)

Күренекле рәссам Харис Якуповның картиналарында Татарстан тарихы һәм татар халкының бүгенге тормышы тирән эчтәлекле, югары идеяле һәм күпкырлы тасвирлана. Аның һәр әсәре халкыбыз тормышының яңа ягын, үзенчәлеген күрсәтә. Рәссам тормыш, тарих һәм кеше характерына фәлсәфи якын килә, картиналарның һәр штрихына, деталенә тирән мәгънә сала белә.

Харис Габдрахман улы Якупов 1919 елда Казанда туа. Мәктәптә укыганда ук, сынлы сәнгать студиясенә йөри, күргәзмәләрдә катнаша. «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында рәсемнәрен бастыра. 1940 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый.

1941—1945 еллардагы сугыш Харис өчен чыныгу һәм тормыш мәктәбе була. Разведчик, топограф, старшина Х. Якупов Мәскәү яны, Курск дугасы, Украина, Польша, Чехословакияне азат итү сугышларында катнаша. Анда да рәсем ясаудан туктамый.

Харис Якупов — портрет остасы. Ул ясаган Г. Тукай, А. Пешков, Ш. Камал портретлары аеруча уңышлы дип табыла.

«Габдулла Тукай крестьяннар арасында», «А. С. Пушкин Казан юлында», «А. М. Горький Марусовкада» (1946—1949) кебек картиналары тарихи темаларга багышланган.

Харис Якупов — пейзажчы да. Ул «Иделдә эссе көн», «Казанкада су ташу», «Кабан күле», «Иделдә яз», «Зур Идел» кебек зур полотнолар иҗат итә.

1950 елда Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов белән бергәләп, «В. И. Ленин Татарстан АССР төзү турындагы декретка кул куя» исемле зур картина яза. Бу картина өчен рәссамнарыбыз Харис Якупов һәм Лотфулла Фәттаховка СССРның Дәүләт премиясе бирелә.

1954 елда Харис Якупов җәмәгатьчелекне үзенең «Хөкем алдыннан» дигән атаклы картинасы белән таң калдыра. Картинада фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән каһарман шагыйрь Муса Җәлил сурәтләнә.

Харис Якупов китап графикасы өлкәсендә дә күп эшли. Ш. Камал, М. Гафури, К. Нәҗми, Җ. Тәрҗеманов, Ә. Фәйзи, Л. Ихсанова һ. б. язучыларның китапларына, татар халык иҗаты әсәрләренә рәсемнәр ясый.

Чит илләрдә йөрү башка халыкларның тормышын сурәтләгән әсәрләр туута сәбәп була. Кореяда, Италиядә булу Харис Якуповка яңа картиналар язу өчен өстәмә мәгълүмат бирә.

Харис Якупов, 1951 елдан башлап, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе булып эшли. 1974 елда СССР Сәнгать академиясенең әгъза-корреспонденты итеп сайлана.

1976 елда рәссамга И. Репин исемендәге премия, 1980 елда сәнгатьне үстерүдәге хезмәтләре өчен СССРның халык рәссамы дигән исем бирелә.

Сораулар һәм бирем

1. Харис Якупов кем ул?
2. Сез аның нинди әсәрләрен беләсез?
3. Харис Якупов иҗаты белән тулырак танышу өчен, музейларга, күргәзмәләргә барыгыз.

«Хөкем алдыннан» картинасы турында

Без, фронтовик рәссамнар, Бөек Ватан сугышы турында хәтердә калганнарга еш мөрәҗәгать итәбез. Мин солдат батырлыгына багышланган берничә әсәр иҗат иттем: «Елецны азат итү», «Төп көчләр керә», «Рәссам», «Фронт юллары...», «Минем полкташым», «Мария Щербак». Бу картиналар фронтта алган тәэсирләремә нигезләнеп язылды. Шуның белән бергә, кайбер картиналарым үзем катнашмаган вакыйгалар турында да иҗат ителде. Мәсәлән, «Михаил Девятаевның батырлыгы», «Хөкем алдыннан» картиналары. «Хөкем

алдыннан» картинасы каһарман шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган.

Муса Җәлилне мин шәхсән белмим. Дөрес, ул сугышка кадәр сәнгать кешеләре белән без укый торган 13 нче мәктәпкә килгән иде. Әмма аның образы минем хәтердә сакланмаган.

1950 еллар башында без шагыйрьнең якын дусты композитор Н. Җиһанов белән очраштык. Алар бергә «Алтынчәч» операсын язганнар. Ул миңа Җәлил турында картина язарга тәкъдим итте, ә үзенең «Шагыйрь» дигән опера язачагын әйтте.

Шулай итеп мин «Хөкем алдыннан» картинасын эшли башладым. Ул вакытта әле фашистлар тылында эшләгән Җәлил һәм җәлилчеләрнең яшерен группасы акланмаган булуы картинаны эшләүдә кайбер кыенлыклар тудырып, хәтта саграк эш итү сорала иде.

Мин ул чакта булачак әсәремнең герое турында нәрсә белә идем соң? Ул Волхов фронтында каты яраланган килеш фашистларга әсир булып төшкән һәм аларга каршы эшчәнлеге өчен җәзалап үтерелгән. Яшерен оешмадагы дусларының гильотинада башлары киселгән. Эскизларны эшләү барышында, шагыйрьнең фронттагы тормышына артык игътибар итмичә, Җәлилдән сорау алу вакытына тукталдым. Миңа нәкъ менә шунда каршылыклы хәл тудыру өчен мөмкинлекләр бар кебек тоелды. Шулай итеп, шагыйрьне фашист башкисәрләре арасында сурәтләргә булдым.

Караңгы төрмә бүлмәсе. Диварда фюрер портреты, тәреле әләм, тоткыннар турындагы мәгълүматлар урнаштырылган шкаф, алгы планда хәтәр һәм үз-үзенә ышанган генерал, ә аның артында бераз иелгән тәрҗемәче. Өстәл янында телефоннан сөйләшеп утыручы — тикшерүче. Кабинетның караңгырак ягында эзәрлекләүләргә әзерләнүче тагын бер палач. Шул фонда дошманнар оясында кыю һәм рухы сынмаган шагыйрь басып тора. Рәссам өчен аның героеның тышкы кыяфәтен бирү бик мөһим. Бу турыда Җәлилне күреп белгән кешеләрдән ныклап сораштым. Мин шагыйрьне мәһабәт сынлы, фашистлардан өстен итеп, зур планда бирдем. Җәлилнең йөзен Әминә ханымнан алган фотолар буенча яздым. Аны сакал-мыек үскән каратут йөзле, сызылып киткән озын кашлы, очкын чәчеп торган күзле, яндырып ала торган карашлы итеп ясадым. Өстенә гимнастерка һәм окопларда таушалган фрон-

товиклар телогрейкасы кидердем. Муенына әсир икәнлеген күрсәткән билге элдем. Җәлилне хәрби әсир түгел, ә сәяси әсир буларак хөкем иткәннәр. Ихтимал, ул төрмә халатында яки гади киемдә булгандыр. Ә мин тоткынны хәрби киемдә бирдем, чөнки ул — сугышчы һәм фашистлар тоткынлыгына да хәрби әсир буларак килеп эләккән. Безнең сугышчының фашистлардан әхлакый өстенлеген һәм аның характер нык-лыгын күрсәтәсем килде. Картинадагы образ шагыйрьнең:

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә;
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә,—

дигән шигъри юллары белән аваздаш булырга тиеш.

Ике елдан «Хөкем алдыннан» картинасы эшләнеп бетте. 1954 елда ул Бөтенсоюз күргәзмәсенең Третьяков галереясына куелды һәм халык тарафыннан бик җылы кабул ителде.

Ул вакытта Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелмәгән һәм «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясенә тәкъдим ителмәгән иде әле. Минем Ватан сугышы чорында фашистларга каршы көрәштә үлемсез батырлыклар эшләгән, кыю, милли каһарман образын сурәтлисем килде, һәм максатыма ирештем.

Хәзер «Хөкем алдыннан» картинасы Татарстан Сынлы сәнгать музеена куелган.

Харис Якупов истәлекләреннән

Бирем

Харис Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы турында сөйләгез.

Габдрахман Әпсәләмов

(1911—1979)

Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов 1911 елның 28 декабрендә хәзерге Мордва Республикасының Иске Аллагол авылында туа.

Г. Әпсәләмов әдәби иҗат эше белән бик иртә мавыга башлый. 4 нче сыйныфта укыганда, беренче шигырьләрен яза. Арадан берсе Муса Җәлил редакторлык иткән «Октябрь баласы» журналында басыла. Г. Әпсәләмовның язучы булып китүенә Муса Җәлилнең йогынтысы зур була. Габдрахман Муса Җәлил җитәкләгән әдәби түгәрәккә йөри. Шул чагында беренче хикәяләрен, сәхнә әсәрләрен яза. Аның тәкъдиме белән М. Горький исемендәге әдәбият институтында укый. 1941—1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Иҗат эшчәнлеге дә чын-чынлап шушы елларда башлана.

Бу чорда язылган әсәрләрендә әдип сугыштагы батырлыкны сурәтләсә, аннан соң иҗат ителгән романнарында күбрәк әлеге батырлыкның чыганакларын ачыклау белән кызыксына. «Алтын Йолдыз» (1948) — шундый романнарның берсе.

1951 елда Г. Әпсәләмов татар халкының батыр улы Газинур Гафиятуллин истәлегенә «Газинур» романын яза. Укучылар бу әсәрне яратып укыйлар.

Язучының Бөек Ватан сугышы чоры вакыйгаларына нигезләнеп язылган өченче романы «Мәңгелек кеше» дип атала. Анда Бухенвальд үлем лагеренда булган хәлләр тасвирлана. Халкыбызның кыю йөрәкле улы Бакый Назимовның фашист тоткынлыгындагы көрәше күрсәтелә.

Сугыш турында романнар, повестьлар язганнан соң, язучы бүгенге тормышны сурәтләүгә күчә. 1958 елда аның Казан

шәһәре кешеләре турында «Сүнмәс утлар» романы басылып чыга. Бу роман өчен Г. Әпсәләмовка Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. Аннан соң бер-ике ел да узмый, язучы медицина хезмәткәрләре турында «Ак чәчәкләр» исемле яңа романын төгәлли. Әбүзәр Таһиров, Гөлшәһидә образларын укучылар бик яратты. Габдрахман Әпсәләмов шигыренә Җәүдәт Фәйзи язган «Гөлшәһидә» җыры хәзер дә яңгырый.

«Ак чәчәкләр»дән соң Габдрахман Әпсәләмов укытучылар хезмәтен һәм тормышын яктырткан «Яшел яр» исемле яңа роман иҗат итә, бик күп мәкаләләр, хикәя, повестьлар яза.

«Агыла болыт» романы Муса Җәлилгә һәм каһарман шагыйрьнең намуслы исемен кире кайтаруга зур көч куйган галим Гази Кашшафка багышлана.

Габдрахман Әпсәләмов, озакка сузылган авырудан соң, 1979 елның 7 февралендә Казан шәһәрендә вафат була.

«Ак чәчәкләр» романы турында

Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы кеше турында кайгыртучанлык, кешелеклелек фикерләре һәм хисләре белән сугарылган. Романның үзәгендә һәрвакыт ярдәм кулы сузучы, ак күңелле кеше образлары тора. Әсәрнең лирик исеме дә шуны аңлата: тереклек һәм бәхет билгесе булган ак чәчәкләр! Романда ак халатлы кешеләр — медицина хезмәткәрләре дөньясы һәм аларга өмет, ышаныч, хөрмәт белән караучы авырулар дөньясы ачыла. Бу романда табибларның халык каршында җаваплылыгы, рухи гүзәллеге турында сөйләнә. Әсәрнең үзәгендә — күпне күргән, күпне башыннан кичергән атаклы профессор Әбүзәр Таһиров. Ул Тукай, Ямашевларны күргән, халык арасында яшәп, гади табибтан атаклы профессор дәрәҗәсенә үскән. Әбүзәр абзыйның тормышы һәм эше әсәрдә киң итеп бирелә. Аның өчен халыкка намус белән хезмәт итүдән дә изгерәк бурыч юк. Әбүзәр абзый — гаиләдә дә, эштә дә олы җанлы, миһербанлы, рухи яктан матур кеше.

Әсәрнең башыннан ахырына кадәр карт профессорның иң яраткан укучысы Гөлшәһидәнең мәхәббәт тарихы тасвирлана.

«Ак чәчәкләр» романы авторның шифаханәдә авырып ятканда күргәннәренә нигезләнеп языла.

АК ЧӘЧӘКЛӘР

(өзекләр)

Беренче бүлек

IV

Профессор Әбүзәр Таһиров Казанда йөрәк авырулары буенча иң зур белгечләрнең берсе санала. Аңа күренер өчен төрле шәһәрләрдән һәм авыллардан йөзләрчә кешеләр килә. Халык арасында аның абруе, дан-шөһрәте бик зур. Аның ягымлы, игътибарлы булуы һәм сәләте турында хәтта легендалар йөри. Гаҗәп тә түгел. Ул — татарлардан беренче врачларның берсе, әле мең тугыз йөз унберенче елда ук Казан университетының медицина факультетын тәмамлаган, Казанда һәм Казан губернасында исеме аеруча билгеле булган мәшһүр медик Казембекның һәм башка Казан профессорларының иң сәләтле шәкертләреннән берсе. Шуның өстенә аның озын гомерле булуы, бик озак еллар гел татарлар арасында эшләве дә аны халык каршында югары күтәргән. «Әбүзәр абзый әле безнең бабайны да яки әткәйне, әнкәйне дә дәвалаган» дип сөйләүчеләр аз түгел иде. Аны еш кына «Мәңгелек доктор» диләр. Аннары Татарстанда һәм күрше республикаларда аның меңләгән шәкертләре эшли. Алар да остазларының данын күтәрәләр, билгеле. Ниһаять, аның бик зур җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе булуы, дөньякүләм фәнни конференцияләрдә, конгрессларда катнашуы, анда докладлар ясавы, халык арасында әледән-әле лекцияләр укуы, матбугат битләрендә әледән-әле мәкаләләре чыгуы, радиода, телевизорда ясаган чыгышлары да аның абруен халык каршында бик югары күтәргән иде.

Әбүзәр абзыйның әтисе Гәрәй исемле булган. Ләкин бу исем рус дөньясына Пушкиннар аркылы «Гирей» булып кергәнгә, Әбүзәр абзый әле гимназиядә чакта ук әтисенең исемен «Гирей» дип язган. Соңыннан руслар гына түгел, татарлар да аны «Әбүзәр Гиреевич» дип йөри башлаганнар.

Кичәге борчылулар, күрәсең, аңа нык тәэсир иткән, больницага килеп кергәндә, аның йөзе шактый суырылган иде. Ләкин һәрвакыттагыча пөхтә һәм ягымлы иде. Гадәтенчә, очраган бер кешесе белән, аның врач, сестра яки гади бер санитарка булуына карамастан, ихтирам күрсәтеп исәнләште, авыруларның хәлләрен сорашты һәм үзенә хас омтылышлы,

эшлекле йөреше белән кабинетына юнәлде. Кергәч тә, иң элек тәрәзәдән гөлҗимеш куагына күз салды. Кичә кич буе алар Аксюша түти белән Галина Петровна турында сөйләшеп утырдылар. Хәзер дә уенда гел ул гына иде. Ләкин аның күз алдында һаман шул үзе белгән, актык мәртәбә партизаннар лагеренда саубуллашкан чагындагы Галина Петровна басып тора. Әбүзәр абзый Зур җиргә очып киткәндә, Галина Петровна, иңенә җылы шәл салып, аны самолет янына кадәр озата килде. Ябык йөзенә кырыс сызыклар яткан мөлаем рус хатыны. Агара башлаган коңгырт чәч, куе зәңгәр күзләр, тыйнак сабырлык...

Галина Петровнаны ул башкача итеп, бигрәк тә боегып, моңланып кичке шәфәкъкә карап утырган авыру итеп уйлый алмый иде. Шулай да инде кичәдән бирле аның күңелен ачы үкенү сызлата. Аерылышканда онытмам дип биргән вәгъдә антлары кайда? Әгәр изге җан Аксюша түти килеп әйтмәсә... Үкенечле эш эшләгәннән соң, вөҗданга аклану юк инде ул, юк!

Каты авыру кешене мәшәкатьле озын юлга чыгару бик хәтәр булса да, Әбүзәр абзый, озак уйланганнан соң, Галина Петровнаны Казанга алдырырга карар итте. Бүген кич белән Аксинья Алексеевна юлга чыгарга тиеш.

Профессор уйланып торган арада, кабинетка Вера Павловна белән дәвалаучы врач Маһирә ханым Бариева килеп керделәр.

Бүген профессорның консультация көне иде. Ул сәгатенә карап алды да:

— Башлыйк,— диде.— Маһирә ханым, сез нинди кыз турында әйткән идегез әле?

— Ул монда, Әбүзәр Гиреевич, көтеп тора. Унтугыз яшьлек кыз, студентка.

— Йөрәк?

— Комбинированный порок. Моңарчы да больницаларда яткан, ләкин дәвалану уңай нәтиҗә бирмәгән.

— Керсен.

Профессор, урыныннан торып, ишектән килеп кергән кызга каршы атлады.

— Рәхим итегез, менә монда утырыгыз,— диде ул, ишектән юри шактый ерак куелган урындыкка күрсәтеп, үзе кызның ничек килеп керүен, аяк атлауларын, хәрәкәтләрен, чыраен күзәтте.— Тартынмагыз, иплән утырыгыз. Менә

шулай.— Үзе дә, урындык алып килеп, кызга каршы утырды.—Исемегез ничек?

— Асия.

— Я Асия, күзне яратасызмы?

Бу сәер сорауга кыз башын селкеп кенә җавап кайтарды.

— Ә без, картлар, киресенчә, күзне яратабыз. Күз —муллык. Кеше үзенең хезмәт җимешен җыя. Ә яз — чәчәк кенә әле.— Профессор бер Асиягә, бер өстәл янына барып утырган Вера Павловна белән Мәһирә ханымга карап, елмаеп куйды. Якты, ягымлы һәм үзенә тарта торган иде аның елмаюы.— Я Асия, сөйләгез, нәрсә борчый сезне?

— Бераз авырдым әле менә,— диде Асия, аска карап.

Чынында исә аның тормышы көннән-көн көчәя барган бетмәс-төкәнмәс зәһәр приступлардан гына тора иде. Приступ башландымы, бөтен тәнен коточкыч көзән җыера, арка, йөрәк сызлавына чыдар хәл калмый, әйтерсең, ит турагыч аркылы үткәреп, барлык сөякләрен берәм-берәм сындыралар, суларына һава җитми, буыла, кул-аяклары салкыная, йөзе кәфен төсенә кереп, иреннәре күм-күк була, күзләре атылып чыгарга җитешә. Бернинди уколларның да, эчкән даруларның да файдасы тими. Кайчак бу сызланулар атналар буена сузыла һәм бары тик тагын да зәһәрләнә төшеп яңадан башланыр өчен генә беразга басылып тора.

Әле Асиянең ишек төбендә ничек басып торуы, ничек аяк атлаулары, урындыкка ничек килеп утыруы, ничек сулыш алуларыннан ук профессор бу кызның ни дәрәҗәдә авыруын чамалап алды. Ләкин, гадәтенчә, нәтиҗә ясарга ашыкмады. Һәр чирнең үз төрләре бар, шуның өстенә һәр организм үзенчә генә, әйе, фәкать үзенчә генә авырый. Ә чирнең индивидуаль үзенчәлеген бары тик авыруның үзеннән сөйләтеп кенә ачыкларга мөмкин. Кайберәүләр, хәзерге заманда иң мөһиме — анализлар, диагноз куючы машиналар, диләр. Ләкин профессор Таһиров, нинди генә акыллы машина булмасын, ул һичбер вакытта да врачның фикер йөртүен алмаштыра алмый, дип уйлый иде.

Профессор бик гади генә сораулар бирде. Кыз, теләсә-теләмәсә дә, аларга ачык җавап кайтарырга мәҗбүр иде.

— Бала чакта малайлар белән уйный идегезме, Асия?

— Уйнамаган кая!

— Үртиләр идеме?

— Малайлар булсыннар да үртәмәсеннәр.

— Кем дип үртиләр иде?

— Чеби Асия...

— Ә мороженое яратасызмы? — дип елмайды профессор.

— Аны кем яратмый.

— Ә тамак? Авыртмыймы?

— Авыртса, әнкәй кайнар сөт эчерә.

— Димәк, ангина белән еш авырыйсыз. Ә театрга еш йөрисезме, Асия?

— Театрга да йөрмәгәч...

— Әлбәттә, капрон оек киеп. Шулаймы? Кыш көне дә?

— Авыл кызлары кебек йон оекбаш киеп бармам инде.

— Аяклар сызлыймы?

— Анысына гына түзәр идем...

Профессор аның аяк, кул буыннарын карады да:

— Температура еш буламы? — дип сорады.

— Әнкәй гел янасың, пешәсең дип әрли.

Профессорның аз гына уйга калуы булды, Асия үзе сораулар яудыра башлады. Аннары кесәсеннән бер төргәк кәгазь чыгарды.

Профессор кыз сузган кәгазьләрне алмады.

— Мин, Асия, кәгазьләр дәваларга җыенмыйм. Алар миңа әллә ни әйтмәс. Ә менә үзегез, теләсәгез, күп нәрсә әйтә аласыз. Тереләм дигән кеше генә терелә бит. Әле борынгы заманда бер көнчыгыш врачы бер авыруга болай дигән: «Без өчәү: син, мин һәм чир. Әгәр без синең белән икәү бер яклы булсак, бер чирне ничек тә җиңәрбез». Төшендегезме? — дип, йомшак кына сорады профессор. Ул каты борчылган, курыккан, кимсетелгән, Алла иркеннән мәхрүм ителү, кеше кулына калу кебек үтә күңелсез нәрсәләрне генә көткән кызны тынычландыру юлларын эзли иде.

остаз — укытучы, эшкә өйрәтүче

шәфәкъ — офыкта кояш баеганнан соң барлыкка килә торган кызыллык

үкенеч — беркайчан да кире кайтарып булмаган нәрсәләр турында кайгыру, борчылу хисе

сәер — гаҗәп

буын — кеше организмында сөяк-сеңерләр тоташкан хәрәкәтчән, бөгелә торган урын

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен профессор Әбүзәр Таһировның халык арасында абруе зур?
2. Аның авырулар белән мөнәсәбәте ничек?
3. *Авыру, дан, ягымлы, вөҗдан* сүзләренә, өзектән файдаланып, синонимнар табыгыз.
4. Өзекнең эчтәлеген сөйләүне кара-каршы сөйләшү (диалог) формасында оештырыгыз.

Өченче бүлек

VII

Акъярга кайтып төшүе белән үк, Гөлшәһидәнең өстенә мең төрле мәшәкать өелде. Казанда чакта онытылып торган баш врач эшләре: дебет-кредит, смета һәм түләү ведомосте, утын, аш-су, кер юу, ремонт хәстәрләре кебек нәрсәләр яңадан аның башына тулды. Дарулар алып кайтырга кирәк, больница бакчасын куяннардан, кәҗәләрдән, тычканнардан саклау чараларын күрергә кирәк, авыруларны карарга кирәк. Җитмәсә, грипп эпидемиясе булу сәбәпле, больница авырулар белән тулган, Гөлшәһидә аларны урнаштырырга урын таба алмыйча тәмам алҗып бетте. Элек тә ул Акъяр больницасының искелегенә, кысанлыгына бик борчыла иде, шәһәрдәге зур больницадан соң мондагы тарлык аны аеруча әрнетте. Шуңа күрә, кайткан көнне үк диярлек, район оешмалары каршында яңа больница салу мәсьәләсен кискен рәвештә кабат куйды. Җитәр инде, еллар буе вәгъдә белән генә борып кайтармагыз, диде. Ләкин яңа больница — яңа бина гына түгел: аның янына рентген аппараты, лаборатория, телефон кирәк, электр белән дәвалану җиһазлары кирәк... Әлбәттә, Гөлшәһидә районның чамасын белә иде, шуңа күрә министрга да язды, Акъяр колхозына өлкә комитеты секретаре белән Совмин председателе килгәнен ишеткәч, идарәгә чабып, аларны да больницага алып килеп күрсәтте. «Менә карагыз: нинди шартларда эшлибез»,— диде, төзү материаллары даулады.

— Материалы булса, салу эшен җәмәгать тәртибендә дә оештырыр идек,— диде.

Кайтуы белән, аны җәмәгать эшләренә дә ныклап җиктеләр. Клубта, китапханәдә санитария-гигиена турында лекцияләр укыды, авыруларга өйдә ярдәм күрсәтү түгәрәгенең бүленеп торган эшен җайга салды, сыер савучы ферма кызларын

үз кулларына массаж һәм ванна ясарга өйрәтте, звено, бригада җитәкчеләре өчен оештырылган уку түгәрәген алып баруны да яңадан аңа йөкләделәр, хәтта үзешчәннәр түгәрәгенә дә чакырдылар. Кыскасы, Казандагы кебек күңел кичерешләренә чумарга түгел, тын алырга да вакыты калмады. Соңгы көннәрдә больницадан да чыкмады. Грипп белән авыручы механизатор Исмәтнең хәле бик авыраеп китте. Бик күпләр кебек, Исмәт тә гриппны аяк өсте генә уздырмакчы булган, аңа кул селтәп караган. Ә хәзер, дүртенче көн инде, ут эчендә саташып ята, температурасы кырыктан узган... үч иткән кебек, кофеин да беткән чак иде. Аны районнан алып кайтуларын Гөлшәһидә дүрт күз белән көтте. Әһлетдин абзыйның ат белән капкадан кайтып керүен күргәч, иңенә шәл генә салып, аңа каршы йөгереп чыкты. Биш-ун минуттан ул Исмәткә кофеин белән камфара уколы ясады. Бераздан Исмәт тирән йокыга талды. Гөлшәһидә соңгы дүрт тәүлектә беренче тапкыр урындыкка утырып җиңел сулыш алды.

Өенә Гөлшәһидә караңгы төшкәч кенә, тәмам карга батып, күчән кебек катып кайтты. Аның шәлен чишәрлек тә хәле калмаган иде. Сәхипҗамал җиңгәсе, аны баштанаяк карга чумган килеш ишек төбендә күргәч, ике кулын чапты да тиз генә янына килеп шәлен чиште, төймәләрен ычкындырды, киез итекләрен салдырды.

— Бичарам, ник ат җиктермәдең, шундый буранда җәяү кайталармыни?! — диде ул, Гөлшәһидәне чын күңелдән кызганып.

Гөлшәһидә идәндә эреп барган кар кисәкләренә карап торды да кулларын җылы мичкә терәде һәм, сызлавына түзә алмыйча, шунда ук кире тартып алды. Күзләреннән яшь бәреп чыкты.

— Угала, угала кулларыңны,— диде Сәхипҗамал җиңгәсе.— Ничә әйттем, ки авыл бияләен, дип, юк бит, шәһәр пирчәткәсеннән йөргән буласың көязләнеп.

Берничә минуттан бармакларының сызлавы туктады. Гөлшәһидә яңадан аларны җылы мичкә терәде.

— Бичаракаем, кулсыз калуың мөмкин бит. Атыгыз була торып....

— Әһлетдин бабай яңа гына районнан кайтты, бик арыган иде, кызгандым,— диде Гөлшәһидә.

— Син барысын да кызганасың, ә үзеңне кызганучы бармы соң? Әнә Питәнәй Якубның хатынын шундый салкында

районга ук алып баргансың. Үзен генә җибәрсәң, район больницасын тапмас идемени?

Гөлшәһидә кулларын мичкә бер терәп, бер алып Питәнәй Якуб хатыны Нурлыгаян апа турында уйлады. Казаннан кайтып төшкән көнне үк ул больницага килде, тыным кысыла, йөткерәм, дип зарланды. Андый гына нәрсәләрдән кем зарланмый, Гөлшәһидә аңа салкын тигәннән дарулар биреп кайтарды. Даруларның файдасы булмагач, ул аны больницага салырга мәҗбүр булды. Үзе тикшереп, үзе сынап белгән дарулар белән дәвалап карады, ләкин алай да файдасы күренмәде. Нурлыгаян һаман йөткерде, һаман күкрәге кысылудан зарланды. Шуннан Гөлшәһидә, борчылып, аны район больницасына рентгенга алып барды һәм авыруны рентгенолог белән бергә үзе карады. Үпкәләренең тамыр төпләре карала башлаган иде! Бик борчылып, районнан ук Казанга шалтыратты. Бәхеткә, Әбүзәр абзый больницада туры килде. Ул онколог чакырырга киңәш итте. Шулай ук ракмы икәнни? Хәзер Гөлшәһидә түземсезлек белән белгечне көтә иде.

Гөлшәһидә уйланып торган арада, батист яулыгын колак артына кысып бәйләгән җиңел сөякле Сәхипҗамал җиңги олы як белән кече як арасында җил-җил йөреп табын әзерләргә кереште: әле колагындагы тамчылы алкалары җем-җем итеп китә, әле бала итәкле чуар күлмәге җилфердәп кала, ә ак йон оекбаш кигән аяклары идәнгә тавыш-тынсыз басалар. Тышта баягыдан да яманрак булып буран котыра. Җил тәрәзә капкачларын каерып атарга теләгәндәй шакылдата, морҗа да елый-елый сызгыра. Әйдә, хәзер теләгәнчә сызгыра, котырына бирсен. Өй эче җылы, электр уты балкып яна.

Сәхипҗамал җиңги өстәлгә шаулап торган самовар китереп куйды.

— Чәй эч тә мич башына менеп ят,— диде ул.

Гөлшәһидә, иркәләнеп, башын чайкап алды.

— Хәзердән үк мич башына менеп ята башласам, картайгач нишләрмен икән, җиңгәм? — дип, Сәхипҗамалны муеныннан кочып алды.— Исмәт йоклап калды, әй шатланганымны белсәң иде, җиңгәм!— диде Гөлшәһидә чәй эчкән чагында.— Бу бит авыруның терелә башлавы инде.— Һәм бераз тыңлап торгач:— Әллә җил басыла төште инде? — дип сорады.

— Кичкә таба башланган буран алай тиз туктамый,— диде Сәхипҗамал һәм, тагын бер чынаяк чәй ясап, Гөлшәһидәгә

сузды,— эчеп җибәр әле тагын,— һәм, Гөлшәһиданең өстәл яныннан торып каядыр җыена башлавын күреп:— Бәрәч, син тагы кая бармакчы буласың?—дип сорады.— Мондый төндә яхшы кешенең эте дә урамга чыкмый.

— Көнбагыш Нәгъмәтҗан абзыйның хәле авыр дип әйткәннәр иде.

— Кем әйтте? Чакыра килгәннәр идеме?

— Чакыруын чакырмадылар да... Барып хәлен белим.

— Иртән барырсың. Ул бит җәһәннәм тишегендә тора.

— Иртәнгә хәтле тормавы мөмкин аның... Актык минутында врач килмәде дип рәнҗеп калмасын инде.

— Барыбер әҗәл даруың юк бит,— диде ни әйтергә белмәгән Сәхипҗамал җиңги.

— Булмаса да барыйм, җиңгәм. Бәлки, күңеленә аз гына җиңелрәк булып китәр. Кеше бит ул...

Сәхипҗамал җиңги көрсенеп куйды, мич башыннан җылы киез итекләрен алып Гөлшәһидәгә бирде, аннары шәле белән бияләйләрен дә сузды.

— Әллә үзем озата барыймы, җаным? Бик ерак бит, адаша күрмә.— Гөлшәһидә каршы килгәч.— Ичмасам, кайтканда берәрсе озата килсен үзеңне. Нефтедәге малайлары кайткан дип ишеттем,— диде.

Тышка чыккач, капка баганасына сөялеп, Гөлшәһидә бермәл аптырап басып торды. Котырынган буранда берни күренми иде. Бая юл әзрәк беленә иде әле, хәзер бөтен җирдә кар көртләре генә.

Күзләре караңгыга ияләшә төшкәч, Гөлшәһидә, карга батачума юлга чыгып, җилгә ян белән борылып, утлары беленер-беленмәс кенә шәйләнгән урам буйлап китте.

Берничә урында буран урам аркылы шундый биек көртләр өйгән, Гөлшәһидә аларны көч-хәл белән генә ерып чыга алды. Киез итекләре, бияләйләре эченә кар тулды. Ләкин аштан соң ул өшемәде, киресенчә, аңа эссе булып китте.

Ниһаять, ул Нигъмәтҗан абзыйларның тәрәзә капкачын шакыды. Тәрәзә ярыгыннан ут күренә иде. Эт өрә башлады. Аннары капка артында ир кеше тавышы ишетелде:

— Кем ул?

— Мин, доктор,— диде Гөлшәһидә.

Өйалдында Гөлшәһидә өстендәге, аякларындагы карны каккалый-каккалый:

— Нигъмәтҗан абзыйның хәле ничек? — дип сорады.

Әтисе кебек сары чәчле, киң, таза җилкәле егет аңа астан гына карап:

— Ята,— диде.

Доктор килүгә ул аз гына да шатланмады шикелле. Аның каравы Нигъмәтҗан абзый үзе, Гөлшәһидәне күргәч, елап ук җибәрде.

— Килерсең дип көткән идем шул... Рәхмәт, кызым,— диде әкрен тавыш белән.— Бүгенге төнне үткәрә алсам, шаять, терелермен дип өметләнәм әле. Син килгәч, әйе...

Гөлшәһидә аңа дару эчерде, укол кадады, байтак вакыт аның янында утырды. Авыру ишек төбендәге караватта ята. Салкын. Караңгы гына ут яна. Мич кырыенда салам өстендә чуар бозау. Киленнәре белән оныклары барысы да түр якта. Малае да шунда кереп китте. Берсе дә чыгып карамады. «Әтиләреннән туйганнар!»— дип әрнеп уйлады Гөлшәһидә. Ә картның, күп булса, берничә сәгатьлек гомере калган.

— Хәзер күкрәкләрем тәмам ачылып киткәндәй булды,— диде авыру, докторга рәхмәт укып.— Сулыш алуларым да җиңеләйде. Иртәгә инде, боерган булса, больницаңа алырсың мине... Хәзер, сеңлем, кайтсаң да ярый. Тәмам хәл керде үземә. Югыйсә әҗәлем җитте дип тора идем.

Гөлшәһидә аңа тыныч төн теләде, иртән тагын килермен, диде. Авыру аңа мең рәхмәт укып калды, ә җирән егет, Гөлшәһидәнең юри кычкырып саубуллашуына да карамастан, хәтта озата да чыкмады.

Гөлшәһидә карга батып кайтып кергәндә, Сәхипҗамал җиңги йокламыйча ут йотып утыра иде. Гөлшәһидәне исәнсау күргәч, и шатланды, и сөенде, нинди генә сүзләр белән иркәләмәде.

— Бик арыдым, җиңгәм, йоклыйсым килә,— диде Гөлшәһидә һәм утырган җирендә үк йоклап китте.

Иртә белән Көнбагыш Нигъмәтҗанның үлгәнлеген әйттеләр. Ә ике көннән соң Казаннан онколог килде һәм, Нурлыгаян апаны карагач, башын селкеп куйды:

— Шул каһәр суккан... Казанга операциягә озатырга кирәк, Гөлшәһидә ханым. Кичекмәстән.

Авыруның үзенә, әлбәттә, дөресен әйтмәделәр, әмма иренә турысын аңлаттылар. Илле икеләр тирәсендәге Якуб абзый, бу шомлы хәбәрне ишеткәч, телсез калды, ышанып та бетмәде. Алай сырхаулап та йөрмәде бит. Кем йөткерми дә, кемнең тыны кысылмый. Ниһаять, ул аңлады, ахрысы.

— Сезнең сүзне, Гөлшәһидә сеңел, тыңламый булдыра алмыйм. Казаннан килгән иптәш тә әйткәч... Кайчан юлга чыгарга?

— Иртәгә үк кирәк булыр, Якуб абзый... Берүк Нурлыгаян апаның үзенә, зинһар, әйтә күрмәгез. Операция кирәклеген без дә әйтербез, сез дә җайлап кына әйтерсез, яме... Казанда аны иң яхшы врачлар караячак, үзем барысына хатлар язармын.

мәшәкать — тыныччлыкны бетерә, бөтен игътибарны таләп итә торган эш
кискен — хәлиткеч, бик каты, киеренке
йөкләү — нинди дә булса эш эшләргә, йомыш үтәргә кушу

Сораулар һәм бирем

1. Гөлшәһидәне авыл халкы ни өчен ярата?
2. Гөлшәһидә авырулар турында ничек кайгырта?
3. Кеше тормышын саклап калу өчен, ул ниләр эшли?
4. Гөлшәһидә үз һөнәрен яратамы? Шул турыда сөйләгез.
5. Сезнеңчә, табиб булу өчен нинди сыйфатларга ия булу кирәк?

Дүртенче бүлек

V

Бүген Гөлшәһидә бүлегенә гипертониядән җәфа чигүче бер картны салдылар. Гипертония картларда була торган авыру инде. Бүгенге обходы беткән булса да, Гөлшәһидә, култык астына Риво-Роччи аппаратын кыстырып, карт янына китте. Ул палатага барып кергәндә, авыру тәрәзә буендагы караватта ята иде. Тышта кояшлы салкын көн, өй түбәләре ап-ак. Морҗалардан төтеннәр туп-туры өскә күтәреләләр. Күрәсең, җил басылган. Иртән эшкә килгәндә, ул шактый көчле иде.

— Исәнмесез, бабай? — диде Гөлшәһидә, яңа авыру янына утырып һәм шунда ук чәчәк сатучы картны таныды.— Авырып киттегезмени, Мортаза бабай?

Карт кулын каш өстенә куйды.

— Әллә күргән кешем инде?

— Былтырлары мин сездән чәчәк сатып ала торган идем.

— Һай, парин! Кемне танымыйм! Исән-саумы соң, кызым? — Карт ике кулын сузды.— Күрешик. Озак күренми тордың. Мин берәр җиргә киткәнсең дип уйлаган идем.

— Авылда эшләдем.

— Ие шул, авылныкы дип әйткән идең шул.

— Кай төшең авырта, бабай?

— Шул тыпыр-тыпыртай инде миндә, кызым. Менә җилкә чокыры астыннан баш сөягенә казык очы белән төртеп торалар кебек. Баш, уйлы кешенеке төсле, гел аска тарта, ком тутырган кебек авыр, җитмәсә. Күз аллары, сөремле мунчадан чыккандагыча, әлҗе-мөлҗе килә. Күңел дә болгана. Аяк атлауларым исерек кешенеке төсле чалыш-чолыш.

— Сездә бу авыру булмаска тиеш, Мортаза бабай. Сез бакчачы, гел саф һавада.

Мортаза бабайның чырае караңгыланып китте.

— И кызым,— диде.— Мортаза бабаңның бакчасыннан җилләр исте инде. Бәлки, авыруымның башы да шуннан булгандыр. Анысын тәгаен генә әйтеп бирә алмыйм.

— Әллә яңа йортка күчтегезме?

— Күчсәк, үкенече дә булмас иде. Югыйсә...—Карт тамырлары бүртеп торган кулын хәлсез генә селтәде.— Югыйсә бер юньсез пирсон аркасында...

— Нинди пирсон?

— Бар безнең күршедә шундый бер аша чыккан бдительный пирсон. Гомере буе бер рәтле эш эшләмичә бдительный булып йөрде. Пенсионерларның күбесе картлык көннәрендә дә халыкка изге эш эшләп калыйм дип тырыша. Ә моның ишеләре... Күршеңә жалу язу эшмени ул? Ярамаган ягым бар икән, тот та күземә карап әйт! Ә ул кәгазь буйый! Грамотный, янәсе. Чәчәк белән подпольный сәүдә оештырган, имеш... Минем бакчаны күргән кеше син. Ашъяулык хәтле бакчада күпме чәчәк үстерергә мөмкин? Бөтен рәхәте — карчык белән шул чәчәкләр арасында чәй эчә идек. Аннары көз җиткәч, күрше-күләннең беренче кат сабакка баручы балаларына букет өләшә торган идем. Алар тәпи йөри башлагач ук минем янда бөтереләләр. «Миңа бирерсеңме дә миңа бирерсеңме?» — дип, авызыма карап торалар иде... Сатарга дигәне биш-ун букеттан артмый торган иде... Аның белән генә баесаң... Эх! Менә шул пирсон бакчамның башын ашады. Аның әләкләве буенча килделәр дә...

— Тынычланыгыз, Мортаза бабай. Монда ниндидер хаталык килеп чыккан.

— ...Яшьрәк булсам, әлбәттә, авыз ачып ятмас идем. Картайгач, бала белән бер буласың икән: үпкәлисең дә кул селтисең.

Гөлшәһидә картның кан басымын үлчәде. Әйе, бабайның кан басымы югары, ике йөздән артып китә.

— Күптән чирли башладыгызмы? — дип сорады Гөлшәһидә.

— Докторларга йөри башлаганга ярты ел була инде.

— Нинди дарулар бирделәр?

— Тәмсез генә бер төймә. Иртән бер, көндез бер, кич бер эчәрсең, диделәр. Резинный бугай.

— Резерпин,— дип төзәтте Гөлшәһидә.— Файдасы тидеме соң?

— Башта бераз тигән кук була да тагын кирегә китә. Соңыннан бер доктор әйтте: картлык галәмәте, диде. Шулай да әзрәк яшисе килә бит әле, кызым. Яңа Бистәдән кайту юк бит.

— Борчылмагыз, Мортаза бабай, терелтербез. Диләфрүз сезгә дарулар китереп бирер, ул ничек кушса, шулай эчәрсез. Ярыймы? Аннары уколлар булыр.

— Ярый, ярый, кызым. Мин аккуратный кеше. Бераз мактанып әйтим: аккуратный булмаган кеше чәчәк үстерә алмый ул.

Башы чатнаудан гел ыңгырашып яткан Мортаза бабай берничә көннән соң үзен яхшы ук әйбәт хис итә башлады. Шуннан ул Гөлшәһидәнең чәчәк яратуын сөйләргә кереште. Аннары, сүзенә йомгак ясагандай:

— Чәчәк кадерен белгән кеше кеше кадерен дә белә инде ул,— диде.

тәгаен — төгәл, ачык
галәмәт — нәрсәне дә булса күрсәтә, белдерә торган билге
йомгак ясау — нәтиҗә ясау

Сораулар һәм биремнәр

1. Гөлшәһидә Мортаза бабай белән ничек таныш була?
2. Мортаза бабайның яраткан хезмәте нинди?
3. Авыруының сәбәбен ул нәрсәдән күрә?
4. Мортаза бабай Гөлшәһидә турында нәрсә ди? Шул юлларны табып укыгыз. Нәтиҗә ясагыз.

Бишенче бүлек

VI

Иртәдән бирле түбә кыекларыннан тамчылар тама. Кояш та күренми, көне дә әллә нинди соры гына, ә тамчылар шыбырдашып тамалар да тамалар. Болар инде язгы тамчылар, төнлә дә тама торган апрель тамчылары. Колак салып тыңласаң, бәлки, бу тамчылар тамуында, язгы авазларның бу беренче җырында бүтән музыканы да ишетергә мөмкиндер. Җиңү җыры да шулай еракtан башлана бит. Ләкин аны бүген кем тыңлый? Мансур өчен, мәсәлән, бу минутта тамчылар тамуы гына түгел, зур дөнья үзе дә, аның шау-шуы да, кайгысы-шатлыгы да, хәтта кешеләре дә юк иде. Ул үзе дә гүя юк иде. Тик акылы, күзләре һәм куллары гына бар. Аның бөтен зиһене операция өстәлендә яткан авыруга юнәлгән. Ул башканы белми, белергә теләми дә. Баш өстендә таш яуса да, үз йорты янса да, ул моннан кузгалмаячак.

Больницаларның операционный бүлмәләре ишеге башында көн саен «Операция бара» дигән кызыл ут кабына. Бу ике сүз үз эченә алган киеренкелекне күпләр белеп тә бетермиләр. Мондагы секундларның, минутларның, сәгатьләрнең биниһая көч таләп итүен күз алдына китерүе дә авыр. Хирург, аның ярдәмчеләре авыру өстенә иелгәннәр. Операция сестрасы бердәнбер кирәкле инструментны күз ачып йомганчы хирург кулына тоттыра...

Авыруның баш очында басып торган врач-наркотизатор аның маңгаена чыккан бөрчек-бөрчек тирләрне марля кисәге белән сыпырып ала һәм приборларга күз төшерә. Приборлар авыруның хәле нормаль икәнен күрсәтеп торалар иде. Кинәт стрелкалар сикереп куйды. Аннары бик кызу рәвештә түбән тәгәри башладылар. Врач хирургка операцияне туктатырга боерык бирде. Авыруның хәлен яхшыртыр өчен ашыгыч чаралар күрә башладылар, ләкин стрелкалар түбән төшүдән тукталмады, алар, мәрхәмәтсез рәвештә, соңгы чиккә якынлашты. Бу чик артында — үлем. Менә лампочкаларда да, сөрән салып, кызыл сигнал утлары кабынды. Авыруның йөрәге тибүдән туктады, сулышы тынды, пульсы югалды. Бер генә прибор да җан әсәре барлыгын күрсәтми иде. Мансурга булышучы ассистентларның, сестраларның йөзендә борчулы аптыраш. Кеше үлде. Рәхимсез үлем тагын бер җанны алып

киттем дип тантана итә. Тик Мансурның гына моның белән килешергә хакы юк иде. Клиник үлем белән чын үлем арасында хәлиткеч дүрт-биш минут вакыт бар. Шушы дүрт-биш минутта яшәү көче үлгән кешенең организмын бөтенләй ташлап өлгерми әле. Бары тик шул санаулы минутлар үткәч кенә, организмны тулысынча паралич суга, һәм барысы да бетә.

Мансур кулын сузды. Операция сестрасы Наталья Владимировна бу юлы да ул сүзсез таләп иткән бердәнбер коралны гына бирергә тиеш. Аның да ялгышырга, икеләнергә хакы юк. Ул күз ачып йомганчы хирургның зур һәм җитез кулына үткен скальпель тоттырды. Бер сызу белән, Мансур авыруның күкрәген ярды һәм, пычагын ләгәнгә ташлап, авыруның йөрәген кулына алды да, камыр әвәләгән кебек әвәли-әвәли, аны ясалма рәвештә эшләтә башлады. Бер үк вакытта хирургның ассистентлары артерияләргә кан кертә башладылар. Приборлардагы стрелкалар кыймылдап куйды. Ләкин бу — йөрәкнең үзалдына, үзенең сихри көче белән эшләве түгел иде. Бу фәкать хирург кулларының мускул көче генә иде. Ләкин бу көч һәр секунд саен рәхимсез якынлашкан гомуми параличны кичектереп торырга мөмкинлек бирә иде. Барысы да тын алмыйча йөрәкнең «кабынуын» көттеләр. Ә аның гүя «кабынырга» исәбе дә юк иде. Ләкин Мансур йөрәкне ясалма рәвештә эшләтүдән туктамады. Аның куллары тала башлады. Әмма туктарга, ял итәргә бер генә секунд та вакыты юк иде аның. Ул әвәләде дә әвәләде.

Дөньяны тетрәткән, могҗизалар ясарга кодрәте җиткән кеше йөрәге бу минутта шундый көчсез, шундый зәгыйфь иде, ул гүя хирургка: ташла, булмый, булмый миннән, дип әйтә иде кебек. Ләкин Мансур чигенмәде. Кирәк булса, ул ике сәгать, өч сәгать, тәүлек буе көрәшергә әзер иде. Ниһаять, җансыз йөрәк беренче тапкыр үзлегеннән тибрәнеп куйды. Бу тибрәнү бик зәгыйфь иде әле, аны Мансур гына сизде. Берничә секундтан стрелкалар көчлерәк кыймылдый башладылар. Авыруның йөрәге ешрак, көчлерәк тибәргә тотынды, үлгән кешегә җан керде!

...Мансур, операцияне тәгәлләп, барлык булышчыларына рәхмәт әйтеп операция өстәле яныннан киткәндә, аяктан егылырлык булып чайкала иде. Кемдер аны култыклап алды, кемдер маскасын, перчаткаларын, алъяпкычын, халатын салырга булышты.

Кабинетта ул креслога утырды һәм күзләрен йомды. Шунда ук тирә-як карусель кебек әйләнә башлады, күз аллары томаланды, кресло каядыр төпсез упкынга очкандай булды.

Күпме вакыт үткәндер, ул белмәде, түбәнгә очып төшү туктады, кайдандыр ерактан, караңгыдан бер өн ишетелгәндәй булды:

— Яши!.. Яши!..

Һәм шуның артыннан ук ниндидер бик матур музыка яңгырый башлагандай булды. Мансур күзләрен ачты. Томан таралган. Кабинетның тәрәзәсе киң итеп ачылган, бүлмәгә кояш тулган, тәрәзә төбендә Диләфрүз биреп калдырган ак чәчәкләр... Алар әле дә шиңмәгән. Кояш яктысында хәтта купшыланыбрак киткәннәр төсле. Мансур үзалдына әкрен генә елмая. Әмма урыныннан торырлык хәле юк иде әле аның. Кнопкага басты. Сестра килеп керде.

— Миләүшә, авыру ничек?

— Сулый, Мансур абый.

Мансур тагын нидер сорамакчы иде, күзләре үзеннән-үзе йомылды.

— Миңа китәргә ярыймы, Мансур абый? — дип сорады сестра, бераз торгач.

— Зинһар, бер стакан кайнар чәй алып килсеннәр,— диде Мансур, яңадан күзен ачып.

Сестра чыгып киткәч, Мансур карашын тәрәзәгә күчерде. Тамчылар шыбырдап тама, ак чәчәкләр кояшка елмая. Тукта, иптәшләренә рәхмәт әйттеме соң ул?

Мансурның күңелен зур җиңүдән соң гына туа торган пакь һәм якты хис биләп алды. Бу хистә бәхет тә, горурлык һәм канәгатьләнү дә, үзеңнең кешеләргә кирәк булуыңны тою да бар иде. Ул үзе дә, гаҗәпләнеп, кулларына карады. Менә шушы кулларда мең вә миллион еллар буе сере ачылмаган, әле тиз генә ачылу ихтималы да күренмәгән тере йөрәк тибрәнеп торды бит!

Чәй китерделәр. Мансур иреннәрен пешерә-пешерә куе чәй эчте. Аның көче кайтты. Ул, урыныннан торып, тәрәзә янына килеп бакчага карады. Агач кайрылары, коймалар каралган, әйтерсең аларны дымсу кара хәтфәгә төргәннәр. Юлларда кар сулары җәелгән. Шул бәләкәй күлләвекләрдә чыпчыклар чыбырдашып коеналар. Балалар бер-берсенә кар томыралар. «Гөлчәчәк тә урамга чыккандыр, ул да кар белән уйный торгандыр»,— дип уйлап алды Мансур һәм иптәшлә-

ре янына чыкты, аларга кабат рәхмәт әйтте, ә Наталья Владимировнаны маңгаеннан үпте:

— Сез бүген батырлык эшләдегез! Рәхмәт!— диде. Сестраның күзләренә яшь килде, оялып читкә борылды. Моңарчы әле аның күзгә күренми торган хезмәтен беркемнең дә болай зурлаганы юк иде, ул моны көтми дә иде. Ә тиргәгәннәре, ул биргән инструментларны үз өстенә атып бәрүчеләре күп булды, гарьләнеп күпме елады ул! Аның уң беләгендә Яңгура ыргыткан скальпельнең яра эзе гомер буе бетмәячәк, ул аны үзе белән кабергә дә алып китәчәк. Эшеннән туйган, бизгән минутлары нихәтле еш була иде аның. Мансур килгәннән соң, ул гүя терелеп киткәндәй булды.

— Татьяна Степановна, әйдәгез авыруны барып карыйк,— диде Мансур үзенә ассистентлык иткән хирургка, һәм алар авыру яткан палатага юнәлделәр. Әле күптән түгел генә ком тутырылган кебек авырайган аяклары хәзер шундый җиңел атлый, әйтерсең Мансурның пар канаты бар.

Авыру хәрәкәтсез ята. Ләкин йөрәге эшли, тамыры тибә, сулышы тигез. Мансур аңа карап баш очында бераз басып торды да, шатланып:

— Яши бит, Татьяна Степановна!— диде.

— Яши, Мансур Закирович!— дип кабатлады хирург.

Алар, бүтән палаталарга кереп, бүтән авыруларның да хәлләрен белеп чыктылар, аннары Татьяна Степановна — үз эшенә, ә Мансур кабинетына китте. Чак кына борып куелган радиодан музыканың талгын моңы сибелә иде. Мансур бүлмә уртасында туктап тыңлый башлады. Кем әсәре икән? Таныш та, тыңлаганы да бар кебек.

Музыка тынды. Диктор: «Медицина институты студентларының үзешчән концертын тапшырабыз»,— диде.

— Халык җыры «Акъярым». Башкара медицина институты студенткасы Асия Чудина.

Мансур шул секундта радиоалгыч эченә керердәй булды. Һәм җырның беренче юлларыннан ук аның халык җыры түгеллеген аңлады. Бу — Гөлшәһидә җыры, Гөлшәһидә сагышы, Гөлшәһидә әрнүе һәм өмете иде:

Сызлама, әрнемә юксынып, йөрәгем,
Сагынып, саргаеп өзелмә, үзәгем.
Мәхәббәт бер генә, килми ул гел генә,
Карлыгач шикелле, кичекми һәр язда...

Мансур тиз генә тәрәзә төбендәге ак чәчәкләргә карап алды. Диләфрүз шушы ак чәчәкләрне генә түгел, Гөлшәһидәне дә бирде бит! Әй Диләфрүз, Диләфрүз! Нинди генә рәхмәтләр әйтергә сиңа!

киеренке — зур көч, игътибар таләп итә торган халәт
биниһая — бик күп, чиксез
әвәләү — нәрсәне дә булса кул белән әрле-бирле йөртү
купшы — матур, көяз
гарьләнү — хурлану
сагыш — берәр кешене сагынудан, юксынудан туган күңел төшенкелеге, моңаю, кайгы кебек хис
әрнү — рухи газап кичерү, ачыну

Сораулар һәм биремнәр

1. Мансур үз хезмәтен ничек башкара?
2. Мансурны хезмәттәшләре ни өчен ихтирам итәләр дип уйлыйсыз?
3. Табиблар кеше гомерен саклап калу өчен ничек тырышалар? Шул юлларны табып укыгыз. Тормыштан да мисаллар китерегез.
4. «Гөлшәһидә җыры»н (композиторы Җәүдәт Фәйзи) бергәләп җырларга өйрәнегез.

XV

Карт артист елый.

Кырык елдан артыкка сузылган сәхнә тормышында аңа төрле рольләрдә бик күп «күз яше» түгәргә туры килде. Кем булып кына еламады ул! Сөйгән яры ятларга калган яшь егет булып та, малын җаныннан артык күргән карун сәүдәгәр булып та, хуҗалары ташлагач, иясез эт хәлендә калган карт лакей булып та, сугыш кырында якын дустын күмүче батыр солдат булып та, күз яше эрегән тимер кебек көйдереп ала торган карт эшче булып та елады ул. Әмма сәхнәдән тыш, үз йөрәгенең әрнүенә чыдый алмыйча, ул бер генә тапкыр елаган иде. Бу хәл моннан утыз еллар элек, беренче хатыны үлгәннән соң булды. Менә хәзер, җиденче ун белән барганда, карт артист йөрәге, өзгәләнүгә түзә алмыйча, икенче тапкыр елый.

Тышта әле яңа гына таң беленеп килә. Кыюсыз яктылык палата эчен тонык кына яктырткан. Авырулар, саташа-саташа, ыңгыраша-ыңгыраша арып, иртәнге сәгатьтәге кыска

вакытлы тынычлыкка талганнар. Төрле көйгә, төрле тавышларга «тегермән тартканнары» ишетелә. Кайсыдыр иреннәрен чупылдатып-чупылдатып ала. Ачык ишек турысында төнге сестраның ак халаты күренә дә юк була.

Икенче инфарктны да җиңеп аякка баскан Николай Максимович бүген өенә кайтып китәргә тиеш. Аяк егәрләре бераз ныгыгач, сәхнәгә чыгарга да исәбе юк түгел әле аның, пенсия турында ишетергә дә теләмәде, инвалидлыкны кире какты. «Күрмәгән нәрсә түгел, күргән, без инфарктның нәрсә икәнен беләбез»,— диде ул пенсия кәгазьләрен тутырыйкмы дип сораган Маһирә ханымга. Беренче инфаркттан соң ул байтак уйнады, җитез хәрәкәтләре, җиңел йөрешләре белән бик күпләрнең исләрен китәрде. Бер тапкыр Маһирә ханым, аның сәхнәдәге кылануларын күргәч, бик каты кыздырды. Ләкин артист аяктан егылмаса, аны кем авыруга саный?! Әле егылгач та ышанып бетмиләр, бу юри генә кылана торгандыр дип уйлыйлар. Шулай булгач, нигә икенчесеннән соң да уйнамаска? Башкалар инфаркттан соң теләсә нишләсеннәр, пенсиягә китәләр икән, китсеннәр, дача алып су буенда гына яшиләр икән, яши бирсеннәр. Бүтәннәр, температуралары 38° булса, өйдән дә чыкмыйлар, артист 38° белән яшь гашыйк ролен уйный.

Сөенергә генә кирәк чакта ник елый соң бу карт артист?

Таң вакытындагы күз яшьләре — изге күз яшьләре диләр. Юк-бар өчен генә еламый инде кеше бу сәгатьтә. Чыдый алмаслык әрнү генә елата аны бу чакта. Әйе, нәкъ менә шундый чыдый алмаслык әрнү, зәмһәрир суык артистның йөрәген кисә иде бүген. Николай Максимович елый-елый Әбүзәр абзый турында уйлый иде. Хәле иң хәтәр вакытта Әбүзәр Гиреевич «мин монда... бирешмәгез» дип әйтмәсә, Николай Максимович, ихтимал, инде беткән дә булыр иде. Юк, сихәтле дару гына түгел, ә профессорга булган чиксез ышану да аны үлем авызыннан тартып алды. Ә профессор үзе... Аның инде дөньяда юклыгына, авырулар янына моннан соң инде беркайчан да килмәвенә һич ышанасы килми иде. Буниндидер башка сыймаслык бер нәрсә сыман, бу ниндидер зур гаделсезлек сыман. Ничек инде ул алай? Шулхәтле авыруларны гомере буе үлемнән коткарып килсен дә үзе үлсен, ди.

Мөгаен, Гөлшәһидә белән Маһирә ханым Николай Максимовичның хәле авыр дип барып әйткәндә, Әбүзәр абзыйның үз хәле дә шәп булмагандыр. Ләкин ул, үзе белән исәпләш-

мичә, яткан җиреннән торып, больницага килгән, авыруны коткарып калырга булышкан, ә үзе, бәйгедән җиңеп кайткан ат кебек, йөрәге ярылып, баскан урынында егылган...

Таһировның батырлыгы яшен кебек бер яшьнәп, бер күкрәп кенә ялтырап узмады, аның батырлыгы гомер буе дәвам итте һәм көндәлек ыгы-зыгы арасында артык күзгә дә бәрелмәде.

Йөрәге сыкранган чагында, акылы Николай Максимовичка башканы әйтә иде: «Әбүзәр Гиреевич кебек кешеләр тормыштан бер эзсез генә югалмый, җирдә аларның җуелмас эзләре кала, алар җисмән бетсәләр дә, эшләгән эшләре, күрсәткән батырлыклары, рухи гүзәллекләре белән башкалар күңеленә күчәләр һәм алар белән бергә яшәүләрен дәвам иттерәләр. Дөрес, моны акыл күзе белән генә күрәсең. Ләкин... моны маңгай күзе белән дә күрерлек итәргә мөмкин. Монда сәнгать ярдәмгә килергә тиеш. Сәнгатьнең бөек көче бар. Ул үлгәннәрне яңадан терелтә, яңадан яшәтә ала. Бу аның гына кодрәтеннән килә».

Нәкъ менә шушы таң сызылган гүзәл бер минутта Николай Максимовичның күңелендә халык өчен туган, халык өчен яшәгән, бөтен гомерен актык тамчысына кадәр халыкка биргән асыл ирнең, чын врачның якты образы инде мәңге яшәр өчен сәнгатьтә туа башлады. Дөрес, Любимов шушындый әсәрне кем язасын да әлегә анык кына белми. Бәлки, аны кайчандыр шушында яткан, Әбүзәр абзый терелткән Хәйдәр Зиннуров язар, бәлки, башка бер кеше. Әгәр инде берсе дә язмаса, Николай Максимович үзе тотыныр. Ул да булдыра алмаса, халык тудырыр. Ничек кенә булмасын, андый әсәр һичшиксез туачак. Моңа карт артистның иманы камил.

Күптән инде яктырган, күптән инде кояш чыккан, палата эчләре балкып тора. Авырулар да уянган. Төнлә эшләгән санитаркалар, сестралар өйләренә кайтып киттеләр. Бүтәннәре, килеп, тәрәзәләрне ачтылар, идәннәрне юдылар, үзләре торып йөри алмый торган авыруларны юындырдылар. Аннары өлкән сестра Диләфрүз күренде. Ул, башын кыңгыр салып, һәр палата ишеге төбендә бераз басып торды да, керфекләрен сирпеп, үзенең нурлы күзләре белән палаталардагы барлык авыруларга елмайды.

— Исәнмесез, ничек йокладыгыз?— дип сорады. Беренче тапкыр бугай, Николай Максимович бүген аны шаяртмады. Сәгать уннарда Гөлшәһидә килде. Бераздан Маһирә ханым да

палатага килеп керде. Кайтучы авыруларны алар Гөлшәһидә белән бергә карарга тиешләр иде.

— Нишлибез, Гөлшәһидә, Николай Максимовичны? Чыгарабызмы, әллә тагын бер атнага калдырабызмы?— дип сорады ул, артистның караваты янына утырып.

— Бүген кичкә үк театрга чапмаска сүз бирсә генә чыгарабыз,— дип елмайды Гөлшәһидә. Николай Максимовичның терелүенә ул әйтеп бетергесез шат иде.

— Эх сез, минем яхшыларым,— диде артист, икесенең иңбашларына ике кулын салып.— Сез елмаясыз, сезгә күңелле. Сез тагын бер тапкыр карт исәрне үлем авызыннан тартып алдыгыз. Сез үз бурычыгызны үтәдегез. Ә мин үз бурычымны кайчан үтәрмен? Мин бит түләп бетерә алмаслык бурычлы кеше сезнең алда. Диләфрүз баярак нигә күзләрең кызарган дип сорады. Еладым мин бүген... Бик ямансу булганга...— Николай Максимович тагын бармак буыны белән күз яшен тәгәрәтеп төшерде.— Юк бит инде ул, юк!.. Аның алдында мин бигрәк тә бурычлы...

Әбүзәр абзыйны искә төшерү Маһирә ханым белән Гөлшәһидә күңелендә дә йөрәкне сыза торган үткен сагыш уятты. Ләкин бу тойгыга бирелергә ярамый иде. Аннары көне буе җан әрнеп йөреячәк.

— Николай Максимович,— диде Маһирә ханым,— сезгә борчылырга ярамый. Бары тик яхшы нәрсәләр турында гына уйларга тырышыгыз. Театрга баруны хәзергә тыябыз. Сәхнә турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Сез инде үзегезне онытып чабып йөри башлыйсыз.

Николай Максимович әзрәк тынычланды, бетмәс-төкәнмәс шат күңеллелеге яңадан калкып өскә чыкты, һәм ул инде беркадәр җиңелрәк тонга күчте:

— Урамда йөгереп йөрмә дисәгез, анысы минем ихтыярда, хәтта йөз адым атлаган саен туктап бер минут ял итегез дисәгез, аңа да риза. Әмма сәхнәдә... Нинди юләр драматург инфарктлы артистка исәп тотып әсәр язсын, ди. Акробатик номерлар кертмәсә, шунысына рәхмәт.

Башкалар сизмәделәр бугай, әмма Николай Максимович үзе көчәнеп шаяртуның көлке түгеллеген бик ачык сизде һәм шундый көннәргә калдыммыни дип уйлап күңелсезләнде. Врачлар тагын әллә нихәтле киңәшләр биреп, ул киңәшләрнең барысын төгәл үтәсәң, ак сакаллы карт булыр идең, дип чыгып киткәч, ул, ике кулын баш астына куеп, бер

сәгать чамасы беркем белән дә сөйләшмичә уйланып ятты. Аннары Диләфрүз килеп сөенеч әйтте:

— Сезне алырга килделәр. Әйдәгез, киемнәрегезне алмаштырыгыз.

Гадәттә, иң якын, иң яраткан кеше юлга чыгып китсә, өй эче бушап, күңелсезләнеп калгандай була. Һичбер чир белән исәпләшмәүче, Тукай әйтмешли, Газраил белән тартышканда да елмаерга, елмайтырга үзендә көч таба алучы тынгысыз карт артист китеп баргач та, больницада беразга бушлык сизелде, күңелсез булып китте.

Аны озатканнан соң, Гөлшәһидә, өскә менеп, тәрәзә янагына килеп сөялде дә тышка карап тора башлады. Яңадан көз, яңадан бакчада сары яфраклар коела. Күк йөзе зәп-зәңгәр, тик анда-санда гына ак болытлар күренгәли. Әмма бу ак болытлар күкнең саф зәңгәрлеген генә көчәйтәләр. Койманың бу ягында, утын әрдәнәләре ышыгында, гамьсез Байгыш һаман кояшта кызынып ята, ул тагын да симерә төшкән, рәтләп йөри дә алмый, ә койманың теге ягында чәчәк аткан гөлҗимеш куагының очы күренә. Башка агачлар яфракларын, алмагачлар алмаларын койган вакытта да гөлҗимешнең бернигә карамый чәчәк атып утыруы күңелгә якты нур өсти, ниндидер яшерен өмет тудыра, яшәүгә ышаныч арттыра иде шикелле.

карун — бик саран һәм вакчыл кеше
өзгәләнү — бик нык борчылу, газаплану
зәмһәрир суык — ачы салкын, каты салкын
иманы камил — ышанычы зур

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу бүлектә сүз кем турында бара?
2. Карт артист ни өчен елый?
3. Ул Әбүзәр абзый турында нәрсә уйлый? Шул юлларны табып укыгыз. Нәтиҗә ясагыз.
4. Артист үзен кемнәргә бурычлы дип саный?
5. Табиблар нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Шуларны Гөлшәһидә, Диләфрүз образларына нигезләнеп аңлатыгыз.
6. Ни өчен роман «Ак чәчәкләр» дип атала? Романда бу символ — ак чәчәкләр белән бәйле нинди вакыйгалар күрсәтелә?
7. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын тулысынча укыгыз. Әсәр турында үзара фикер алышыгыз.

«Кем булырга, нинди булырга?» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Сез нинди һөнәрләр беләсез?
2. «Ак чәчәкләр» романында сез нинди һөнәр ияләре белән таныштыгыз?
3. Табиблар нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Шуны «Ак чәчәкләр» әсәрендәге образларга нигезләнеп аңлатыгыз.
4. Сез үзегез бу һөнәрне сайлар идегезме? Ни өчен?
5. Хезмәтен намус белән башкаручы кешеләр турында тагын нинди китаплар укыганыгыз бар?
6. Сезнең әти-әниләрегез кайда эшли? Алар үз хезмәтләрен яраталармы?
7. Сез киләчәктә кем булырга телисез? Моңа үзегезне ничек әзерлисез?

Биремнәр

1. Мәкальләрне укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз.

   * Һәр эштә сәләт кирәк.
   * Һөнәр өйрәнер өчен дә һөнәр кирәк.
   * Эш остадан курка.
   * Уку — энә белән кое казу.
   * Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.

2. «Мин кем булырга телим?» дигән темага кечкенә сочинение языгыз.

Нәби Дәүли
(1910—1989)

Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин) 1910 елның 1 июнендә Татарстанның Әлки районы Мәүләшә (Иске Камка) авылында туа. Нәбиуллага сабый чактан ук тормышның бөтен ачысын татырга туры килә: дүрт яшендә әтисе һәм берникадәр вакыттан соң әнисе үлә. Нәбиулла ятим кала. 1921 елда ул Царицын (хәзерге Волгоград) шәһәрендәге балалар йортына килеп эләгә һәм шунда җидееллык мәктәпне тәмамлый. Бераздан Донбасска китә.

Н. Дәүлинең беренче язмалары Донбасста татар телендә чыга торган «Пролетар» газетасында басыла. Соңыннан ул шушы газетада әдәби хезмәткәр булып эшли.

1935 елда Н. Дәүли Казанга килә. Сугышка кадәр «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Бу елларда аның дүрт шигырь җыентыгы («Бәхет», «Ал чәчәк», «Уйлар», «Кырык шигырь») басылып чыга.

Нәби Дәүли сугышның беренче көннәрендә үк фронтка китә. 1941 елның август аенда Орша тирәсендә барган сугышларның берсендә чолганышта калып, фашистлар кулына эләгә. Аны Германиягә озаталар. Башта ул берничә ай Бухенвальдта тотыла. Аннары Баден-Баден, Магдебург шәһәрләре янындагы лагерьларда газап чигә. 1945 елның апрелендә берничә иптәше белән лагерьдан кача һәм үзебезнекеләргә кушыла.

1945 елның декабрендә Нәби Дәүли Казанга кайта. Башта рәссам-бизәүче булып эшли. 1956 елдан башлап, әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Җир язмышы, тынычлык, азатлык өчен көрәш, шул чорда корбан булганнарга дан җырлау, тормышта очрый торган һәртөрле җитешсезлекләргә, гаделсезлекләргә карата килешмәүчәнлек — болар әдипнең бу чор иҗатындагы төп эчтәлекне тәшкил итә. Бу темалар аның күп санлы лирик, публицистик, сатирик шигырьләрендә, балладаларында, мәсәлләрендә, шигъри парчаларында, «Берлинда окоп» (1956), «Авыл дәфтәре» (1954—1967) кебек күләмле поэмаларында һәм прозаларында чагылыш таба.

Әдипнең проза әсәрләреннән «Яшәү белән үлем арасында» (1958) дигән повестен һәм «Җимерелгән бастион» (1965) романын укучылар аеруча кызыксынып укыйлар. Бу әсәрләр автобиографик материалларга, сугыш чорындагы шәхси кичерешләргә нигезләнеп язылган.

Язучы үзенең ятимлектә, балалар йортында үткән үсмер чагы турында «Агат» исемле әсәр яза. Бу турыда ул болай ди: «Ничек кенә ярлы үтсә дә, балачак хатирәләре кадерле. Язарга рәхәт».

Нәби Дәүли 1989 елның маенда Казан шәһәрендә вафат була.

ЯШӘҮ БЕЛӘН ҮЛЕМ АРАСЫНДА

(өзекләр)

Мин хәбәрсез югалган идем

1941 елның җәе иде.

Тыныч иртә иде.

Балалар әле матур төшләр күреп йоклыйлар. Кинәт офык читендә ниндидер алсу, кан төсле яктылык күренде. Аннан соң җирне калтыратып гөрелдәгән тавыш яңгырап китте. Шушы тыныч иртәдә безнең җир өстендә фашист бомбасының беренче кат шартлавы иде бу.

Сугыш башланды. Чик баганаларын аударып, дошман безнең туган җиребезгә аяк басты. Ил кузгалды, халык күтәрелде. Ватан үзенең улларын һәм кызларын көрәш сафларына чакырды.

Сугышның икенче көнендә үк миңа да повестка килде. Инде кичке якта безнең эшелон юлга чыкты. Вокзалда меңләгән куллар яулык болгый-болгый безне озатып калды. Без фронтка киттек.

Мин сугышта гади солдат идем. Алдан ук әйтеп куям, ул вакыттагы сугыш стратегиясен тикшерергә яки тәнкыйтьләргә җыенмыйм. Бу минем хәлдән килерлек эш түгел. Ләкин мин шунысын ачык белә идем: бу сугыш безгә көчләп тагылды. Без үз җиребезне дошманнан сакларга, туган халкыбызның азатлыгын якларга гадел сугышка чыктык. Без, теләмәсәк тә, үтерергә тиеш булдык. Югыйсә безнең үзебезне үтерәчәкләр иде. Коллыкка төшкән илдә безгә нәрсә кала иде соң? Хурлыклы газап та сыкрау!..

Шул көннәрдә мин меңләгән иптәшләрем белән Белоруссия кырларында дошман чолганышында калдым. Ләкин бу җиңелү түгел, сугышның бер моменты яки вакытлы бер хәле генә иде. Сугышта йөргән кеше моны яхшы белә. Сугыш һәр көнне яңа эз белән бара. Бүген солдатка котылгысыз булып күренгән хәл иртәгә бөтенләй киресенчә булуы мөмкин. Безгә шунысы билгеле иде: дошман безне чолгап алган. Чигенү юлларын бикләгән. Тик бу әле бар да бетте дигән сүз түгел. Чөнки без үз җиребездә аяк басып торабыз. Тирә-ягыбызда үз авылларыбыз, үз халкыбыз яши иде.

Билгеле, сугыш корбансыз булмый. Аны солдат сугышка китәргә повестка алган көнне үк исенә төшерә. Ләкин әсир булырмын дип мин уйлаган идемме соң? Киресенчә, дошман безнең җиребездә үзе әсир калган кебек тоела иде миңа.

Чыннан да, әле сугышның беренче айлары гына. Безнең армия үзенең көчен җәеп җибәрергә өлгермәгән. Безне чолганыштан коткарулары мөмкин кебек иде. Дошман армиясе әле үзе чолганышта калмагае дигән фикер безнең күңелләрдә озак яшәде. Сугыш тарихында шундый хәлләр дә булгалаган. Безнең өмет киселмәгән. Үзебезнең армиягә кушылу ышанычы безне юата һәм безгә көч бирә иде.

Минем кайбер окопташларым әле ул вакытта ук илгә кайта алмаганнардыр, яңадан үзебезнең армия белән сугыш юлыннан Берлинга кадәр барып җиткәннәрдер. Ләкин миңа башка язмыш белән очрашырга туры килде. Мин дошман кулына эләктем һәм шул көннән алып бик озак вакытка «хәбәрсез югалып» калган идем. Бу сүзләрне язарга түгел, әйтергә дә авыр. Нишлисең, бу турыда сөйләмәскә мөмкинме соң? Шунсыз мин тыныч кына яши алмам, тыныч кына үлә дә алмам.

Яшь кеше!

Син минем яшемә җиткәндә, мин инде җирдә булмам. Бу котылгысыз аерылу алдыннан мин сиңа кечкенә генә хат язып калдырам.

Син әле мәктәптә укыган көннәрдә үк җирнең тарихы белән, халыкларның тормыш юллары белән танышырсың. Синең күз алдыңнан бик еракта калган гасырлар узып китәр. Нинди генә исемнәрне күрмәссең син ул тарих битләрендә! Нинди генә хәлләрне очратмассың син ул чорларда!

Ниһаять, син, шулай тарих битләрен бергәләп ача-ача, безнең гасырга, без яшәгән чорга килеп җитәрсең һәм анда «фашист» дигән сүзне күрерсең.

Кем иде соң ул фашист?

Мин сиңа шул турыда сөйләргә телим.

Ул көннәрдә

Хәтеремдә: ул көн болытлы иде. Аз гына яңгыр сибәләп тора. Тирә-якта Белоруссия кырлары. Урылмаган игеннәрнең башлары түбән иелгән. Алар, шулай моңланып, җирнең кайгылы зарын тыңлап торалар кебек. Юл буенда, кырда янган машиналар, танклар аунап ята. Арыш арасыннан зенитка көпшәләре күренеп кала. Күз күреме җитә алган һәр җирдә окоплар, базлар һәм балчык өемнәре зур-зур каберләргә охшап тора. Урманнар өстендә төтен болытлары асылынган. Янып каралган агачлар күңелгә авыр моң сала. Шомлы бу күренешләр. Бирегә инде тормыш яңадан кайтмас шикелле. Шулай ук барысы да бетте микәнни? «Ела, ела, табигать, хәзер синең шундый чагың!»—диясе килә. Сугыш сине дә, безне дә кызганмый. Ләкин көт, анакай, без әле килербез...

Моннан кичә генә сугыш узган. Кая гына карасаң да, үлгән иптәшләрнең гәүдәләре ята. Алар, күккә карап, гүя кемнедер көтәләр. Алар өстендә инде каргалар өере оча. Ә еракта туплар гөрселдәве ишетелә. Кургаш төсле авыр соры болытлар эчендә яшен ялтырап китә. Һавада самолетлар гөрләве яңгырый. Сугыш үзенең юлын дәвам итә. Сугыш җирдәге бар тереклекне ут белән кырып бара, артыннан көл генә кала.

Без ике яклап юл читеннән барабыз. Ә юлдан немец танклары, солдатлар төялгән машиналар уза. Танкларның күбесенә немец солдатлары сырышкан. Алар шат. Безнең өсте-

безгә тәмәке төпчекләре атып китәләр. Кайберләре карбыз кабыклары ыргыталар. Үзләре ниндидер хайван тавышы чыгарып көлешәләр.

— Руски капут, капут!— дип акыралар.

Менә бик түбәннән генә самолет очып китә, колоннаны буйдан-буйга күзәтеп уза. Түбәннән аңа немец солдатлары нәрсәдер кычкыралар, кул болгыйлар.

Минем белән янәшә баручы бер иптәш:

— Безнең өстә очарга зур кыюлык кирәкми, син әнә тегендә, фронтка бар, канатыңны өтеп җибәрерләр иде синең,— ди.

— Юк шул, юк, өтмиләр. Өтсәләр, биредә киерелеп очып та йөрмәс иде ул. Күрәсең, алар көчле әле,— ди икенче берәү.

Сүз шуннан артыкка сузылмый. Кем көчле дә кем көчсез, хәзер каян беләсең? Хәзер бу турыда сөйләшүнең нигә кирәге бар? Без инде әсирләр. Безне каядыр алып баралар. Колоннаның як-ягыннан немец солдатлары безгә мылтыкларын төбәгәннәр. Күбебезнең аягыннан итекләре салдырылган, ремеиьнәр алынган, тик кайберәүләрдә генә противогаз сумкалары калган. Күбебез яланбаш. Барыбызны да сакал баскан. Читтән караганда, без бик карт булып күренәбездер, мөгаен. Ләкин безнең иң картыбыз да утыздан узмагандыр. Ә күбебезгә егерме ике-егерме биш яшь.

Безне бик кызу куалар. Әледән-әле «Шнель, шнель!» дигән тавышлар ишетелеп тора. Яралылар, хәлләре бетеп, һаман артка кала баралар. Ахырында, тәмам көчсезләнеп, юлга егылалар. Кинәт мылтык тавышы ишетелеп китә — юл читендә безнең дус, җирне кочаклап, күзләрен йома. Колонна алга узган саен, юлда ятып калган солдат гәүдәләре күбәя бара.

Кайберәүләр, кинәт кенә сикереп, арыш кырына ташланалар. Ләкин фашист пулясы аларны шунда ук куып җитә. Иреккә омтылган йөрәк тибүеннән туктый. Арыш арасында тагын бер гәүдә аунап кала. Ә колонна өстендә «Шнель, руски, шнель!» дигән сүз һаман яңгырап тора... Ул сүзләрне ишеткән саен, йөрәкнең кайсыдыр җиренә яра салына кебек.

Менә алда кечкенә генә авыл күренде. Дөресрәге, кайчандыр авыл булган да, хәзер инде нигезе генә калган урын. Янып күмергә әйләнгән өйләр урынында, кабер ташлары кебек тырпаеп, шәрә мичләр утыра. Авылда җан әсәре күренми.

Колонна килеп җитәрәк, каяндыр шунда җимерекләр арасыннан бер әби белән бер кечкенә генә кыз килеп чыкты. Әбинең кулында чиләк, ә кыз кружка тоткан иде. Алар безгә

су алып чыккан булганнар. Яннан атлаган немец солдаты йөгереп барды да әбинең чиләген тибеп аударды, кызның кулыннан кружканы алып, аяк астына салып таптады!

— Руски, вег, вег!— дип кычкыра-кычкыра, әбине дә, кызны да куарга тотынды. Әби тиз генә китмәде. Яулыгының чите белән күзләрен сөртә-сөртә:

— Улларым, балакайларым! Бер Ходай гына сезне коткарсын инде,— диде.

Бу карт ананың сүзләре әле дә минем исемдә. Бүген дә аның кайгылы йөзе күз алдымда тора. Рус анасы безгә үзенең иң соңгы ярдәмен күрсәтергә теләде. Бәлки, икенче көнне ул үз өенең кисәүләре өстенә ятып үлгәндер. Аның туфрагы каршында мин бүген башымны иям. Кайда син, нәни кыз? Мин сине, әгәр бүген очратсам, инде танымам. Шулай да мин сине оныта алмыйм. Әгәр исән булсаң, бәхетле яшә, аппагым! Синең нәни кулларыңнан без су эчә алмадык. Ләкин без ул авыр минутларда сезне күргәч күпме шатлык кичердек?! Без туган илдә онытылмаган идек...

Авылны узып киттек. Алда — Днепр елгасы. Аның аргы ягында шәһәр күренә. Йортлар өстендә төтен болыты, шәһәр читендә ниндидер баклар яна. Кинәт-кинәт шартлаулар ишетелә. Шәһәр ерак әле. Дары катыш көйгән ис тамак төбенә утыра.

Шәһәргә керер алдыннан безне туктаттылар. Озак та үтмәде, кара брезент япкан зур-зур машиналар күренде. Алар безнең янга килеп туктадылар.

— Җәяү алып барырга куркалар,— диде янымдагы бер иптәш.

Чыннан да шулай. Чөнки шәһәр эченә кергәч, һичшиксез, безгә качарга мөмкинлек ачыла иде.

— Немецның башына тай типмәгән, белә, шайтан,— диде кемдер.

— Белмәскә, шуңа күрә фашист ич ул...

Безне машиналарга утырттылар. Кузгалдык. Бераздан җимерелеп, актарылып беткән урамнар буйлап бара-бара, кызгылт таштан салган бина янына килеп туктадык. Бу — Орша төрмәсе иде.

Капка ачык. Капкадан эчке якка таба өч пулемет көпшәсе төбәлгән. Башларына тимер каска кигән немецлар шул пулеметлар тирәсендә кайнашалар. Ә капкадан әсирләр төялгән машиналар уза тора.

Бу — немецлар тарафыннан Россия җирендә ясалган беренче лагерьларның берсе иде. Безне шунда алып килделәр.

Гомеремдә дә уйламаган тоткынлык көннәрем менә шушы лагерьда башланды.

офык — горизонт, күкнең җир белән тоташкан сыман булып күренгән сызыгы
гадел — дөреслекне яклый торган
корбан — сугышта газап чиккән яки һәлак булган кеше
тереклек — яшәеш, яшәү

Сораулар һәм бирем

1. Вакыйга кайчан һәм кайда бара?
2. Автор сугышта нинди хәлгә очрый?
3. *Сугыш җирдәге бар тереклекне ут белән кырып бара, артыннан көл генә кала* дигән җөмләне ничек аңлыйсыз?
4. Авторның тоткынлык көннәре кайда башлана?
5. Бүлекнең эчтәлеген сөйләгез.

Яшәү белән үлем арасында

Җиде көн узды. Безнең арабызда инде ачлыктан шешенә башлаган кешеләр дә күренгәли. Яткан урыннарыннан тора алмаучылар да бар.

Әле бу көннәрдә без ниндидер бер өмет белән, безне дошман кулыннан коткарырлар дигән ышаныч белән яши идек. Лагерьда әсирләр арасында «Бу атнада безнекеләр һөҗүм башларлар, һәм немец үзе чолганышта калыр» дигән сүзләр йөри иде. Хәтта безнекеләр, немецны юри шулай тылга кертеп, аны капчыкка ябарга уйлыйлар, дип, сугыш стратегиясенең кайбер ысулларын да телгә алучылар булды.

Көннәр узган саен, бу сүзләр азая бара, өметләр сүнә, котылуга ышаныч бетә бара иде. Чөнки туплар аткан тавышлар ишетелми. Орша өстендә бомбалар да шартламый. Фронт бик ерак тылга киткән. Ә фронт ил эченәрәк кергән саен, без дә туган илдән ераклашабыз кебек.

Лагерь капкасыннан яңа әсирләр һаман кереп тора. Аларны безнең белән очраштырмыйлар, ишегалдының тимерчыбык белән бүлеп алынган икенче ягына куып кертәләр. Шулай да, тимерчыбык аша булса да, дуслар дусларны таба.

— Әй Петро, нихәл? Безнекеләр әле һаман чигенәме?— ди бу яктан берәү.

Бу сүзләрне ишеткәч, Петро тиз генә тимерчыбыклы койма буена килә. Ул үзенең дустын күреп шатланырга да, гаҗәпләнергә дә белми.

— Васька, Васька, син дә биредәмени?

— Күрәсең.

Алар тынып торалар. Бер батальонның ике сугышчысы бер-берсе алдында бу әсирлек өчен уңайсызланып калалар.

— Эшләр начар, егет, немец Минск юлына чыгып алган да туры Мәскәүгә чаптыра,— ди Петро.

Ә үзе дустының ачлыктан зураеп калган күзләренә карый. Бу авыр хәбәрне, бәлки, әйтергә дә кирәкмәс иде. Нишлисең, бу дөрес ич.

Дуслар батальонда бергә хезмәт иткән иптәшләре турында сөйләшәләр. Кемне генә искә алсалар да, кайсы үлгән, кайсы хәбәрсез югалган. Күңелне аз гына да куандырырлык хәбәр юк.

— Да,— ди Вася,— батальон беткән.

Алар тагын тынып калалар. Тагын ни сөйлисең?

Петро теге яктан әсирләргә карый:

— Ә сезнең хәлләр ничегрәк соң?— ди. Вася эндәшми. Сүзсез дә аңлашыла ич... Шулчак теге яктан да, бу яктан да ике немец солдатының ашыгып килгәне күренә.

— Вег! Вег!— дип кычкыралар алар.

Иске әсирләр белән яңа килгәннәрне сөйләштермиләр. Ике дусның икесе дә артка чигенә. Өстәвенә немец Васяны куып җитеп җилкәсенә мылтык көпшәсе белән төртә. Вася алга сөрлегә һәм төркем арасына кереп югала. Моңа беркем дә гаҗәпләнми. Дошманнан нәрсә көтәргә мөмкин соң?

Мин инде берничә көн Василий Петровичны очратканым юк. Кайда ул, әллә качып киткәнме?

Шулвакыт мин аның тавышын тагын ишеттем:

— Егетләр, берәр газета алып килмәдегезме?— диде ул теге яктагыларга.

Җавап булмады. Тик төн җиткәч, безнең якка вак кына ташлар төшә башлады. Әсирләрнең кыр почтасы эшкә кереште. Бу ташларга бәйләнгән язу кисәкләре аша без сугыш турында бик күп хәбәрләр белдек, һәм безнең кулда «Правда» газетасы да бар иде инде.

Василий Петрович бүген, ни өчендер, бик шат күренә, ул пилоткасын артка ук төшереп кигән, гимнастерка өстеннән билен бау белән буган. Ул сакал баскан битен сыпырып карады да:

— Кырынып җибәрәсе иде,— диде.

— Ә пәке каян алырга?

— Туктагыз әле,— диде берәү.— Мин бит парикмахер. Бөтенләй онытып җибәргәнмен. Мин бит Харьков салоннарында эшләгән беренче класслы мастер...

Ул урыныннан торды. Җимерек стена буеннан берничә кирпеч китереп, берсе өстенә берсен өеп куйды. Без аңа гаҗәпләнеп карап тора башладык. Бу нишләргә уйлый икән?

Шуннан соң пыяла ватыклары алып килде. Аларны берберсенә чыңгылдатып ышкып алды һәм бары парикмахерларда гына була торган җитезлек белән шул пыялаларның йөзенә бармагын тидереп узды.

— Шәп!—диде ул.— Хәзер лагерьда беренче номерлы парикмахерский ачып җибәрәбез...

Мин элек тә, пыяла белән кырынып була, дигән сүзләрне ишеткәнем бар иде. Аның дөреслегенә бик үк ышанып җитми идем. Бу юлы чынлап ышанырга туры килде. Күпләребезгә әле таныш булмаган мастер үзенең «классын» күрсәтте.

Парикмахерскийны ачарга әзерлек эшләре әле бетеп җитмәгән иде. Тарак һәм кайчы кирәк иде. Мастер монысына да аптырап калмады. Ул унлап шырпыны бер агачка тезеп бәйләде дә, моннан бик уңайлы ике яклы тарак килеп чыкты. Ул арада аңа, кирпечләрдән өеп, «өстәл» ясап өлгерделәр. Инде көзге генә кирәк иде. «Көзгесез дә ярар»,— диючеләргә мастер:

— Көзгесез эшләмим. Көзгесез ул нинди парикмахерский булсын инде,— дип, кулларын як-якка җәеп җибәрде. Әйтерсең, чыннан да, ул «салон» ачарга җыена иде.

Бер солдат каяндыр ватык машина фарасы табып китерде. Мастер аны алып карады.

— Ярый торган нәрсә бу,— дип, ул көзгене бер әсиргә тотып торырга кушты. Аннан соң гимнастеркасын салып, аны алъяпкыч кебек итеп биленә бәйләде дә, бик эре кыланган булып:

— Василий Петрович, утыр. Сез минем беренче клиентым, шулай булгач, сезне түләүсез генә кырам,— диде.

Василий Петрович утырды. Көзгедә ул башы белән түбән асылынып куелган кебек күренә иде. Аңа бу кызык булып тоелды, ахры, ирексездән көлеп җибәрде. Читтән карап торучылар да көлештеләр.

— Прошу внимания!— диде мастер, һәм пыяла китеген алып, Василий Петровичның битенә куеп, әкрен генә түбәнгә таба кырып төшерә башлады. Ун-унбиш минуттан соң Василий Петрович инде яшәреп калган иде. Мин шунда гына аның әле яшь кеше икәнен күрдем. Сакал-мыекларын кыргач, ул тагын да ябыграк булып күренде.

— Рәхмәт,— диде ул мастерга.

Ә мастер исә, үз эшеннән бик канәгать булып:

— Следующий!— дип кычкырды.

Бу, бер карасаң, уен-көлке кебек иде. Ләкин, чынлап уйласаң, бу — яшәргә омтылу, җанга сүнәргә ирек бирмәү, кыскасы, тормышның бер саламына тотыну иде.

Озакламыйча, безнең лагерьда шундый парикмахерскийлар берничә урында оешып китте. Хәтта кырынган өчен «түләү» дә кертелде. Мәсәлән, сакал-мыек кырган өчен, бер төрерлек тәмәке. Тәмәкең булмаса, башка берәр нәрсә, хәтта гимнастерка төймәсе дә ярый иде.

Лагерьда башка һөнәрчеләр дә табылды. Безнең арабызда тимерчыбыктан энә ясаучылар да, ут чыгарыр өчен чакматаш ясаучылар да, хәтта анда-монда ауналып яткан түбә калайларыннан котелок һәм кружка ясаучылар да эшкә керештеләр. Билгеле, болар яшерен, лагерьда немецлар йөрмәгән вакытта эшләнә иде.

Шулай итеп, чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган йортта яшәү өчен көрәш үзенең беренче адымын атлады.

ысул — алым, юл
сөрлегү — абыну
чакматаш — ут алу өчен кулланыла торган каты таш

Сораулар һәм биремнәр

1. Лагерьда тоткыннарны ничек газаплыйлар?
2. Әсирләр нәрсәгә өметләнәләр?
3. Тоткынлыкта кешеләр яшәү өчен ничек көрәшәләр? Шул юлларны табып укыгыз.
4. Сугыш чорында милләтләр дуслыгы ничек чагыла?
5. *Өмет, куаныч* сүзләренә бүлектән синонимнар табыгыз.

Егерменче гасыр фиргавеннәре

Иртүк безне эшкә алып киттеләр.

Юлга чыккач, мин артка әйләнеп карадым. Колоннаның очы да күренми иде. Беркем дә сөйләшми. Башлар түбән иелгән. Аяклар, җиргә ышкылып, авыр атлыйлар. Кулларда хәрәкәт көчсез, ирексездән, ачлык һәм түбәнлек кешенең рухын сүндерә бара. Безнең өстебезгә карап: «Коллар, коллар»,— диярге генә мөмкин иде.

Ләкин бу тыштан гына шулай күренә.

Әгәр кем дә булса берәү безнең йөрәкләребезне күрә алса, аның исе китәр иде. Шул йөрәкләргә җыелган нәфрәтне күрсә, бу кешеләрнең күкрәгендә кызган тимер бар икән дияр иде. Юк, без биредә узган бер генә көнне дә онытмабыз. Биредәге күргән газапларны күңелләребезгә язып барабыз. Без әле башларны күтәрербез...

Без, тауны уратып, түбәнгә таба төшеп киттек. Бераздан таш чыгарыла торган җиргә килеп җиттек. Бу — тирәсе ялангач таш кыялар белән уралган зур тирән чокыр иде. Югарыдан караганда, без, мөгаен, бөҗәкләр кебек кенә күренәбездер.

Нәкъ безнең баш турыбызда зур-зур ташлар асылынып тора. Алар биектән безнең өстебезгә сикерергә әзерләнгән юлбасарларга охшыйлар.

Көз көннәре иде. Һава салкын. Кинәт-кинәт болытлар ябырылып килә дә, яңгыр ява башлый. Безнең киемнәребез юка, алар да инде тузып бара.

Безнең белән бергә поляк әсирләре дә эшкә килделәр. Без алар белән үзара тату идек. Кайвакытларда без бер генә минутка булса да очрашабыз. Фронт яңалыклары турында хәбәрләшеп алабыз. Тәмәкебез булганда, уртаклашып тартабыз. Ләкин немецлар безнең дуслыкны яратмыйлар, алар безне бер-беребездән ераграк тотарга тырышалар.

Бу юлы да безнең эш урыннарыбыз аерым иде. Полякларга тау төбеннән чыгарылган ташларны тигез кисәкләргә ватып, кырыйларын шомартырга куштылар. Әсирләрнең бер төркеме әзер ташларны машиналарга төйи башладылар.

Безнең кулыбызга авыр тимер кәйләләр, ломнар бирделәр. Без таш чыгарырга тиеш булдык.

Эш башланды. Безне, ерактан торып, сакчылар күзәтә. Алар овчарка этләрен ияртеп йөриләр. Безнең янныбызда

тагын берничә солдат бар. Алар һаман безне ашыктыралар, хәтта кайберләре, русча сөйләшергә маташкан булып:

— Тавай, тавай,— дип кычкыралар.

Бераз хәл җыярга туктаган кешене шунда ук күреп алалар, атылып янына баралар да, камчыларын баш өстендә чыжлатып, акыра-бакыра башлыйлар.

Минем биредә беренче генә көнем. Шулай да шушы салкын ташлар арасында бик-бик күптән яшим шикелле тоела. Тормышымда булган шатлыкларым, бәхетле көннәрем бу соры ташлар арасында гомергә онытылдылар кебек.

Янымдагы иптәшләрем биредә инде өч ай буена эшлиләр. Хәтта моңа ышанасы да килми. Ничек алар үлеп бетмәгәннәр? Бу газапка ничек түзгәннәр?! Йөрәк, күрәсең, таштан да ныграктыр! Йөрәктән кан сыгыла, ул күпме хурлык, түбәнлекләрне кичерә, ә үлми, һаман кайнар, һаман күкрәктә ярсыпярсып тибә. Дөньяда катыдан да катырак нәрсә каты?— дип сорасалар, мин: «Йөрәк!»—дип әйтер идем.

Мин, кулыма авыр лом алып, җирдән сыртын күрсәтеп яткан таш катлавы янына килеп бастым. Таш миңа ыржаеп торган шикелле. Ул мине, кочагына алып, кысып үтерергә җыена иде кебек.

Лом белән ташка китереп бәрдем. Таш чуен кебек чыңлап куйды. Лом кулларымны яңгыратып җибәрде. Сөякләремдә дә ниндидер бер тавыш ишетелде кебек. Гүя сөякләрем дә чыңлый иде.

Ташка тагын лом очы белән бәрдем. Ләкин таш минем көчемне бөтенләй сизми, лом төшкән урында бары нокта кадәр генә эз кала. Бу ташны минем көч белән ватарга мөмкинме соң? Таш түгел, бәлки, мин үзем шунда вак кисәкләргә уалып бетәрмен.

Арыдым. Ломны ташладым да, таш өстенә утырып, тирәягыма карый башладым. Тау өстендә озын, кара сынлы наратлар чайкала. Алар үзләренең очлы башлары белән болытларны тишеп кергәннәр кебек. Түбәндә меңләгән кешеләр кәйләләр белән таш чүкиләр, чак-чок иткән тавышлар ишетелеп тора. Әнә бер төркем әсирләр бик зур таш кисәген тәгәрәтеп баралар. Алар таш янында кечкенә генә коңгызларга охшыйлар. Әнә тегендәрәк поляк әсирләре машиналарга таш төйиләр. Әнә бер машина китеп бара, берсе инде килеп тора. Әнә бер солдат кемгәдер кычкыра...

Тукта әле, бу күренеш миңа, ничектер, таныш кебек тоела. Мин кайчандыр шул ташлы тауны, шул ябык кешеләрне күргән идем кебек. Ләкин кайда? Әллә берәр рәсемдәме, кинодамы әллә төшемдәме? Юк. Кайда соң?

Кинәт исемә төште: мин бала чагымда ук бер китап укыган идем. Ул китапта Борынгы Мисырда яшәгән фиргавеннәр турында язылган иде. Менә шул фиргавеннәр заманында күпме халык коллыкта изелгән! Коллар фиргавеннәргә сарайлар төзегәннәр, җир эшкәрткәннәр, җимешләр үстергәннәр.

Мисыр пирамидаларын кемнәр белми? Ул тау кадәр кабер һәйкәлләрен йөз меңләгән коллар салганнар. Ничә еллар буена алар үз җилкәләрендә таш ташыганнар, үзләре шунда һәлак булганнар. Әнә шушы күренеш минем хәтеремә килде.

Әйе, ул — Мисыр трагедиясе. Ә биредә Мисыр түгел, Германия. Күп мең еллар элек түгел, бүген — безнең заманда, егерменче гасырда! Аерма тик шунда: Мисырда колларны фиргавеннәр газаплаганнар.

Германиядә безне фашистлар һәлак итәләр. Мисырда фиргавеннәр коллардан үзләренә пирамидалар салдырганнар, ә Германиядә капиталистлар безнең куллар белән сугыш утыннан алтын эретеп алалар. Без чыгарган бу ташлардан алар үзләренә матур йортлар салалар. Тагын да баерак булырга телиләр. Я, фиргавеннәр белән фашистлар арасында нинди аерма бар соң?

— Син нәрсә, егет, пышылдап кына сөйләнеп утырасың?— диде миңа бер әсир.

Мин сискәнеп киттем. Урынымнан торып, ломны кулыма алдым.

— Әнә сиңа баядан бирле фриц карап тора. Башыңны сакла, туганкай, кирәк булыр әле ул,— дип, әсир, минем янга килеп, кәйлә белән ташка суга-суга сөйләшә башлады.

— Кемгә кирәксен безнең башлар?— дидем мин аңа.— Кемгә кирәксен бу бәхетсез башлар?..

— Туган илеңә!— диде теге әсир. Мин аңа күтәрелеп карадым. Аның бу сүзләре миңа бик ягымлы булып ишетелде. Минем бу кешенең күзләренә карыйсым килде. Теләгемне сизгән кебек, ул да йөзен миңа таба борды.

Ул шактый яшь кеше иде. Аңа, бәлки, егерме биш-утызлардан ары булмагандыр. Аның йөзендә беренче карауда ук күзгә бәрелә торган аерым билгеләр юк. Бит сызыклары дөрес урнашкан. Күзләре башка кайбер кешеләрнеке шикелле

зур яки бик кечкенә түгел, борыны да җәелеп яки озынаеп тормый. Кыскасы, барысы да үз урынында иде. Тормыш тәҗрибәсеннән күренгәнчә, мондый кешеләр, гадәттә, тыйнак һәм гадел булалар.

Мин яңа танышыма бераз карап торгач, бая өзелеп калган сүзне дәвам итәргә уйладым. Үзем лом белән ташка бәрәм — үзем сөйлим.

— Безнең башлар туган илгә кирәк булырлармы соң?— дим.

— Ә нигә син алай уйлыйсың?

— Уйламас идем дә, уйларга туры килә, парин. Ни әйтсәң дә, без — әсирләр. Илдә безнең турыда яхшы хәбәр йөрмәс... Безнең монда шулай газап чигүебезне кем белә?

— Ил белә, халык белә. Без — әсирләр, ләкин җинаятьчеләр түгел ич...— ди теге әсир.

— Җинаятьчеләр түгел, анысы дөрес, ләкин батырлар да түгел,— дип, тагын берәү сүзгә кушылды.— Менә уйлап кара, син хәзер нишлисең? Таш чыгарасың. Кемгә? Дошманга. Я, шуннан соң син кем инде, әйт?

— Соравың туры, ләкин яңа түгел. Синең башыңа бу уй бик соң төшкән булса кирәк... Мин үз язмышымны бары туган илемә генә тапшыра алам. Әгәр мине ил җинаятьче дип саный икән, атсын, ассын. Тик үз кулы белән.

Әсир ярсып китте. Аның маңгаена кан тамыры бәреп чыкты. Күзләре ачыла төште. Тавышы дулкынланды. Ул, шулай сөйли-сөйли, үзе дә сизмәстән, кәйлә белән зур таш кисәген ватып, түбәнгә таба тәгәрәтеп җибәрде. Үзе:

— Сакланыгыз!— дип кычкырды. Аннары кәйләгә таянды да:

— Теләсә нишләсеннәр, исән-сау калсам, илгә беренче булып кайтам,— диде.

— Ә Себергә җибәрсәләр?— диде баягы әсир.

— Юк, мине Себергә җибәрмәсләр. Чөнки мин — тамгаланган солдат.

Әсир, чалбар балагын күтәреп, шәрә аягын күрсәтте.

— Менә кара,— диде ул,— бу нәрсә? Мин аның аяк балтырында зур яра эзен күреп калдым. Шунда мин яңа танышымның аксак икәнен белдем.

— Бу,— диде әсир,— сугыш тамгасы. Ә менә монысы...— Ул, кәйләсен ташлап, пиджагын күтәреп, аркасын күрсәтте,— ә менә монысы фашистлар тамгасы.

Әсирнең аркасы аркылы-торкылы кызыл җепләр белән сызгаланып беткән иде.

Әсир сүзен дәвам итте.

— Исән генә калыйм, илемә кайтам. Кайтам да фашистларның явызлыкларын бөтен дөньяга сөйләп йөрим. Ышанмасалар, менә шул тамгаларны күрсәтәм. Мин фашистларның киләчәген үтерүче булып кайтам... Беләсеңме?— Әсир бераз тынып торды. Кәйләсен алып, тагын ташка сукты.— Себергә җибәрәләр икән,— диде ул,— курыкмыйм. Себер дә безнең туган илебез ич.

Мин бу бәхәсне исем китеп тыңлап тордым. Әле бая гына көчсез, рухсыз булып күренгән кешеләр хәзер ниндидер батырлар кебек күренә башладылар.

Чыннан да, без әгәр исән калсак, тәннәребездәге камчы эзләре белән, сынган, биртелгән кул-аякларыбыз белән, үпкәләрдәге авыруларыбыз белән һәм йөрәкләргә язылган онытылмаслык нәфрәтебез белән фашизмны тере гаепләүчеләр булып җирдә йөрербез. Моның өчен яшәүнең кызыгы бар әле!

Теге Себер турында куркып сөйләгән әсирне аңлыйм мин. Ул, әлбәттә, үзенең бу язмышы өчен хурлану газабын кичерә. Ул үзенең фашистларга эшләп йөрүен җинаять итеп саный. Күңеленә тулган шул авыр хисләрен бушатырга тели иде.

Бу сөйләшүләр миңа дәрт өстәп җибәрде.

Безнең янга бер солдат килеп, эшебезне карап торды. Без бик тырышып эшләгән кебек күренергә маташтык. Солдат бер сүз дә әйтмәде. Ул ниндидер көй сызгыра-сызгыра китеп барды.

— Әйдә, юлыңда бул,— диде минем яндагы аксак әсир,— хәзер сызгырсаң, биисе көннәрең дә булыр әле.

Аксак әсир миңа якынрак килде, тагын сүз башлады.

— Син ничек уйлыйсың?— диде.

— Сугыш беткәнче үк туган илгә кайтасы иде,— дидем мин,— тик менә җае чыкмый әле.

— Монысы, ичмасам, сүз,— диде аксак әсир.— Мин дә шулай уйлыйм. Тик менә аяк сынатыр.

Әле бая гына бик гади булып күренгән күзләр хәзер кара күмердә янып торган чаткылар кебек ялтырыйлар иде.

— Синең исемең ничек?— диде аксак әсир.

— Николай.

— Минеке дә Николай, димәк, адашлар.

— Шулай булып чыга,— дидем мин.

Кинәт тау кырыенда озын комендант һәм гражданский киемдәге тагын берничә кеше күренде. Алар арасында мине бирегә эшкә җибәрүче немец та бар иде.

Алар югарыдан безне күзәтеп торалар. Комендант бер кулын артка куйган, бер аягын алгарак чыгарып, як-якка карана. Коралсыз әсирләр каршында, тау башына басып, «җиңүче» булып күренергә тырыша. Аның бу ахмаклыгы тумыштан килгән, ахрысы. Аңа, бәлки, бервакыт акыл да керер. Ләкин соң булыр.

Николай аларга күз төшереп алды да кәйлә белән ташка китереп сукты. Ул ачулы иде. Кәйлә очыннан сибелеп киткән чаткылар үз йөрәгеннән чыгалар иде кебек.

— Адаш,— дидем мин аңа.

Ул да, миңа күтәрелеп карап:

— Адаш,— диде.

Без бер-беребезне әле хәзер генә танып алдык кебек, йөзгә-йөз карашып тордык. Ни өчендер, икебез дә берьюлы елмайдык. Бәлки, бу безнең күңелләрнең очрашкан чагы булгандыр. Кеше гомерендә мондый минутлар озак онытылмый.

нәфрәт — иң көчле дошманлык, куралмау хисе
фиргавен — Борынгы Мисыр патшасы
кыя — үтә текә тау
кәйлә — бер ягы очлы итеп эшләнгән чүкеч сыман тимер корал
уалу — вак кисәкләргә бүленү, ватылу
җинаять — хыянәт, илгә, халыкка каршы эшләнгән зарарлы гамәл

Сораулар һәм бирем

1. Әсирләрне нинди эшләрдә эшләтәләр?
2. Бу газаплы тормышны автор кайсы чор белән чагыштыра?
3. Әсирләр нәрсә турында бәхәсләшәләр?
4. Повестьны тулысынча укыгыз.

Шамил Рәкыйпов

(1929—2005)

Шамил Җиһанша улы Рәкыйпов 1929 елның 22 сентябрендә Татарстанның Чүпрәле районы Яңа Чокалы авылында туа.

Язучының беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре — очерк, хикәя һәм сәхнә әсәрләре — матбугатта 1956 елда күренә башлый. 1957 елда Бөтендөнья яшьләр фестивале уңаеннан үткәрелгән республика конкурсында Ш. Рәкыйповка «Сөю билгесе», «Арзан матурлык» исемле бер пәрдәлек пьесалары өчен беренче бүләк бирелә.

Ш. Рәкыйпов укучыларга документлар нигезендә язылган проза әсәрләре белән киңрәк билгеле. Ул иҗат иткән очерк, хикәя, повестьларның күбесен Бөек Ватан сугышы һәм аның үлемсез каһарманнары темасы берләштерә. 1967 елда аның «Чәчәкләр сөйли белә» исемле повесте басылып чыга. Бу әсәр фашизм белән көрәштә Александр Матросов һәм Газинур Гафиятуллинның тиңдәшсез батырлыгын кабатлаган Барый Шәвәлиев турында. Шулай ук язучының Иван Кабушкин хакындагы «Кайдан син, Жан?» (1968), каһарман сугышчы Гыйльфан Батыршин һәм аның дусты Иван Чернопятко турындагы «Таңнар һаман матурмы?» (1969), хатын-кыз очучылар Мәгубә Сыртланова, Ольга Санфирова һәм аларның полкташларының батырлыкларына багышланган «Кызлар-йолдызлар» (1972) һәм башка әсәрләре дә укучылар күңеленә хуш килде.

Шамил Рәкыйпов 2005 елның 17 февралендә Казан шәһәрендә вафат була.

ЧӘЧӘКЛӘР СӨЙЛИ БЕЛӘ

(өзекләр)

I

Беркөнне кич ятарга җыенганда гына, Барый мышкылдап урамнан кайтып керде дә энисенә:

— Әни, әни! Иртәге көннән башлап, мине үзең торганда уятырсың, яме,— диде.

— Бәрәч, ни өчен шулай тагын?

— Сабан туйлары җитә ич.

— Җитсә соң.

— Узган ел алка ыргытышта — Сәмигулла, капчык киеп йөгерештә Гадел беренчелекне алган иде. Быел аларны узарга исәп.

— Һи, улым, икесен дә узу авыр булмагае ул.

Кулларын баш астына куеп, уйланып яткан Гани абзыйның күзләре очкынланып китте. Ул торып ук утырды һәм идәнгә, Габделвәли янына ятарга җыенган олы улына:

— Прабильно, Габделбарый. Икесен дә уз,— диде.

— Син, атасы, котыртма баланы. Авырып китмәгәе...

— Пычак та булмас.

Шул арада өс-башын чишенеп өлгергән Барый энисе күпертеп куйган мамык мендәрне алып сандык өстенә ыргытты, мендәр урынына баш астына иске бишмәт салды.

— Нишләвең бу, Габделбарый? Җүләрләндеңме әллә, исәр малай?

— Мин Суворов дигән китап укыдым. Ул, үзен чыныктыру өчен, саламга ятып йоклаган. Ахырдан генерал булган бит шул кеше, әти!

— Язалар җыен тузга язмаганны!..

— Алай димә син, хатын. Чүтеки хак сүздер ул. Үземнең дә колакка чалынганы бар.— Аннары ул Барыйга таба борылды һәм, елмаеп:—Тәвәккәллә, улым. Тәвәккәл таш ярган!— диде.

— Кәнишне, әти. Юкса командадагы малайларны җиңмәгәч, какуй башлык мин аларга!

— Дөрес. Хәзер йокла. Иртәгә үзем уятырмын.

Әйттеме — эшли инде аның этисе. Ул, иртән кызарып кояш чыгып килгәндә, балалар уянмасын дип пыш-пыш тиргәнгән Миңлеҗиһан апаның сүзләрен колагына да элмичә, елмая-елмая Барыйны уятты. Салкын су белән юынырга

кушты һәм келәттән дүрт пот арыш сыярлык капчык алып бирде, аны киеп ничегрәк йөгерергә кирәген аңлатты.

Барый, йорттагы тавыкларның котларын алып, шап та шоп егыла-егыла йөгерде, тагын торды, тагын йөгерде.

— Батыр ярасыз булмас. Туеңа хәтле төзәлер!— диеп куәт бирә торды улына Гани абзый.

Тирләгәнче күнегүләр ясагач, Барый капчыкны үзе генә белгән җиргә яшереп куйды һәм әнисенә йорт эшләренә булышты. Аннары, көндәлек гадәте буенча, чәчәкләргә су сипте. Мәктәптәге түгәрәккә йөри башлагач, чәчәкләрне яратуы тагын да артты малайның. Су сибә дә, тәрәзәгә килеп: «Сәгать ничә?»—дип сорый. Сорый да йөгереп бакчага керә һәм, чәчәкләргә карап, дәфтәренә нидер язып куя. Тора-бара ул:

— Әни, әни, кара әле, сәгать җидеме? — дип, вакытны төптөгәл үзе әйтә башлады. Шундый чакларда аналы-уллы ничек шатлануларын күрсәгез иде!

Шатланмаслыкмыни?! Чәчәкләргә карап вакытны төгәл әйтүчеләр аяк астында чуалып йөрмиләр алар. Андыйлар бармак белән генә санарлык бу дөньяда. Бәлки, артыграктыр. Һәрхәлдә, Барыйның әнисе шулай уйлый. Ышанмыйсызмыни? Әйе, әйе, чәчәкләргә карап вакытны белү үзегезнең хәлдән килми шул. Юк, бернинди дә тылсым юк биредә. Тырышса, игътибарлы булса, һәркем төшенә бу эшкә. Хәзер Тегермәнлек малайларының барысы да дип әйтмик, хата булыр, ә Барыйның дуслары һәрберсе өйрәнде моңа. Чәчәкләргә генә күз сирпеп алалар — сәгате-минутына хәтле төгәл әйтәләр.

Ә бит башта тәмам тамаша булды...

Үзсүзле Гадел һәм Сәмигулла, дәрес өйрәнеп тә туйган дип, Галим абыйлары түгәрәгенә язылмаган иделәр. Илһам авырып түгәрәккә килми калды. Нәкъ шул көнне укытучы чәчәкләр турында сөйләде. Дөньясын онытып, рәхәтләнеп тыңлады Барый, һәм чәчәкләргә карап вакытны төгәл билгеләргә өйрәнде. Әйткәнебезчә, башта малайлар моңа бер тамчы да ышанмадылар.

Нәкъ бүгенге кебек, Барый бакчада чәчәкләргә су сибеп йөри иде. Уйнарга чакырырга дип, Гадел керде. Куллары кесәсендә. Фырт. (Югары оч малайларының кузнасын отып кайткан икән.)

— Әйдә «Чөгәле күл»гә, балыкка,— ди бу.

— Бүген өлгермибез. «Чөгәле күл» биш чакрымда, ә хәзер сәгать өч инде,— диде Барый.

— Нинди өч булсын? Җүләр сатма, унике дә юк әле,— ди Гадел.

— Юк, төп-төгәл өч...

— Юк, унике...

Биш кузна өстеннән бәхәсләштеләр. Гадел оттырды. Бераздан оттырышны кайтарырга теләп, Гадел тагын бәхәсләште һәм тагын оттырды. Шулай итеп, барлык кузналар Барыйга күчте. Гомер булмаган хәл.

— Син хәрәмләдең, ахры,— диде Гадел, һаман исенә килә алмаган кеше төсле каңгыраеп.

— Юк, ипидер, кояштыр әгәр...

— Ник оттырдым соң мин алайса ун кат?

Барый бакчадагы чәчәкләргә үрелеп карады һәм:

— Тагын бәхәсләшсәң, тагын оттырыр идең менә,— диде.— Хәзер алтынчы ярты булып килә.

Гадел, ышанырга да, ышанмаска да аптырап, өйгә кереп китте һәм: «Сихерең бардыр синең!» — дип, бик тиз борылып та чыкты. Күзләре уттай яна, бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырыйлар.

Барый, дустыннан көлә-көлә, серне аңлатты. Аннары, хикмәтле чәчәкләргә сибү өчен чишмәдән су ташып алҗыган Миңлеҗиһан апаны кызганып, чиләк эләрлек итеп арба әмәлләргә керештеләр. Шул көннән башлап, Миңлеҗиһан апаның иңнәреннән көянтә төште, Барыйга исә тагын бер хатын-кыз эше өстәлде. Иртә-кич, әйтүне дә көтеп тормый, барлык чиләк-кисмәкне су белән тутырып куя. Юлда очраган картыяше Барыйны мактый.

Иртәгә Сабан туе дигәндә, Сәләхи карт, кулына озын колга тотып, җигүле ат һәм бер төркем малайлар ияртеп, өй борынча йөрергә чыгып китте. Тегермәнлектә килене яки җиткән кызы булмаган өй сирәктер. Шуңа күрә озын колгага матур чигүле сөлгеләр, кулъяулыклар һәм көя даруы исе сеңгән бүтән төрле чүпрәк-чапрак өстәлә генә торды. Дистә-дистә күкәй, бал, аяклы мал бирүчесе дә табылды, әлбәттә.

Гөлсем очларына әтәч сурәтләре чигелгән менә дигән затлы сөлге чыгарып бирде.

— Кызганып-нитеп тормыйм, агай,— диде ул,— тик бер шартым бар.

— Әйт, әйт, апаем, җәмәгатькә ирештерермен. Шартың ни, Өммегөлсем?

— Шартым шул, агай: яшь әтәч суръте чигелгән бу сөлгем яшьләрдән беренче булганга бирелсен иде.

— Авызыңа бал, кызым. Шартың үтәлер.

Ниһаять, көтелгән көн килеп җитте. Чишмәле тау, кояш агач буе күтәрелергә өлгермәс борын, халык белән кайный башлады. Ерактан караганда, тау итәге төрле төстәге чәчәкләр белән бизәлгән диярсең. Яшь киленнәр, кыз-кыркын аеруча чибәр киенгән. Күлмәкләрнең бик алы да, җете кызылы да, куе зәңгәре дә, ачык сарысы да бар монда. Күңелләрне җилкендереп, чылтыр-чылтыр иткән көмеш чулпылар, алар янындагы елык-елык тасмалар, чуклы, энҗеле калфаклар... Тирә-як авыллардан да күп килгәннәр шикелле. Халык белән мыжлап торган мәйданнан читтәрәк тәртәләрен югары күтәреп бәйләп куелган арбаларның да чутына чыгарлык түгел. Аннары галоштыр-чүәктер, иләктер-чиләктер, сыра, квас, төрле тәмле-тәмле нәрсәләр сата торган лареклар һәм гармун уйнап җибәрүгә чаң-чаң итеп әйләнә башлаган түгәрәк түбәле карусельгә чаклы китергәннәр хәтта. Болары район үзәге Красный Бордан икән. Мондый нәрсәләр Тегермәнлек малайларына башка елларда тәтеми торган иде.

Алар катык салынган савытлардан авыз белән акча эзләүчеләр янына тукталдылар. Күзләре генә күренеп торган, онга төшкән тараканны хәтерләткән бу шамакайлардан халык тәгәрәп-тәгәрәп көлә. Бер үк савытка бер-бер артлы дүрт-биш кешенең тыгылуын күреп, ахры, ап-ак халатлы ике хатын бу уенны туктатырга кушкач, Барыйлар капчык киеп йөгерүчеләр ягына юнәлделәр.

Менә чыгам, менә чыгам дип исәрләнеп шактый вакыт чирәмдә утыргач, ниһаять, Барый түзмәде, мәйданга чыкты. Иягенә чаклы җитәрлек капчык киерттеләр. Ул — соңгы дүрт парның берсе. Арада бу төр уен буенча узган ел батыр калган Югары Тегермәнлек малае Гыйльми дә бар. Аның янәшәсендә Гадел, икенче ягында Барый. Кем җиңәр?

Сыбызгы сызгыруга, малайлар тыпыр-тыпыр йөгерә башладылар. Барый иплән кенә йөгерде. Аны узып киттеләр. Тик менә бер малай аяклары чуалып егылды, аннары икенчесе, өченчесе... Менә Барый берәүне узып китте, тагын кемнедер узды, тагын... Хәзер өчәү ярыша башладылар. Халык аларга куәт биреп тора.

— Ай-ли бу Гыйльми, матур баса түгелме?

— Сынатма, Гадел!

— Чиерт борыннарына, Барый җаным!
— Уз, уз тизрәк, безгә синнән шул кирәк!
— Уз, Барый, и — баста!

Барый шатлыгыннан чак-чак кычкырып җибәрмәде: Прокофий дәдә дә килгән. Күңеле шат чакларда әйтә ул әнә шул сүзләрне... Аның аяклары кызурак хәрәкәтләнделәр, гәүдәсе җиңеләеп калгандай булды. Башта Гаделне узды, аннары Гыйльмине. Халык гөр килде.

хәрәмләү — хәйләләү, алдау, ялганлау
җәмәгать — халык төркеме, кешеләр төркеме, халык
затлы — кыйммәтле, асыл

Сораулар һәм биремнәр

1. Барый нинди бәйрәмгә әзерләнә?
2. Барыйның чәчәкләр ятатуы турында сөйләгез. Чәчәкләрнең «сөйли» белү серләрен ул кайда өйрәнгән? Шул юлларны табып укыгыз.
3. *Күзләре очкынланып китте, күзләре уттай яна* фразеологик әйтелмәләрен ничек аңлыйсыз?
4. Бүлеккә исем куегыз, эчтәлеген сөйләгез.

II

Барый исәп-хисапка мәктәптә чакта ук бик һәвәс иде. Шалт-шолт иттереп счет тарта белүе дә бик ярап куйды. Кыскасы, идарәдә эшли башлавына биш-алты ай үтәр-үтмәс, ул хисапчы ярдәмчесе вазифасын «су кебек эчә» иде инде. Колхозчылар да, председатель Нәҗип Гарипов та егеттән бик канәгать иделәр. Эчми, тартмый, ут кебек өлгер, пөхтә... Тагын ни кирәк председательгә? Ул хәтта Барыйны баш бухгалтерлар курсына укырга җибәрергә ниятләвен дә сиздерде. Ләкин укырга китәргә туры килмәде Барыйга.

Якшәмбе өмәсенә печәнгә чыккан халык, Сәләхи карт китергән шомлы хәбәрне ишеткәч, тырма-чалгысын күтәреп авылга чапты.

— Сугыш!

Тегермәнлектән беренче көнне үк утызлап кешене озаттылар. Аннары көн саен шул хәл. Андрей Петрович белән Миңлевәли бер көнне чыгып киттеләр. Күп тә үтмәде, Гани абзыйга да чират җитте. Колхозда ныгытып эшләр кеше, рәтле ат

калмады. Карт-коры, малай-шалай, кыз-кыркын кырда кунып-төнеп эшләделәр, ат урынына сыер җиктеләр, ипи урынына туяр-туймас бәрәңге ашадылар. Түзде халык, ыңгырашмады. Фронт сораганның барысын бирә торды. Тир түгеп, хәсрәт йотып үстерелгән уңышны җыеп алырга шәһәр кешеләре булыштылар.

1943 елның январенда Барый да солдат булды. Өч атна Казанда яттылар.

Озакламыйча, аларны фронтка җибәрделәр. Барый да, Краснов та Витебск тирәсенә эләктеләр. Биредәге гаскәрләр шактый вакыттан бирле оборонада торалар иде инде. Саф көчләр килеп кушылгач, сугыш хәрәкәтләре көчәя төште. Ләкин кара-каршы атышлар гына иде әле алар.

Барый ике көннең берендә диярлек Тегермәнлеккә хат яза торды. Бер хаты әнисенә булса, икенчесе... Тиздән авылдан әтисенең үлгән хәбәре килүен белдерделәр. Шаян тонда хат язулар онытылды, уйчанланып, басынкыланып калды Барый.

һәвәс — оста, сәләтле
вазифа — берәр эш һәм шуңа бәйле бурычлар
күнекмә — осталык, сәләт
уйчанлану — уйга бирелү, уйга бату, моңсулану
басынкылану — тынып, җитдиләнеп калу

Сораулар һәм бирем

1. Барый кем булып эшли һәм үз вазифасын ничек башкара?
2. Авылга нинди шомлы хәбәр килә?
3. Барый кайчан фронтка китә?
4. Әтисенең сугышта үлү хәбәре Барыйга ничек тәэсир итә?
5. Бүлеккә исем куегыз һәм эчтәлеген сөйләгез.

III

Апрель ахырларына таба 31 нче гвардия дивизиясе, айлар буе биләп торган позициясен калдырып, тылгарак күчте. Полкларга өстәмә көчләр һәм яңа кораллар алынды. Солдатларның хәрби әзерлеген күтәрү буенча күнегүләр үткәрелә башлады, һөҗүм көтеп торганда, яңадан өйрәнүләргә йөрергә мәҗбүр булган карт гвардия сыкранырга ук тотынды. Көннәрдән бер көнне генерал Галицкий борчылган күңелләргә үзе килеп кенә тынычлык бирде:

— Тылда озак ятмассыз, бөркетләр!— диде ул тигез сафларны карап узганда.— Кузгалырбыз. Хәл җыеп калыгыз. Туктап торырга туры килмәячәк. Кыз-зу булыр! Ә кулыгыз кычытса, задание шул: күршеләргә булышырсыз. Урман эчендә аэродромнар төзергә кирәк.

Генерал китүгә, Барыйлар полкы маршка чыкты. Өч көн, өч төн чегәннәр кебек төялешеп урман кичтеләр. Билгеләнгән урынга барып җиткәч, ял бирерләр дип өметләнгәннәр иде, булмады. Эшкә керештеләр: агач аудардылар, төпләрне казып чыгардылар, чокырларны тигезләделәр.

Барый үзен туган якларга әйләнеп кайткан төсле хис итте. Балта тотып эшләүгә чаклы сагындыра икән ул. Күнегелгән гадәт буенча, агачларны, турап, штабельләргә салдылар. «Сугыш бит, һәммәсен каплар»,— дип, халык байлыгына исләре китмичә караучы кайбер солдатларны Барый утлы табага бастырды.

— Яндырылган авылларны онытмагыз!— диде ул.— Сыңар казык та калмаган. Һәммәсен яңабаштан төзергә туры киләчәк. Коры штабельләрне килеп тапкач, мең-мең рәхмәт әйтерләр. Бәлки әле, бу утын белән мәктәп җылытырлар...

Чыршы ылысларыннан шалашлар әмәлләделәр. Аста ылыс, мендәр урынына ылыс — рәхәтләнде солдат халкы урман табигатендә. Алсуланып таң атканда, сандугач сайраулары уятты үзләрен. Татлы уйларны туган якларга алып киткән бу сихри моңнар тәмам үзәкләрне өзде. Кайсылары, авыр сулап, әрәмәдә печән чапканын, кызлар белән уйнап-көлеп җиләк җыйганын искә алды, кайсылары шундый иртәләрдә урман буйларында койрык чәнчеп йөгерешкән кырыкмыш тайларын юксынды.

Сәләхи карт шомлы хәбәр китергән көн күз алдына килде Барыйның. Печән өсте иде. Икенче елны да шул ук болынга чыктылар. Гайрәтле ирләр дә, типсә тимер өзәрлек егетләр дә юк иде бу юлы болында. Кияүгә чыгып тол калган яшь киленнәр, әле кайчан гына күз җитүгә кызыл туйлар өмет иткән җиләктәй кызлар, капкалап алырга туктаганда, кибән ышыгына утырып, моңсу җыр башлыйлар иде, фронттан җылы хәбәрләр көтәләр иде.

Егете янында булгангадыр инде, Нурҗиһан моңсу җыр җырлаучылар яныннан гел кача иде. Үзе белән Барыйны да аулакка сөйри. Шундый бер очрашуда, суга таба бөгелеп

үскән өянке өстенә утырып, Нурҗиһан гаҗәеп матур җыр җырлады:

Болыннарда йөрим сине көтеп,
Болыннарда сагыш онтыла.
Сайрый тургай — моңланмаска куша,
Күңел сиңа гына омтыла.
Чәчәк җыеп, чәчәк тотып,
Мин килермен каршыңа.
Мин ул хыялыңда йөргән
Бердәнбер тиң яр сиңа!
Бүләк итәр идем сиңа, бәгърем,
Тәүге чәчәкләрнең барысын да.
Тәүге чәчәкләрдән дә назлырак
Керсез мәхәббәтем бар сиңа...

Эх, кайтасы иде хәзер туган якларга! Юк шул, фашистларны җиңми торып, бу мөмкин түгел. Ә җиңү үзлегеннән килмәячәк. Һәр солдат белә: бәлки, шушы җиңү хакына ул кайдадыр ятып калыр, мондый матур таңнарны һичкайчан күрергә туры килмәс... Егерме яшькә дә җитмичә кабергә керүдән авыр нәрсә бармы икән?! Яши башламас борын... Юк, үлем турында уйламаска кирәк! Тик ничек уйламыйсың ди? Әнә еракта-еракта туплар гөрселди, бомбалар шартлый башлады.

Кинәт урман эчендә гүя бик каты күк күкрәде. Кояш көлеп торган зәңгәр күктән сызгырып ракеталар үтте, снарядлар ухылдады, миналар чинады. Күкрәү, шартлаулар көчәйгәннән-көчәйде. Аяк астындагы җир таган атынгандай чайкалды, калтыранды, ыңгырашты. Колаклар ишетмәс, күзләр күрмәс булды. Әле берничә минут кына элек күктә елмайган кояш каядыр еракта — төтен, тузан эчендә калды.

Немецлар артиллериясе дә җавап уты ачты. Дөнья хәзер тәмам мәхшәргә әверелде. Снарядлар әле алга, әле артка төшеп ярылдылар. Биткә пешереп ала торган һава дулкыны, ком, балчык бураны бәрелде. Вакыт-вакыт туфрак фонтаны окоптагыларны күмеп китте. Көнме, төнме икәнен аеру кыенлашты. Вакыт исәбе чуалды. Бу атыш күпме дәвам итә инде — моны берәү дә өзеп кенә әйтә алмас булды. Шунысы ачык: якында гына снаряд шартлаган саен тәнгә салкын йөгертеп, акылны исәрләндерә торган шомланулар, газаплар башланганга инде әллә ни гомер. Бик куркыныч төшме икән әллә бу? Алай дисәң, куркыныч төшнең иң коточкыч җирендә уянып китәсең... Аннары, тирләгән маңгаеңны сөртеп,

ярый әле бу хәлләр төштә генә булган дип сөенәсең. Юк, бу төш түгел, бу мәхшәрнең бетәсе дә, төгәлләнәсе дә юк, ахры...

Баш очыннан сыерчыклар көтүе шикелле бер төркем самолетлар үтте. Шартлаулар тагын көчәя төште.

Барый җиргә ныграк сыенды. Күзләрен чытырдатып йомды, колакларын томалады. Хәер, алар барыбер ишетми иделәр инде. Йоклап китәсе иде хәзер... Тагын якында гына снаряд ярылды, монысы — янәшәдә үк. Димәк, өченчесе... Ул өскә килеп төшсә, нәрсә була икән? Үлем... Бу турыда уйламаска кирәк.

Кинәт Барый граната кыйпылчыклары умырып-умырып алган иләмсез дзотның әкиятләрдә сөйләнә торган дию пәриенеке төсле киң авызыннан кабат давыллы ут төкереп ятуын күрде.

— Юк, албасты, җиңә алмассың! Әле барысы да бетмәде...— Барый сул кулын йөрәк өстендәге кесәгә куйды, бармакларының каты нәрсәгә кагылуын тойды. Ул үлмәячәк, туган җирнең изге туфрагы аңа көч бирәчәк...

Барый сикереп торды, аякларны нәрсәдер пешереп узды, тик бернинди авырту тоймады ул. Менә... амбразура... сулу алырга мөмкинлек калмады... Төтен... Бу — пулемет төтене. Күкрәктә...

Ильченко барысын да күреп торды, егетне туктатырга чамалап кычкырырга теләде, теле әйләнмәде. Үлемсезлеккә атлаучыны туктатырга беркемнең хакы юклыгын аңлады ул.

Барый күкрәге белән дзот амбразурасын томалады. Ату тукталды.

— Ватан өчен, азатлык өчен! Алга!

Артта яңадан «ур-ра» тавышлары яңгырады. Ләкин батыр егетнең җансыз гәүдәсен штык белән амбразура алдыннан төртеп төшергән мәкерле дошман яңадан атарга тотынды. Барый, уң кулын амбразурага сузып, күккә карап ята, гүя нәрсә эшләргә кирәклеген күрсәтә...

Вакулюк сикереп торды, аңа Корычбаев иярде.

Шулчак Ильченко тавышы яңгырады:

— Пулемет, капла! Живо!

Вакулюк күзләрен тотып авып төште. Ярсыган Корычбаев пулеметка ятты. Әнә ул да тынып калды.

Өч-дүрт адымда гына дзот. Өч-дүрт адымда гына уң кулын амбразурага таба сузган Барый Шәвәлиев чалкан ята. Барый хәзер аңа терәк булачак. Төртеп төшерә алмаячаклар.

Ильченко татар егетенең кочагына ташланды, киң күкрәге белән амбразураны каплады. Пулемет карт эт кебек ырылдады-ырылдады да, тамагына сөяк кадалгандай, төелеп, тынып калды.

Иңкүлектә тагын көчле «ур-ра» яңгырады... Штык сугышы башланды.

Сугышчылар сөекле командирлары өчен дошманнан аяусыз үч алдылар. Дзотларга, өч катлы траншеяларга поскан бер генә фашист та исән калмады. Безнең частьлар алга ыргылдылар. 95 нче гвардия полкы, дошманның көчле оборона ныгытмаларын өзеп, тугыз километрга эчкә үтте. Туктамадылар. Арттан яңадан-яңа көчләр килде.

Язгы ташкын шикелле үзенә юл ярып барган зур көчне дошман ничаклы гына тырышса да туктата алмады. Фашистлар өне — рейхстаг өстенә Җиңү байрагы кадаган хәлиткеч һөҗүм әнә шулай башланды.

* * *

...Кичкә таба санитарлар күзләре яраланган бер сугышчыны тынып калган дзот янына алып килделәр. Үлекләрне җыеп күмүгә яңа керешкәннәр генә иде әле. Яралы сугышчы чайкала-чайкала дзот алдына килде, бетон стенаны капмалап, амбразурага иелде һәм, мәңгелек дуслыкны беркеткән төсле, бер-берсен кочаклап йокыга талган ике җансыз гәүдә өстенә ятып, елап җибәрде...

Иртән авыл читендәге туганнар кабере өстенә чәчәк бәйләмнәре китерделәр. Алар шиңмиләр — халык аларны көн саен алмаштырып тора. Чәчәкләр җилдә тирбәлә, чәчәкләр ир-егеткә булган ил ихтирамы турында сөйлиләр...

ыңгырашу — әрнүле авазлар чыгару
мәхшәр — ыгы-зыгы, шау-шу, буталыш
томалау — каплау
мәкерле — эчкерле, астыртын

Сораулар һәм биремнәр

1. Каты сугыш барганда да, Барый нәрсә турында уйлый?
2. Немецларның һөҗүменә каршы ул нинди кыю адым ясый? Аңа ярдәмгә кем килә?

3. Барый — кыю, батыр, түземле, үз илен яратучы егет. Бу сыйфатларны ул үзендә ничек тәрбияләгән?
4. Дошман амбразурасын күкрәге белән каплаган тагын кемнәрне беләсез?
5. Бүлеккә исем куегыз. Эчтәлеген сөйләгез.

«Син батырлыкны ничек аңлыйсың?» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Нәрсә ул батырлык?
2. Батырлык эшләү өчен нинди сыйфатлар кирәк?
3. Батырлыкны тыныч тормышта эшләп буламы?
4. Батырлык эшләү өчен үзеңне ничек чыныктырырга кирәк?
5. Батырлык турында нинди китаплар укыганыгыз бар?
6. Батырлык турында нинди мәкальләр, әйтемнәр беләсез?

Мәкальләр һәм әйтемнәр

* Батыр яуда беленер.
* Ат — дагасыз, батыр ярасыз булмый.
* Батырга үлем юк.
* Батыр әйтмәс, әйтсә — кайтмас.
* Батырлыкта — матурлык.
* Батыр туса — ил бәхете, яңгыр яуса — җир бәхете.

Атилла Расих

(1915—1996)

Атилла Расих (Атилла Кадыйр улы Рәсүлев) 1915 елның 16 сентябрендә Төркиянең Истанбул шәһәрендә туа. 1918 елда аларның гаиләсе хәзерге Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәренә, 1928 елда Казанга күчеп кайта. Казанда ул ветеринария институтын тәмамлый. 1940 елда хәрби хезмәткә чакырыла. 1941—1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950 елда аспирантура тәмамлап, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Шуннан бирле аның хезмәте ветеринария институты белән бәйләнгән. 1976 елдан ул тулысынча әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

А. Расихның беренче хикәясе 1930 елда басыла. Шуннан бирле ул туктаусыз иҗат итә, хикәяләре, повесть һәм романнары бер-бер артлы басылып килә. Укучылар аның әсәрләрен җылы каршылыйлар, яратып укыйлар. Чөнки әдип һәрвакыт заманның иң мөһим мәсьәләләрен күтәрә. Үзе яхшы белгән тормыш турында ышандырырлык итеп яза. «Дустым Мансур», «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Сынау» романнарында, «Ык буенда» повестенда әйтерсең лә нәкъ менә язучы үзе катнашкан вакыйгалар сурәтләнә.

Атилла Расих халкыбыз бәхете өчен көрәшкә гомерен багышлаган, хатыны Хәдичә белән берлектә татар телендә «Урал» исемле газета чыгарган Хөсәен Ямашев турында роман-трилогия яза. «Каһарманнар юлы» романы да үз укучыларын таба.

Язучының «Бәхет орлыклары», «Урланган хәзинә», «Хәвефле сынау», «Сәхи бабай маҗаралары», «Ишан оныгы» әсәрләрен дә укучылар яратып укыйлар.

Язучының хезмәтләре югары бәяләнә. Аңа 1982 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Атилла Расих 1996 елның 9 маенда Казанда вафат була.

«Ишан оныгы» романы турында

Язучы бу әсәрен бала чагы, әти-әнисе, бабасы турындагы истәлекләргә нигезләнеп яза. Аның бабасы Зәйнулла ишанны халык бик хөрмәт итә. Ул гомере буе мәдрәсәдә укыта. Аның мәдрәсәсендә күренекле кешеләр, шул исәптән Мәҗит Гафури да белем ала. Зәйнулла ишан турында газеталарда да языла. «Кояш» газетасы аның турындагы мәкаләне шундый сүзләр белән тәмамлый: «Киң холыклы, юмарт куллы, хуш мәҗлесле мәрхүм үзенең соңгы гомерендә дә мәдрәсәне онытмады. Аның матди җәһәтен тәэмин итү мәсьәләсен кузгатып, мәзкүр мәдрәсәгә башлап үзе ун мең сум һидия итте. Ходаның рәхмәтендә булсын».

Атилланың әти-әнисе дә укытучылар була. Әнисе Зәйтүнә — бөек шагыйрь Габдулла Тукай белән дә таныш кеше. Тукай аңа багышлап шигырьләр дә язган.

Әтисе 1922—1928 елларда мулла була. Совет хакимиятенең динне чикләве сәбәпле, гаиләсенә кыенлыклар килә. Аның улын, мулла малае булганы өчен, югары уку йортларына алмыйлар. Ветеринария институтына укырга кергәндә дә ул, чыгышын яшереп, анкетага хезмәткәр баласы дип яза. Шулай итеп, Атилла институтта уку бәхетенә ирешә. Әмма бу бәхет озакка бармый, аны, мулла малае дип, институттан чыгаралар. Аның бик тә белем аласы килә, һәм ул, гаделлек эзләп, Мәскәүгә китә. Гаҗәпкә каршы, Мәскәү комиссиясе мәсьәләне уңай хәл итә, ул укырга кире алына. Атилланың әнисе дә Казан педагогия институтының кичке бүлегендә укый, ләкин аны да институттан куалар. Атилла Мәскәүдән яхшы хәбәр белән кайткач, алар Мария Ильинична Ульяновага хат язалар, һәм аннан уңай җавап килә. Аның әнисе татар теле һәм әдәбияты бүлеген язучы Абдулла Әхмәт, Шәйхи Маннурлар белән бергә уңышлы тәмамлап чыга.

ИШАН ОНЫГЫ

(өзекләр)

I

Термез шәһәреннән Казанга 1934 елның июль аенда, юкә чәчәк аткан чакта кайтып төштем. Казан ифрат сагындырган. Мондагы һәрбер нәрсә — ишегалдындагы агачлар да, чарлактагы бәләкәй бүлмәбез дә, каршыдагы базар кибетләре дә (әнием турында әйткән дә юк инде) — барысы-барысы үзләренең күренешләре белән үк миңа ял рәхәте бирәләр. Теләгем — хәзер инде укырга керү. Ярар, бераз дөнья күрдем, читят җирләрдә «лаеш шулпасы» эчеп бактым. Хәзер күптәнге теләгемне тормышка ашыру эшенә керешергә вакыттыр. Укырга, укырга, укырга! Минем әле генә ачылган авиация институтына керергә теләгем зур. Гомумән, мәктәп елларында төгәл фәннәрне якын иттем һәм ул өлкәдә үземне сәләтле бер кеше дип саный идем. Инде Казанда авиация институты ачылгач, минем иң изге теләгем шул институтка укырга керү булды. Нигә бәхетемне сынап карамаска?! Минем урта белемем бар ич.

Казанга исән-сау әйләнеп кайтуыма чиксез шатланган әниемнең хуплавы белән канатланып, тиз арада кирәкле документларны барлыйм, анкета тутырам һәм, кайтуыма атна-ун көн дә узмый, үзем керергә җыенган институтка йөгерәм.

Институтка нинди хыяллар белән ашкынып баруымны, тетрәнеп, аның авыр ишеген ачуымны, калтыранган кул белән папкадан документлар чыгаруымны, аларны кабул итү комиссиясе секретарена тапшыруымны ничек тә төгәл, жанлы һәм ышандырырлык итеп язып булмас кебек. Мин артык дулкынланам. Алырлармы, студент дигән гүзәл исемне йөртүче булырмынмы тиздән?

Әмма миңа уку йортына керү насыйп түгел икән. Чөнки бу өметләр, секретарь өстәле янында ук сүнеп, һавага очты. Кабул итү комиссиясенең кырыс карашлы, өстенә юнгштурм костюмы кигән секретарь анкетамны карап чыкты да, бик гади генә итеп:

— Без мондый кешеләрне алмыйбыз,— диде.

— Ни өчен?— дидем мин, тәмам аяктан кала язып.

— Чыгыш бит сезнең... үзегез беләсез,— диде ул, бер яңагы белән генә елмаеп.

Мин тәмам коелып төштем. Документларымны папкага ничек салганымны да тоймастан, йөгерә-атлый бүлмәдән чыгып киттем. Юк, булмады! Миңа институтларда укырга язмаган икән. Яңадан эшкә керергә туры килер. Урта Азиягә киткәнче, токарь булып Вахитов исемендәге сабын кайнату заводында эшли идем. Без яшәгән Арча кырыннан ул заводка эшкә йөрүләре шактый авыр, ара ерак, трамвайлар бик начар йөри. Мин шул хәлләрне искә алам. Шуңа күрә үзебезгә якынрак булган трамвай паркына урнашырга кирәк, дигән фикергә киләм.

Мин трампаркка кереп эшли башладым. Тик шулай да күңел тыныч түгел. Укыйсы килә. Ни өчен соң әле минем укырга хакым юк? Ни өчен, ни өчен? Әллә башкалардан кимме мин? Шулай гомере буе әтисе өчен җәзаланырга тиеш микәнни аның улы?

Җитмәсә, трампаркта эшем дә бик көйсез бара. Станокның иң начары янына бастырдылар. Эш кораллары да ... ташка үлчим.

Әмма шулай да көннәр бер-бер артлы уза тора. Һәм шул көннәрнең берсендә, һич уйламаганда-көтмәгәндә, минем сүнгән өмет йолдызым кабат җемелдәп яктыра башлады.

Шулай эшкә керешүемә атна-ун көн үтмәгәндер, көндезге ашка дип өйгә кайтсам, ни күрим, тимер караватымда бер егет йоклап ята. Димәк, безгә ниндидер бик якын кеше килгән. Ул бик алҗыган булган, йокысызлыктан интеккән, ахры. Чөнки көпә-көндез нинди йоклау инде ул? Әнием исә, ничектер серле итеп елмаеп, миннән сорый:

— Я, кем бу, таныйсыңмы?

Аптырап, иңбашларымны гына җыерам. Егет, уянып, миңа кулын сузгач кына, аның кем икәнлеге беленә: бу — миңа күптәннән таныш Шәүкәт Корбангалиев икән. Шәүкәт — Троицк егете, бергә уйнап үскән малай дигәндәй, әтиләр үзара аралашкан, йөрешкән укытучы Вәли абзый улы. Без күрешмичә яшәгән елларда ул үскән, җитлеккән, авыл хуҗалыгы техникумын тәмамларга өлгергән, бер совхозда ике ел агроном булып эшләгән, хәзер исә Казанга авыл хуҗалыгы институтына укырга килгән.

Безнең җитди сөйләшү, көн тәмамлангач, кичкырын башланды. Ул мин юкта әнием белән барысы турында да сөйләшкән, минем хәл-әхвәлләрнең торышын белә икән. Шәүкәт сүзне миңа укырга кирәклеген, хәзер минем нәкъ укый торган вакытым икәнлеген аңлатудан башлады.

— Беләм,— дидем.— Әгәр мине укырга алмыйлар икән, нишләмәк кирәк? Әтинең алты ел Троицкида мулла булып торуы аркасында, мине сыйнфый дошман дип саныйлар икән, мин нишли алам?

Шәүкәткә, төкми-чәчми, барын да сөйләдем. Шәүкәт минем аһ-зарымны тыныч кына тыңлап торды. Шуннан соң әйтте:

— Беләсеңме нәрсә, Атиллә,— диде (миңа өйдә дә, Троицк кешеләре дә шулай, исемемнең азагындагы «а»ны, нечкәртеп, «ә»гә охшатып дәшәләр иде).— Бер дә ут йотма. Документларыңны әзерлә, аларны институтка үзем илтеп бирәм. Без синең белән икебез дә авыл хуҗалыгы институтына керәбез. Честный слова, алмый калмаслар...

— Ә минем чыгыш мәсьәләсе?— дидем мин.

— Син аны яшер, әйтмә. Анкетага хезмәткәр баласы, дип куй. Әллә кайдагы Троицк кешеләрен кем белсен?!

Нинди генә юллар белән булса да институтка эләгү минем өчен бик мавыктыргыч теләк иде. Ләкин шулай да алдашу дигән нәрсәгә җинаять эшләү дип карыйм. Мин:

— Бәлки, шулай кирәктер дә, тик элек укыганнар онытылган инде,— дигән булдым.— Кайчаннан бирле инде кулга дәреслек алган юк. Барыбер имтихан бирә алмам дип уйлыйм.

— Бирәсең,— диде Шәүкәт зур ышаныч белән.— Тик документларыңны иртәгә үк институтка тапшырырга кирәк. Чөнки анда абитуриентлар өчен әзерлек курслары ачылган. Алар укый башлаганнар инде. Шунда керәбез. Белдеңме?

— Белмим инде, нишләргә дә белмим,— дидем икеләнеп. Минем нинди дә булса берәр техник вузга керәсем килә иде. ФЗӨдә уку һәм заводта токарь булып эшләү чорында мин инде техникага тәмам гашыйк кеше хәленә күтәрелгән идем. Өстәвенә, уйлап табучылык белән дә «җенләнүем» машиналарга, механизмнарга булган мәхәббәтемне көчәйтте генә.

Уйга калдым. Ләкин бит мине берәү дә техник вузга чакырып тормый. Ә монда, Шәүкәтнең әйтүенә караганда, авыл хуҗалыгы институтына эләгүем бик мөмкин. Бу турыда әни белән дә киңәштем. Ахыр чиктә минем төп максатым югары белем алу түгелмени? Авыл хуҗалыгы белгече булу ни дә, төгәл фәннәр буенча белгеч булу ни?! Иң мөһиме — белем алу ич!

Шулай итеп, мин йомшадым. Карышып торуны кирәк санамадым. Әгәр сәләтле кеше икәнмен, теләсә кайда да

сынатмам, ә инде һөнәремә мәхәббәт дигән нәрсә дә өстәлсә, эшләр мантымый калмас. Шулай фикер йөрттем дә, Шәүкәтнең киңәшен дөрес табып, документларымны яңадан барлап чыктым. Яңабаштан анкета тутырдым, өр-яңа үтенеч яздым.

Кешегә сылтап гөнаһлы буласым килми, төп гаеп үземдә.

Чыгышымны анкетада яшердем мин. Авыз бер тапкыр пеште бит инде, җитәр, дип акландым.

Һәм бу эшемнең җәзасын тугыз ай институтта укыганнан соң татыдым...

Мин чиксез бәхетле идем. Иң олы максатыма ирештем. Хәзер барлык көчемә яшьлек дәртемне кушып, ашкынуларымны өстәп, укырга да укырга тиешмен, дип юана идем. Тик, кызганычка каршы, минем өчен бу бәхетле көннәр санаулы булган икән.

Шатлыклы, чәчәкле Май бәйрәменнән соң бер атна узмагандыр, мине дәрес вакытында институт директорына чакырдылар. Күңелем нидер сизенеп, шунда ук йөрәгем дерт итеп куйды. Бу чакырылу, һәрхәлдә, хәерлегә түгел иде...

Институт директоры булып, ул вакытта Соловьев фамилияле керәшен татары эшли иде. Урта буйлы, чибәр генә, түгәрәк кысалы күзлек киеп йөри торган урта яшьләрдәге бер кеше иде ул. Әле күптән түгел генә Май бәйрәме мөнәсәбәте белән студентлар сафы алдында безгә нотык сөйләде. Өстендә кара пальто, башында кепка, кулында трость. Ул, ялтыр резин галошларына туфрак чәчрәтеп, таяк очы белән җиргә бәрә-бәрә сөйли:

— Әгәр сугыш башланса,— ди ул,— без барыбыз да иптәш Ворошилов яклы булырбыз!

Әнә ул, мине чакырткан кеше, хәзер кәгазьләр актарып, үзенең яландай зур яшел постау өстәле артында утыра. Озакламый ул миңа үзенең үтергеч сүзен әйтәчәк.

— Мондарак кил,— диде ул, мине сискәндереп. Аның күзләрендә нәфрәттән башка берни дә юк кебек иде. Мин аңа таба атлыйм. Хәзер инде күңел түремдә тычкан уты кадәр генә дә өмет яктысы калмаган. Чөнки күз кырыем белән Соловьев алдында яткан анкетамны шәйлим.

— Әйт әле, синең әтиең кем булган?— диде ул шул кырыслык белән.

— Укытучы,— дим мин, чөнки, чыннан да, минем әти гомеренең күбрәк өлешен укытучылыкта уздырган.

Директор авыз чите белән генә мәсхәрәле елмаеп куйды. Миңа бик ачык сизелә: ул җиңү тантанасы кичерә.

— Ә егерме икенче елдан егерме сигезенче елга кадәр?

— Мулла,— дип куйдым мин шыпырт кына.

— Ә нигә анкетаңа хезмәткәр дип яздың?

— Дөресен язсам, институтка алмассыз дип курыктым.

Директор минем язмышымны бик тиз хәл итте:

— Совет хөкүмәтен алдаганың өчен, сине институттан сөрәчәкбез. Сиңа тотылган расходларны кайтарып алу өчен, судка бирәчәкбез.

Шуның белән безнең аңлашу тәмам булды, башны аска иеп, кабинеттан чыгып киттем. Барысы да берничә минут эчендә җимерелеп төште. Барлык ашкынулар, татлы хыяллар, гүзәл планнар...

Кечкенәдән үк укырга, укырга кирәк, дигән тәрбия алган идем шул. Әти дә, әни дә минем, укып, илгә бик файдалы, зур кеше булуымны телиләр иде. Инде миңа юллар ябык, ябык, ябык! Нишләргә соң миңа? Башымда чиксез зур кайгы булып оеган кан, шаулап, чыжылдап, бөтен миләремне пешереп, каядыр өскә үрләде.

Институтның якты, иркен коридорына чыктым да, кая барырга, инде нишләргә белмәүдән аптырап, капкадай зур якты тәрәзә төбенә килеп сөялдем. Юк, миңа урамдагы хәрәкәт күренми, минем колакларыма тирә-юньдәге шат кешеләрнең көлешү-сөйләшүләре ишетелми. Минем бөтен барлыгымны хәсрәт сөреме баскан.

Шулай да таркалган зиһенемне бераздан җыя алдым булса кирәк, һәрхәлдә, үземә бер таяныч табарлык хәлгә килдем. Институттан куылсам да, югары мәктәптә уку насыйп булмаса да, мин бит әле исән, мине бит әле үтермәделәр. Мин бит әле яшим, мин бит әле яңадан станок янына баса алам, рәхәтләнеп эшли алам.

Шулай уйлап, күңелемнән барысына кул селтәдем дә коридор буйлап алга таба киттем.

Белдерүләр тактасы янында ике студент нидер укып тора. Алар миңа борылып карангалыйлар. Күзләрендә исә аптырау, шом. Узышлый, күзгә әле генә эленгән приказ чалына. Анда минем турыда, явыз ният белән чыгышымны яшергән өчен институттан куылуым, судка биреләчәгем турында язылган. Мин хәзер үк, хәзер үк, өч-дүрт баскычны бер атлап, аска, урам ишегенә таба төшеп китәргә риза. Тик иптәшләрем

утырган ботаника кафедрасына керми булмый. Минем анда портфелем калды. Аны миңа институтка керү имтиханын уңышлы бирүем белән котлап, барлы-юклы акчасына әнием сатып алган иде. Ул — минем өчен бик кадерле бүләк. Әле генә үзем гербарийлар карап утырган аудиториягә керәм. Анда өстәлләр тирәсендә студентлар кайнаша. Мин килеп керү белән, аудиториядә авыр, котсыз тынлык урнашты. Иптәшләрем, эшләрен ташлап, кайсы аптырау, кайсы кызгану аша миңа текәлгәннәр. Алар минем һәр хәрәкәтемне бизмәнгә салып үлчиләр кебек. Тиз генә өстәл тартмасыннан портфелемне алам да коридорга ташланам. Сизәм, кемдер артымнан килә. Быков Гога. Дус егет. Ул тирә-юненә карана, кеше юклыгыннан файдаланып, миңа якынлаша:

— Атилла, мин бу хәлгә бик хафада...

Ул ашыгып читкә китте. Яныма, шундый ук саклык белән, икенче дустым Газиз Нуриев килеп җитә. Ул — Минзәлә егете. Беренче айларда, әле укуда шактый аксаганда, ярдәмен күп күрдем аның.

— Агайне, Атилла,— ди ул.— Мин... просто ни әйтергә дә белмим инде...

Ул, әйтер сүз таба алмаудан гаҗиз булып, тукталып тора, аның каратутлы матур йөзе кызарган, күзләрендә яшь элпәсе.

Мин, институт белән мәңгегә саубуллашып, урамга чыгам. Һава искиткеч матур, көн аяз, институт бинасына каршы бакчада кошлар чыр-чуы. Ләкин боларның берсе дә миңа куаныч, өмет бирми иде.

Ул көнне, мин институттан куылып кайтып кергәндә, әни өйдә иде. Дәфтәр тикшереп утыра. Ул — укытучы. 18 нче татар мәктәбендә башлангыч класс балаларын укыта. Үзе дә, читтән торып, педагогия институтында укый. Күрәсең, минем хәсрәтем йөземә бәреп чыккан булгандыр, әнием, шундук эшеннән аерылып, сорау белән миңа текәлде. Минем исә аны әз генә дә борчыйсым килми иде. Әмма булдыра алмадым. Портфелемне өстәлгә ташладым да караватыма йөзтүбән сузылып яттым. «Мине институттан куып чыгардылар»,— дидем. Бер мизгел тынлык булып торды. Әнием үзенең көчләрен туплады булса кирәк, мөмкин кадәр тыныч тавыш белән: «Кайгырма, улым, бирешмә, балакаем»,— диде.

Кадерлем, бәгърем минем, бердәнберем, газиз әнием! Синең чандыр, юка гәүдәңә табигать ничек шундый зур көчләр

сыйдырган? Бу минутта, бәлки, башка ана булса, еларга яки мескенләнергә керешер иде. Ләкин минем әни андыйлардан түгел. Ул — көчле, тормыш чыбыркылауларына каршы тора алган, буранга каршы барудан курыкмый торган кеше.

Әни әле моннан ике ел гына элек, Шәле дигән сәер исемле татар авылыннан кайтып, Яңа Бистәдәге татар мәктәбенә урнашты. Ул чакта Шәле Татарстандагы иң караңгы авылларның берсе иде дисәм дә, шәт, ялгышмам. Аның халкы ифрат усал. Ирләре генә түгел, анда хатын-кызлар да оятсыз сүзләр кыстырып сөйләшә. Кеше үтереш, суеш анда еш кабатлана торган бер хәл. Әни шундый авылда укытты. Алай гына да түгел, ул анда шул шомлы авыр көннәрдә колхоз төзү эшендә, тырышып, актив катнашып йөрде. Шундый авыр хезмәттә дә ул мине бер генә минутка да онытмады, авызыннан өзеп, миңа даими рәвештә акча җибәрде, әз генә мөмкинлек чыкса да, шәфкатьле ярдәм кулын сузу өчен, мине күреп, өс-башымны карау өчен, Казанга кайтып китә торган булды.

Инде Шәледән Казанга бөтенләйгә кайткач, ул, бер генә көнен дә әрәм итмәскә тырышып, укуын дәвам иттерде.

Тормыш ифрат авыр. Үзенең «гөнаһ»ларын яшереп, ерак Кыргызстан таулары арасындагы бер колхозда хисапчы булып эшләп яткан әтидән бернинди дә ярдәм юк, әниемнең эш хакы бик аз. Икмәк карточка белән генә бирелә. Ашаган төп ризык — бәрәңге. Аны үсемлек маенда кыздырып ашыйбыз, ит исә — артык тансык ризык, әллә нигә бер эләгә.

Әйе, без фәкыйрь яшәдек. Әни, авылга эшкә китү белән, миңа кул сәгате алып бирү өчен тырышты. Аны кибеткә авыл хуҗалыгы продукты тапшырган кешеләргә бирелә торган талонга гына саталар иде. Әни шул талоннар сатып алу эшенә дә керешеп карады. Мәгәр теләгенә һич ирешә алмады.

Без Вахитов заводы янында бер фатирда яшәгәндә, әниемнең аягына брезент итек киеп кыш уздырганын яхшы хәтерлим. Аның кышкы суыкларда мәктәбеннән кайткач, сызланып, тезләрен уып, мич авызы каршында утырган чакларын онытасым юк. Бу итекне безгә Урта Азиядән кунакка кайткан, әнинең олы абыйсы Шакир абый бүләк иткән иде.

Кыскасы, безнең эшләр «байларски» ук булмады. Ләкин шуңа да карамастан без әниле-уллы үзебезне моңарчы бик бәхетле сизеп яши идек. Нигә дип без бәхетсез булыйк: тормыш — илдәгечә, без һаман үсәбез, укыйбыз, куйган максатка таба тауга үрмәлибез!

Тик бу бәхет бүген, югарыда әйтелгәнчә, боздан ясалган бинадай чытырдап җимерелде. Хәзер инде эшкә урнашу турында баш ватарга кирәк иде.

Мин үземә кулай эш эзләргә керештем. Универсаль токарьлар һәр җирдә кирәк, һәр җирдә белдерү очратырга була. Ләкин күңелгә ятышлы урынны табуы читен. Мин Казан заводларын айкыйм. СК-4 заводы артык ерак, трамвайлар һаман начар йөри. Вахитов заводында эшләгәндә дә җитәрлек газап кичерде кеше. Аерата икенче сменада эшләгәндә өйгә кайтулары авыр. Онытылмый, көне буе аягүрә торып аяклар тала. Шамов больницасы тавыннан менгәндә, алар бүрәнәдәй авыраялар. Шулкадәр ничек йөрмәк кирәк? СК-4 чуттан сызып ташлана. Инде трампарк. Ул безгә бик якын, тик андагы станоклар, әйткәнемчә, ватык арбадай, эш кораллары ярым хөрти. Мин, йөри торгач, Державин бакчасы каршында Агамали углы исемендәге язу машиналары заводын сайладым. Ләкин миңа анда да озак эшләргә туры килмәде. Уенчыктай кеп-кечкенә револьвер станоклар минем өчен бөтенләй кулай түгел. Зур станокларда иркенләп эшләргә өйрәнгән кеше өчен бу авыр гына түгел, хәтта газаплы да икән. Мин тагын эшсез. Төшенке күңел белән йөрим. Җитмәсә, эш эзләп йөргән көннәрдә әниемне дә институттан чыгардылар. Без хәзер, аңа эшләгән җиреннән дә ул-бу булмагае дип, тагын куркуда яшибез.

ифрат — чамадан тыш, бик тә
чарлак — йортның алгы ягында бизәп ясалган балконга охшаш янкорма
манту — уңай нәтиҗәгә ирешү, уңу
шәйләү — чамалау, төшенү, аңлау
сөрү — куу
зиһен — акыл, аң

Сораулар һәм биремнәр

1. Термез шәһәреннән кайткач, Атилла нәрсә турында уйлый?
2. Ул нинди институтка укырга керергә тели?
3. Аны ни өчен укырга алмыйлар?
4. Егет үзенең бәхетен тагын ничек сынап карый? Аны ни өчен институттан куалар?
5. Аның әнисе кем була? Әнисе турында язган урыннарны укыгыз.
6. Өзекнең эчтәлеген сөйләгез.

Гариф Ахунов
(1925—2002)

Татарстан Республикасының халык язучысы Гариф Ахунов (Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов) 1925 елның 18 сентябрендә Татарстанның Арча районы Өчиле авылында крестьян гаиләсендә туа.

Гарифҗан башта күрше Казанбаш авылы мәктәбендә белем ала. Аннары Арча педагогия училищесын тәмамлый. 1947—1952 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Шушы елларда әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый.

Университетны тәмамлагач, биш ел «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә эшли.

1956 елның көзендә ул Әлмәт шәһәренә берьеллык иҗади командировкага китә. Соңыннан бөтенләй шунда күчеп, андагы җанлы тормыш материалы нигезендә очерк, хикәя, кечкенә повестьлар яза. Нефтьчеләр тормышы турында «Хәзинә» (1963) һәм «Хуҗалар» (1968) исемле романнарын иҗат итә. «Хәзинә» романы аны чын-чынлап язучы итеп таныта. Бу роман буенча Свердловск (хәзерге Екатеринбург) киностудиясендә нәфис фильм эшләнә. 1982 елда ул «Кошның да үз оясы була» дигән исемдә Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә куела.

1968 елда Г. Ахунов Казанга кайта. 1971—1974 елларда «Казан утлары» журналында баш редактор булып эшли. 1974 елда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайлана.

Г. Ахунов җитмешенче еллар дәвамында «Чикләвек төше» (1974), «Олы юлга сәяхәт» (1974), «Ардуан батыр» (1975), «Без бит Арча яклары» (1978), «Йолдызлар калка» (1979) һәм башка повестьларын яза. 1978 елда «Идел кызы» исемле трилогиясенең ике кисәген бастыра.

Гариф Ахуновның әдәби эшчәнлеге шактый киң, һәм ул төрле жанрларда иҗат итә. Ул танылган прозаик, җитез журналист, публицист, тәнкыйтьче, тәрҗемәче, драма әсәрләре авторы буларак та билгеле. Төрле елларда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия, Әлмәт, Минзәлә театрлары сәхнәләрендә аның «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта», «Ардуан батыр» һәм башка пьесалары куела. Ул Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен сәхнәләштерә.

Әдипнең хезмәтләре югары бәяләнә. Ул «Чикләвек төше» повесте, «Хәзинә» романы өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1993 елда Татарстанның халык язучысы дигән мактаулы исем бирелә.

Гариф Ахунов 2002 елда Казан шәһәрендә вафат була.

«Идел кызы» романы турында

Гариф Ахуновның «Идел кызы» әсәре ике кисәктән тора. Бу романда 1920—1930 еллардагы катлаулы һәм каршылыклы авыл тормышы сурәтләнә. Моны автор чорның кырыслыгын, гаделсезлекләрне турыдан-туры үз җилкәсендә татыган кешеләр язмышы аша чагылдыра.

Г. Ахунов әлеге әсәрендә муллалар катлавыннан төрле тип кешеләр чыкканын искәртә. Аларны ул өч төркемгә бүлеп карый. Беренчесе — шымчы муллалар. Болар заманында патшага хезмәт иткәннәр, революциядән соң аклар ягына күчкәннәр. Икенче төркемгә автор шагыйрь муллаларны кертә. Дөрестән дә, муллалар арасыннан күренекле әдипләр, галимнәр һәм мәдәният эшлеклеләре чыккан. Өченче төркем муллалар исә мәгърифәт эше белән шөгыльләнгәннәр: гомерләре буена балалар укытканнар, кара халыкны агартырга тырышып яшәгәннәр. Аларга казна акча түләмәгән, алар патша хәзрәтләренең дә сөекле балалары булмаган. Мәгърифәткә булган ихтирам, дөреслекне ачып бирү теләге аларны алга

әйдәгән. Автор шушы төркем вәкилләренә дөрес бәя бирелмәвенә, аларның мондый фидакарь хезмәте искә алынмауга борчыла. Бу хәлне ул әлеге төркемгә караган Габбас мулла мисалында күрсәтә. Гади крестьяннан мулла булып киткән Габбас гомер буе үз көнен үзе күреп яши. Әмма колхозлашу чоры башлангач, аның янгыннан соң мең бәла белән җиткергән соңгы йорты, бөтен мал-мөлкәте тартып алына. Ул хатыны һәм яшь баласы белән мунчада яши башлый. Бердәнбер терәге булган кызы Нурия дә әтисеннән баш тарта.

Кызының шундый мөнәсәбәтен белгән Габбас мулла өчен дөньяда яшәүнең кызыгы бетә. Ул үзен үзе үтерә.

Нурия исә әтисеннән һич тә үз теләге белән баш тартмый, аны бу адымга шул кырыс заман этәрә. Рабфакта укыганда, аның нинди гаиләдән булуы мәсьәләсе күтәрелә. Мулла кызы булганы өчен, аны рабфактан куу турында карар кабул ителә. Әтисеннән ваз кичкәч кенә, ул укуын дәвам итүгә ирешә. Мондый адымнарның ул вакытта хуплануы һәм макталуы әлеге фаҗигане тагын да тирәнәйтә һәм көчәйтә.

«Идел кызы» татар һәм рус телләрендә басылды, аның буенча алты серияле телевизион фильм-спектакль төшерелде.

Флүн Мусиннан

ИДЕЛ КЫЗЫ

(өзекләр)

Беренче башлам

VI

Көн артыннан көн үтә, ел артыннан ел.

Нурия әтисеннән укырга-язарга өйрәнде.

Зураеп, буйчанланып китте. Чәчен ике толым итеп үреп йөртә башлады.

Әтисе белән алар бик дус. Көн саен бер мәртәбә сабак тыңлатып, матур язу дәресе үткәргәннән соң, әтисе аңар Тукайның берәр шигырен ятларга куша.

Нурия китапны шап иттереп яба да аяклы зур көзге артына кереп кача. Әтисе, бүлмә бетереп, тавышланып, аны эзли, эзләп тапкач, шаулап сөенә, көрәктәй зур куллары белән кызын тотып ала. Башыннан сыйпаган чакта, Нурия әтисенең бармаклары кәкре-бөкре булуын күрде.

— Әтием, ә нигә синең бармакларың кәкре?— диде Нурия.

— Мин бик озак урман кистем, кызым, агач төпләдем,— ди әтисе.

— Ә нигә агач төпләдең?

— Ягарга утын кирәк булды.

— Ә нигә менә бу бармагың кыска?

— Без, кызым, бабаң белән кышкы суыкта утын кисә идек, мин туңдым да өйгә керик дип шыңшый башладым. Бабаң керми дә керми. Мин балта белән ярырга дип әзерләгән утын пүләненә кулымны куйдым да: «Кисмик инде бүтән»,— дидем.

Бабаң балтасын селтәп өлгергән икән, тотып кала алмады, минем менә шул бармагымны өзеп чыгарды.

Нурия, әтисен кызганудан, нишләргә дә белми.

— Әти, мин сиңа шигырь сөйләп күрсәтәм, яме?— ди.

— Күрсәт, балам,— ди әтисе.

Нурия күзен йома, башын артка кайшалдыра, иркен зур бүлмәдә аның тавышы яңгырап ишетелә:

> Кыш. Буран. Салкын һава. Яфрак кадәрле кар төшә.
> Җил куа карны, һаман да кар төшәм дип тартыша.

Кар бураннары эченнән биек манаралы мәчет килеп чыга, кызыйның яңгыравыклы нечкә тавышы мәчет янына дөм сукыр бер картны китереп куя; картны кызганудан, аның тавышы өзелеп-калтыранып китә, күз төпләренә эчеттереп яшь бөялә.

Ул тавышы кысылып туктый.

Әтисе аны, күкрәгенә кысып, аркасыннан сыйпый, Нурия инде зур — ун яшендә, аркасыннан сыйпаганга ояла, тартыла, урындык алып, әтисе янына утыра.

Әтисе аңа әкият сөйли. Әкияткә үз тормышын, башыннан кичкәннәрен кушып җибәрә.

Йомшак, куе тавыш Нурияне, тирбәтеп, әллә кайларга, ерак дөньяларга алып китә. Иксез-чиксез казакъ даласы ак болытлар төсле ак тирмәләр белән чуарланган. Яланнарны тутырып, сарык көтүләре йөри, көтүченең чыбыркы шартлатканы ишетелә, ала мүкләк муенындагы кыңгыраулар чыңлый. Казакъ даласын, сарык көтүләрен Нурия үзләренең Заргугай болынына, Бояр урманы буйларына кайтарып куя. Солтан — күрше Садыйк абзый малае — уҗымга чыгып барган сарыкларны куып алып килә.

Бояр урманы янына көтү йөргән урыннарны карарга барганда, и рәхәт тә соң Нуриягә. Солтан җирне казып учак яга, көлгә күмеп бәрәңге пешерә.

— Мулла кызы, бәрәңге ашыйсыңмы?— ди.

Солтан— такыр башлы, каты куллы малай. Нурия кайбер көннәрне, аңа ияреп, тегермән буасы янына төшә.

Тегермән буасы янында вак бака күп. Нурия аларны, и бичаралар, туңгансыз бит! дип, учына тотырып, тыны белән җылыта-җылыта, өйгә алып кайта. Җамаякка су салып, бака балаларын шунда җибәрә. Иртән инде бака балалары корсаклары белән өскә әйләнеп агарып яталар.

Нурия аларны югарыгы бакчага алып менә, куян баласын күмгән төсле, кабер казып, Көмеш түтәй өйрәткән догаларны укып күмә.

Әнисе аның бу эшен бер дә яратмый.

— И гөлкәем, ник булышасың бака белән? Ир малай түгел бит син. Ичмасам, чигү чигәриең. Кулың үнәргә өйрәнә торые...

Әтисе Нуриянe яклап чыга:

— Тимә. Баланы балалыктан мәхрүм итмә. Җан иясен ярата белгән бала җүнсез бала булмас ул.

Әтисе белән әнисе, нәрсәдер бүлешә алмыйча, дәгъвалашып китәләр. Бу елларда алар гел тавышланышып торалар. Тату чагында да әтисе гел боек йөри, ул нәрсәдәндер, кемнәндер риза түгел.

Нурия күңеле белән әтисе яклы, ул аны үпкәләтмәскә тырыша, аның боек йөргәнен күрәсе килми. Шуңа күрә ул хәзер күбрәк вакытын урамда, су буенда, ир малайлар балык тоткан урыннарда үткәрә.

Нуриягә нинди сабак укыту турысында да әтисе белән әнисе уртак тел таба алмадылар. Әтисе кызын, Салагышка йөртеп, җәдит мәктәбендә укытырга тели. Әнисе моңа теше-тырнагы белән каршы:

— Юк-бар белән баланың башын катырмасана, хәзрәт! Син аны укый-яза белергә, ун эчендә исәп-хисап йөртергә өйрәттең бит инде. Шул җитмәгәнмени? Болай да бит ул саулыкка туймый. Төннәр буе китап өстендә күз бетәштереп, йөз саргайтып утырганчы, мин аны үзем йорт алып бару үнәренә өйрәтермен.

Тыштан караганда юаш кына күренсә дә, әтисе таякны тоткан җиреннән сындырырга ярата. Әнисе белән ул озак бәхәсләшми, үз дигәнчә эшли дә куя.

Меӊ тугыз йөз унынчы елның декабрь урталары. Җир-су туңган. Мул булып кар яуган. Зартугайның 362 йортыннан сыкылы күгелҗем һавага, туп-туры булып, төтен баганалары күтәрелә, янган салам исе, яңа пешкән икмәк исе таралган иде.

Габбас мулла йортыннан кара туры айгыр җигелгән артлы чана Салагышка таба җиңел генә элдереп китте.

Чанага аркасын терәп, төлке толыплы Габбас мулла утыра; аңа каршы көпәш кебек итеп төргән, мамык юрган эченнән алсу бите генә күренеп калган Нурия бара.

Сары каеш кебек сузылган саргылтым юлдан, чана табаннарын чыжылдатып, авылны элдертеп кенә чыктылар да атны сул тарафка — Салагышка таба бордылар.

Юлда Саклау урманы аша уздылар. Әтисе атны куаламады, дилбегәне кулына нык тотып, җай гына алып барды. Тоташ актан киенгән имәннәр, юл чатларына басып, озатып кала, урман юлы баш әйләндергеч дәрәҗәдә аулак иде. Шыкырдап очып киткән озын койрыклы саескан, юл буена ак шәлләрен бөркәнеп тезелгән чыршылар, тел белән әйтеп бирә алмастай тынлык Нуриянең күңелен биләп алды.

Ул әтисенә карап түгел, кышкы урманга карап барды.

Кара туры айгыр урман юлыннан хуҗа булып бара, аның гөрселдәтеп йөрәк какканы ишетелә, баш очындагы алма бизәкле калын дуга бару уңаена селкенеп-селкенеп куя иде.

— Кызым, туңмыйсыңмы?— диде әтисе.

— Ю-у-ук,— дип, иркәләнеп җавап кайтарды Нурия.

Әтисе дилбегә кагып чөңгереп куйды.

Ат аягы астыннан каты кар кисәкләре очып, тирә-якка чәчрәде, куәтле тыгыз җил, биткә бәрелеп, күздән яшь чыгарды.

Шулай да Нурия артына борылмады.

Каты шаулап сызгырып барган чана, атның баш очында инде тизрәк атына башлаган алма бизәкле дуга, каршы җилдән тузган ат ялы — болар барысы яңа, күңел кузгаткыч яңа иде.

Ат, җилдәй очып, урманнан кар даласына килеп чыкты.

Чуртанкүл болыннары башланды.

Инде хәзер Нуриянең күңелен чана юлы офыкка барып тоташкан урын биләп алды. Анда күк йөзе алсу-күгелҗем, кайдадыр болытлар артында кояш нурлы йөзен күрсәтә алмый интегә, шул урында алкаланып килгән саргылт бер балкыш хасил булган иде.

толым — үрелгән чәч
шыңшу — кәефсезләнү, зарлану, елау
яшь бөялә — яшь тыгыла
үнәр — һөнәр
дәгъвалашу — берәр нәрсәне таләп итү, бәхәсләшү
җәдит — яңа, яңача

Сораулар

1. Нурияне укырга-язарга кем өйрәтә?
2. Нурия әтисен ни өчен ярата?
3. Аның әтисе кем була?
4. Әтисе кызын нинди мәктәптә укытырга тели? Ул бу теләген тормышка ашырамы?
5. *Таякны тоткан җиреннән сындыра* дигән фразеологик әйтелмәне сез ничек аңлыйсыз?

Алтынчы башлам

IV

Төнге сәгать унберләр тирәсендә ишек шакыдылар. Нурия сәерсенеп караватыннан төште. Бу вакытта аңар шәриктәш иптәшләре дә, туганнары да килми торган иде. Солтан кайттымы? Ярабби, алай булгачыннан, нишләп ачмый тора соң әле ул? Кинәт күңеленә килгән шул уйдан, җанын биләп алган сөенеч ташкыныннан зиһене чуалып, берни уйлый алмас дәрәҗәгә килеп, ул ишекне барып ачты, кинәт: «Ай!»— дип кычкырып җибәреп, киредән япты. Ишек төбендә мескен бүрекле, билен кызыл пута белән буган чит-ят кеше басып тора иде.

Нурия, ашыгып, өстенә халат эләктерде, чәчләрен ашык-пошык төйнәп, башына яулык бәйләде. Шуннан соң гына икенче кабат ишекне ачарга җөрьәт итте. Бәлки, ачмаган да булыр иде, ишек артындагы кеше бик сак кына, иплән кенә тагын чиертте ишекне. Авыл мужигының ул кадәр сак кылануы мөмкин түгел, кем булыр бу? Ачаргамы, юкмы?

Ашыгып кына ачып-япкан чакта да кунакның йөзе таныш кебек чагылып калды — авылдашларыннан берәрседер. Күршеләрдер. Бәлки, Солтаннан хәбәр китергәннәрдер. Күңеленә Солтан килгәч, ул тагын сак кыланырга кирәген онытып, ашыгып барып ишекне ачты.

Бу юлы аның каршысында — шул ук кызыл путалы, бишмәтле, әмма мескен бүрекле түгел, ак чалмалы әтисе басып

тора иде. Ул аны тартып диярлек эчкә кертте, ашыктырып чишендерә башлады.

— Ярабби, әтекәем, бәгърем, нишләп йөрисең төн уртасында? Киләм дип хат язсаң булмас идемени? Мескен бүректән мин сине танымадым да бит. Исәнме? Нәрсә белән килдең? Поездмы, пароходмы? Ничек килеп чыгасы булдың, авырмыйсыңмы?

— Өйдә кеше юкмы? — диде Габбас мулла, бишмәтен, чалмасын салып.

Нурия аның шыпыртлап әйткән сүзеннән сагая калды.

— Юк, нигә алай дип сорыйсың?

— Әниең кайда соң?

— Аны Бишбалта карчыклары утырмага алып киткәннәр иде.

— Алай икән. Ярар. Утырып бер дога кылыйк.

Габбас мулла көрәктәй дәү кулын бит уртасына күтәрде. Нуриянең җанын айкап, Зартугайлар, Салагышлар, кыңгыраулы атларда килгән Габделхәлим абзыйлары, Таминдар Тураев биләмәләре күңелендә яңарды. Бөтен яшьлеге аның шуның белән тулы иде. Аны кинәт курку алды — узган, сызып ташланылган, киләчәктә кирәк булмаячак тормыш аны куркытты. Ул әтисе янына утырып кул күтәрмәде, әмма әтисен дога укудан да туктатмады. Дога арасына тормыш вактөяген, көнкүреш хәлләрен китереп кыстырды. Габбас мулла ул сүзләрне вак итеп кабул итмәде. Бу аның кызының, бердәнбер баласының тавышы иде, бу тавыш аңа үтә дә газиз иде. Күңеле аның бу йортка иминлек теләде, теле дога сүзләрен әйтте, колагы чишмә чылтыравыдай матур, яңгыравыклы, рәхәт тавышны, кызының тавышын тыңлады.

Дога кылып бетергәч, аңар инде икегә бүленмәскә, ягъни кызының тавышын дога сүзләре аркылы сөзеп алмаска, турыдан-туры ишетергә мөмкин булды. Рәхәтлек белән бергә, кызының тавышындагы сагаю чалымнары да аның күңеленә иңде, бу хәл аны вәсвәсәләндерде.

Нурия примуста чәй кайнатып алды. Сүзсез генә чәй эчтеләр. Аннары Нурия сорады.

— Киявеңне күрмәдеңме? Зартугайга килеп чыкмадымы әле?

— Күрдем. Килеп чыкты.

— Соң? Әйтеп бетер инде. Нигә соң бәгъремне теләсең, эти?

— Минекен күбрәк телделәр.

— Ничек итеп?

— Киявем җиремне тартып алды. Совет — йортымны.

— Моны ничек аңларга?

— Ничек аңлыйсың? Ничек әйткән — шулай аңла.— Габбас мулла, чал сакалын учы белән гасабилы угалап, кызының күзләреннән теләктәшлек эзләде.— Имам Каһарманов белән Мәрдән Мурзин авылны таларга керештеләр. Солтан— аларның беренче булышчысы. Җирне тартып алырга кирәк — ала. Газиз атасын да кызганмады. Җир эшкәртү ширкәтен таратырга кирәк — тарата. Күзен дә йоммый. Каһармановларга ияреп, йортымны конфисковать итәргә килде.

— Иттеләрме?

— Итмичә! Сәгате-минуты белән сүтеп алып киттеләр. Мунчада яшибез. Ә бит минем йорттан Гыйматдин Хаҗи малын эзләү дөрес микән? Хәнифә белән икәү без күпме интектек! Борыныбыз белән әрчедек пожар кисәвен...

— Инде нишләргә уйлыйсыз?

— Хода белсен. Түләп булмаслык налук китереп салдылар. Беләм мин аларны. Себер җибәргәнче тырышалар.

Нурия әтисенең соңгы сүзләрен Казанга килергә рөхсәт сорау дип аңлады, һәм ул курыкты. Өч ел рәттән рабфактан чыгарылуы күз алдына килде. Завуч Виннерга ялыну, Наркомзем бусагасын таптаулар, җыелышта Нух Галләм сөйләгән ямьсез сүзләр күңелендә яңарды. Әтисе аларга торырга килсә, ул мулла кызы булудан туктамый, нәсел-нәсәбе аны гомер буе эзәрлекли булып чыга. Әнисе белән алар ничек килешерләр? И каһәр суккан язмыш!

Нурия корымлы калай чәйнектән чәшкегә чәй агызды. Әтисенең чәй тәлинкәсен тырпайган бармаклары өстенә утыртып, сакал-мыегы эченнән алсуланып сузылган иреннәре белән шул тәлинкәне гүя үзенә тартып китерүен күңеле нечкәрер дәрәҗәдә күзәтеп утырды.

Чәй эчелеп беткәч, сөйләшер сүз дә калмады.

Басынкы, тонык чырай белән үзалдына карап байтак вакыт сүзсез утырганнан соң, Габбас мулла әйтте:

— Менә сиңа килдем инде, кызым, ни диярсең?

Нурия, җаны телгәләнгән хәлдә, калтыранган куллары белән аны муеныннан кочаклады, бите буйлап мөлдерәп күз яше агып төште:

— Әти... Син безгә килми торсаң иде...

сәерсенү — гаҗәпсенү
җөрьәт итү — батырчылык итү
вәсвәсәләнү — шөбһәләнү, шикләнү

Сораулар

1. Габбас мулла кызы янына ни өчен бик соң килә?
2. Нурия әтисен ничек каршылый?
3. Габбас мулланың йортын ни өчен тартып алалар?
4. Ул авылдан тагын нинди хәбәрләр алып килә?

V

Габбас мулла юньле-рәтле йоклый алмады. Төш күрә дә саташып уяна, төш күрә дә саташып уяна. Үзе тагын уянып торып утыргач, нинди төш күргәнен дә хәтерли алмый. Ярты төнгә чаклы шулай саташып чыкты.

У-уф! Кирәк бит шундый төш керергә! Ул, сәке йөзлеге кырыена ак ыштанлы аякларын асылындырып, күлмәк изүе аша тыгылып, йонлач күкрәген ышкый-ышкый, озак кына уйга батып утырды. Мыш-мыш йоклап яткан Хәнифәгә, аның күкрәгенә башын төрткән сабые Шәфикага, тәрәзәдән төшкән таң шәүләсенә моңсу гына карап торды. Хатыны белән кызының битләре төтен сыман күгелҗем күләгә эченнән йомшак, күңел кузгаткыч нәфис булып, алсуланып күренә, алар икесе дә, дөньяда юк кешедәй, рәхәтләнеп йоклый алалар. Алар өчен ике катлы чарлаклы йорт ни, мунча сәкесе ни! Нигә соң ул шулар кебек гамьсез була алмый? Дөнья малы шулай ук җан тынычлыгыннан кадерлерәкмени аңа?

Габбас мулла, ишекне шыгырдатып ачып, мунча алдына чыгып утырды. Өйне Имам Каһарманов әмере белән сүтеп алып киткәннән соң, бүре базы төсле ыржаеп калган кара чокырга карамаска тырышып, төнге салкынча һаваны бөтен күкрәге белән сулап, офык читенә өелешкән шәмәхә-кызгылт болытлар өеменә күзләре талганчы карап торды.

Кайдадыр, тегермән буасы янында, тартар кычкыра: тарт-пышвыйк, тарт-пышвыйк, тарт-пышвыйк. Бик еракта, Каф таулары артында кебек, каравылчы шакылдавыгы ишетелеп кала.

Дөнья кош сайраулары, каравылчы шакылдавыклары белән яши. Дөньяның үз агымы, аның Габбаста эше юк.

Иртәнге салкынча һава калтырата башлагач, ул тагын мунча эченә керде, һава авыраймасын өчен, ишекне ачык калдырып, үз урынына барып ятты. Күзенә йокы кермәде: Хәнифәнең тигез сулыш белән рәхәтләнеп йоклый алуына сәерсенеп ятты, шундук аны аклады: җанында бер генә дә борчу юк шул аның. Шәмсенисаның да, бәлки, җанында борчу юктыр, Нурия белән икесе чүкердәшеп кенә яши торганнардыр. Аңар хәзер Габбас кирәк түгел. Кызыл малчы Габделхәлим аларны бергә кушып бәхетле итмәкче иде. Морза кызы Шәмсениса белән буразнадан күтәрелгән мужик Габбас кушыла алмады: ничәмә еллар бергә гомер итсәләр дә, алар һаман икесе ике дөнья кешесе булып кала бирделәр. Шәмсениса аның белән араны мәңгегә өзү өчен берәр сылтау чыкканны гына көткән икән, өйләре янып китүгә, калага китеп барды, мәңгегә киткәнлеген, алар арасында бер генә төрле дә уртаклык юклыгын хәбәрсез ятуы белән аңлатты. Ул киткәннән бирле Нурия дә әтисен онытты.

Габбас мулланың моңар да сабырлыгы җитәр иде, ни генә димә, ул әле гаилә бәхетеннән мәхрүм түгел, аның әле үзе төсле үк мужик кызы — Хәнифәсе янында, багалмадай кызы — Шәфикасы янында, тик менә пожардан соң мең бәла белән җиткергән соңгы йортын тартып алып, үзен мунчада яшәргә калдырулары, киңәш сорап калага баргач, Нуриянең, аны караңгы чырай белән каршы алып, бүтән килеп йөрмәвен үтенүе Габбас мулланы тетрәтеп җибәрде. Шул минуттан башлап, аның өчен дөньяда яшәүнең кызыгы бетте...

Атна буе ул балтасы суга төшкән кеше кебек йөрде. Моңарчы кичергән гомерен күз алдыннан үткәрде. Җамалетдин крестьянның ишле гаиләсе, мәдрәсә җәфалары, казакъ арасында, далада үткәргән көннәре, аннары Шәмсениса, аннары муллалык... Муллалык дигәннән, ул үз акылы белән бер нәрсәгә барып җитте: муллалар өч төркемгә бүленә икән. Беренче төркем — шымчы муллалар. Боларның указлары була, болар жандармерия идарәсендә хисапта торалар, болар авыл халкы арасында барган барлык хәлләрне охранкага җиткереп, хәбәр итеп торалар. Болар Алланың барлыгына һәм берлегенә ышанмыйлар, болар өчен кеше җанын кыю бер тиен дә тормый һәм болар моны Алла исеменнән, патша хәзрәтләре исеменнән эшләп килгәннәр. Зартугайның Сөләйман хәзрәт шундый булган, эшләгән эшләренең Совет власте алдында кичерелмәс гөнаһ икәнен белгәнгә күрә дә ул аклар белән

бергә табан ялтыратты. Икенче төркем муллалар — шагыйрьләр. Гасыр саен андыйлар булган: Габделҗәббар Кандалый, Утыз Имәни, Мәрҗани. Боларның укымышы зур. Болар кеше җанының матурлыгына ышаналар, болар, халыклар алга китсен, аңы үссен дип, гомер буе тырышалар; патша ялчылары аларны эзәрлекли, кайберсенең иманын сындыра, әмма шагыйрьлектән туктата алмый. Әнә Даут мулланы ак офицерлар тураклап киттеләр. Аның язганнары кайчан да булса бер халык кулына тапшырылыр микән? Әллә ул түккән көч, җанын сарыф итеп җырлаган тойгылар мәңгегә тарих диварлары астында күмелеп калырмы? Өченче төркемгә кергән муллалар халык өчен иң зур эшне эшләгәннәр: гомер буе балалар укытканнар, кара халыкны агартырга тырышып яшәгәннәр. Аларга казна акча түләми, алар патша хәзрәтләренең дә сөекле балалары түгел, мәгърифәткә булган ихтирам, башкаларга да дөньяны таныту хисе аларны алга әйдәгән. Монысы — Габбас үзе. Аның шәкертләре хәзер кайда гына юк?! Күбесе дөнья өчен дә кирәкле кешеләр булып чыктылар. Казан каласына китеп, зур урыннарга кереп утырдылар. Алар халыкка азатлык бирдек дип күкрәк кагалар, алар мулла-мунтагай, кулак-куштан дип кычкыралар. Алар Габбас мулла кебекләр өстенә дә кемнәрнедер өстереп җибәрәләр. Әнә бит аны, йортсыз-җирсез калган байгышны. Бөкре Гафият хәл белешергә килгән булып мыскыллап китте:

— Нихәл, мулла абзый, тимер караватка сузылып, чарлаклы өйдә гәҗит укуы рәхәтрәк, иеме, мунча ләүкәсендә сузылып ятып укуы рәхәтрәкме?

— Бик рәхмәт, Гафият, хәл белә килүеңә, бу көнне сиңа бирсен,— диде Габбас мулла.

Карале хикмәти хода, Габбасның моңарчы күңелен нык итеп тоткан нәрсә икәү булган икән: берсе — кызы Нуриягә булган ышаныч, икенчесе — авыл халкының ихтирамын тою.

Хәзер боларның берсе дә юк. Кызы Нурия аны күңеленнән сызып ташлады. Аңа ата түгел, аңа үз җаны кадерле.

Көн-ай җәелгәнне Габбас мулла көч-хәл белән көтеп алды. Хәнифә уянгач, комганга җылы су салдырып, озаклап юынды. Юынып сөртенгәч, Габбас мулла пакь күлмәк-ыштан сорап алып киде. Төпченергә яратучан Хәнифә:

— Нәрсә, хәзрәт, әллә тагын Казанга барасыңмы?— дип сорады.

— Юк,— диде Габбас мулла. Хатыны самавыр куярга чарачага чыккач, сәке буена килде, юрганнан буынтыклы ак кулларын чыгарып, чайрап йоклаган Шәфикасы өстенә иелде, үбәргә курыкты, сакалы тиюдән баланың сискәнеп уянуы мөмкин иде, кулын күкрәгенә кушырып, бертын карап торды, борын канатын ачыттырып, бер тамчы күз яше төште дә сакалы эчендә югалды.

Габбас мулла ашыгып, артыннан куып килгәндәй кабаланып, урамга чыкты һәм кире әйләнеп кайтмады.

гамьсез — ваемсыз, бер нәрсә турында да уйламаучы
төпченү — берәр мәсьәләне бик җентекләп, тирәнтен тикшерү, кат-кат сорашу
чарача — мунча алды, чишенү урыны
чайрап — җәйрәп, иркенләп, таралып

Сораулар

1. Габбас мулла нинди уйлар кичерә?
2. Аның ни өчен дөньяда яшисе килми башлый?
3. Габбас мулланы ни өчен авыл халкы хөрмәт итә?
4. Бу әсәргә карата сезнең фикерегез ничек?

Шәүкәт Галиев

(1928 елда туган)

Татарстан Республикасының халык шагыйре Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа.

Ул — сугыш чорының кырыс чынбарлыгын, ачлыгын, ятимлеген үз җилкәсендә татып, әдәбият мәйданына сугыштан соңгы елларда килгән шагыйрьләрнең берсе. Аның исеме матбугатта 1948 елда күренә башлый. Беренче шигырь җыентыклары «Яңа көйләр», «Кичке утлар» илленче еллар башында басылып чыга. Туган авылы, аның эшчән кешеләре, табигате, күңелдә калган сугыш яралары, мәхәббәт хатирәләре турында язылган шушы беренче китапларында ук яшь шагыйрьнең халыкчан рухлы лирик таланты ачык сизелә. 1957 елда язылган «Әткәйгә хат» поэмасы үзенең драматик яңгырашы, кичерешләренең табигыйлеге белән илленче еллар татар шигъриятенең поэма жанрындагы уңышы итеп бәяләнә.

Шагыйрьнең 1960—1970 елларда дөнья күргән «Сиңа әйтер сүзем бар», «Сөенечләрем, көенечләрем», «Уйларым-серләрем», «Чынлык», «Тамчылар тамар чаклар» кебек җыентыклары язучыны югары зәвыклы, дөньяны һәм кешене үзенчә тасвирларга омтылган лирик шагыйрь итеп таныта.

Ш. Галиев шигырьләре композиторларның да игътибарын җәлеп итә. Аның «Раушаниям, бәгърем», «Утыр әле яннарыма», «Ник яңара сагышлар?», «Тамчылар тамар чаклар», «Күпме күзләр күреп онытылган» һ. б. шигырьләре халкыбызның яраткан җырларына әверелде.

Шәүкәт Галиев тормыштагы һәртөрле кимчелекләрне, кире типларны тасвирлаган күп санлы юмор һәм сатира әсәрләре авторы буларак та билгеле. («Гарантияле мәхәббәт», «Өйгә кайткач», «Шалт, Мөхәммәтҗан», «Сөзгәк үгез маҗаралары» һәм башкалар.)

Ш. Галиев — балаларның яраткан шагыйре. 1962 елда аның балалар шигырьләре тупланган «Камырша» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. Бу шигырьләр үз халкыңа, илеңә тугрылыклы булу, дуслык-туганлык, табигатькә һәм хезмәткә мәхәббәт, тынычлыкны саклау хисләре белән сугарылган. 1972 елда аңа «Шәвәли», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Кызык», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән» һәм 1966 елда чыккан «С папой в кабине» исемле шигырь китаплары өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. 1980 елда рус телендә чыккан «Заяц на зарядке» китабы өчен ул Халыкара бүләккә — Х. К. Андерсен исемендәге Почетлы дипломга лаек була.

1995 елда Шәүкәт Галиевкә Татарстанның халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелә.

ӘТКӘЙГӘ ХАТ

(өзекләр)

Бөек Ватан сугышында һәлак
булган әтием истәлегенә

* * *

Кояш төшкән Кайбыч урманнарын
Күз йомгач ук төштә күргәндә,
Сабый чакта таныш басуларны,
Чәчәкләрне сагынып йөргәндә,

Чит кырларда, әткәй, егылып калдың,
Чит туфрак ла булды бит юрган...
Чит чәчәкләр үсә яннарыңда,
Баш очыңда шаулый чит урман...

Кайда, әткәй, безнең өчен сине
Соңгы тапкыр күргән ул кырлар?
Адымнарың кинәт өзелеп калган,
Бөтен сагынуларың күмелеп калган
Кабереңә җитсен бу җырлар.

Син сагынган кырлар, игеннәрнең,
Чәчәкләрнең исе бар анда.
Юксынып гел сине төштә күргән
Имәннәрнең моңы бар анда...

«Мин унике яшьлек малай идем»

«Сугыш!» дигән шомлы аваз иртән
Бәгырьләрне телеп үткәндә,
Мин унике яшьлек малай идем,
Син фронтка чыгып киткәндә...

«Бәбкәм»,— диеп, нидер әйтмәк булдың.
Үзең, никтер, читкә карадың.
Дерелдәгән бармакларың белән
Чәчләремне генә тарадың.

Ахры, әткәй: «Син сабый шул әле,
Аңламассың...»— диеп тилмердең.
Мин, ваемсыз, капчыгыңнан алып,
Җылы сохарилар кимердем...

Сүзсез генә гел тәмәке тарттың.
Җыерылды бары кашларың.
Кинәт, торып, ничә еллар яткан
Зур тәпләрне ярып ташладың...

* * *

Былтыр төпләп кайткан каеныңның
Минем кадәр генә буе да,—
Тамырлары әле ныгымаган.
...Каен түгел, әткәй, уеңда.

Җил-яңгырда шулай улың кала.
Сындырмасмы сугыш давылы?
Элек син күтәргән бөтен йөкнең
Аңа төшәр хәзер авыры...

Тал биленә кулың салып тордың.
Кайнар битең җилне җылытты.
Тау битләрен күз яшедәй чиста
Чишмә чулпылары чылатты...

Бу сукмаклар, арба эзле юллар,
Каеннарың — бар да каласы...
Тал төбендә, сары авызын ачып,
Азык көтә карга баласы...

* * *

Соңгы тапкыр урам әйләндегез,
Соңгы тапкыр җырлап уздыгыз.
Гармун уфылдады, өзгәләнде...
Саубуллашып, җыр-кул суздыгыз.

«Китәм инде, дуслар, китәм инде,
Китәм генә инде, озатыгыз.
Кала җәйгән җылы урыннарым,
Сагынсагыз мине, ятыгыз...»

Җиттек инде басу капкасына,
Капчыкларны вакыт кияргә.
Сеңелемне шул чак иелеп алдың
Соңгы тапкыр кысып сөяргә.

Ябышты ул синең муеныңа,
Алалмас күк беркем аерып.
«Әткәй, китмә!»— диеп елап калды,
Сугыш алды,
алды каерып...

* * *

Үксез калган таллар башын игән,
Чишмәләр дә моңлы чылтырый.
Өй дә елый...
Тәрәз күзләрендә
Бөрчек-бөрчек тамчы елтырый.

Ишегалды шып-шыр булып калган,
Өйгә керсәм, бушрак тагын да.
Синең, әткәй, кая киткәнеңне
Төшендем мин тик шул чагында.

«Әткәй!»—диеп, үксеп чыгып чаптым.
Көпчәк эзе — басу юлында...
Киткән чакта, юансын дип биргән
Пәкең генә калды кулымда.

Башта сугыш минем күңелдә шул
Кинодагы кебек чагылган:
Безнекеләр җырлап алга барган,
Гел дошманнар гына егылган...

* * *

Ботинкасы, әткәй, ялт-йолт килә,
Күзем алалмадым Назардан;
Чиккән кәләпүше белән бергә
Әтисе алып кайткан базардан.

Кәләпүше миңа таман икән,
Сорагач, бер киеп каратты.
...Минем чәчнең төсен кояш алды,
Аякларны «чеби» канатты...

Ә кыш җиткәч, төннәр утырып, мин
Олтан салып кидем итегең.
Буран көнне сары туныңның да
Бөкләп бирде әнкәй итәген.

Менә шулай иртә олыгайдым,
Тормыш дилбегәсен тоттым мин.
Синең адым белән юлны башлап,
Зур сәфәргә яшьләй чыктым мин...

«Җылы урыным кала печәндә»

Хат ташучы үтеп киткән саен,
Тәрәзәгә барып ябыштык.
Өч ел буе көттек өметләнеп,
Өч ел буе, әткәй, ялгыштык.

Күңелләрнең чите китек иде,
Өч почмаклы хатың ялгады.
«Безнекеннән хәбәр бар!» — дип, әнкәй
Кем узса да әйтми калмады.

Туганнарга сөенеп укып йөрдем,
Күпме шатланмадым, көлмәдем!
Әткәй, әткәй, синең кулдан чыккан
Соңгы хатың икән, белмәдем...

Ул хатыңны алып укыдык без
Кырык өченче ел июньдә.
Кем уйлаган, шатлык булып, шулай
Кайгы керер диеп өеңә...

* * *

Ул төнне мин изелеп йоклаганмын,
Хатка каршы хат та язалмый.
Баш очымда басып торган әнкәй
Уятырга мине базалмый.

Сабанчының йокысы тәмле була,
Таңда тагын торып китәргә.
Дилбегәдән кулның бушаганын
Кичкә хәтле кирәк көтәргә.

Ә кич киттек төнге сменага,
Ундүрт яшьтәш — Мәсгуть, Якуплар.
Хәтерләтеп еллар ниндилеген,
Каенсарда калды окоплар...

Таңда кайткач, эреп киткәнмен мин,
Сиңа тагын җавап язалмый.
Баш очымда басып торган әнкәй
Уятырга мине базалмый...

* * *

Алгебрадан калган ак битләрне
Йорт хәлләре белән тутырып,
Өч көннән соң учак яктысында
Хат яздым мин, әткәй, утырып.

«Бәрәңгеләр инде чәчәк атты,
Бер бәбкәне тилгән алды,— дип.—
Син кайтканчы, көзгә, зур үсәрләр,
Әле тагын унау калды»,— дип.

Алъяпкычы белән күзен сөртеп
Тыңлый әнкәй. Өсти соңыннан:
«Керен чыгарып, оек бәйләп куйдым
Сиңа әйбәт бәрән йоныннан...»

Ябыштырдык. Ачып тагын яздык.
Күпме өстәсә дә бүлмәдем.
Өзгәләнеп язган бу хатымны
Укый алмасыңны белмәдем...

* * *

Тастымалга төргән өч бәрәңге
Басып тора бишмәт кесәсен.
Кытыклап ник һаман тамагымны,
Минут саен искә төшәсең...

Көзге юллар буйлап, фронт өчен
Ядрә кебек бодай ташыйбыз.
Тыгыз капчыкларга утырып, үзебез
Бәрәңгене мактап ашыйбыз.

«Стансадан тизрәк җитәр»,— диеп,
Зәңгәр ящикка мин хатымны
Төшерәм дә, тагын килер өчен,
Кайтыр юлга борам атымны...

Икмәгем, дим, сезнең окопларга
Хатым белән бергә килмәсме,
Дусларына әткәм: «Бу тәмле ипи —
Улым күчтәнәче»,— димәсме...

...Сөенәм дә бүген тормышымның
Артканлыгын күреп гел яме.
Уйлап куям: «Онытмадыммы соң
Арыш икмәгенең чын тәмен?»

* * *

Җиденчене бетереп чыккан елым,
Китапларым тора шүрлектә.
Эшләр, әткәй, тыгызланып китте,
Карый алмыйм анда үрелеп тә...

Мин укыйсы китапны шул фашист
Сугыш ялкынында көйрәтте.
Бураznада, арбаларда тормыш
Нужа әлифбасын өйрәтте.

Китапларым кебек, хыялым да
Күңел шүрлегендә калырмы?
Еллар тынычланса, килер көзгә,
Бәлки әле, укый алырмын...

Звонок тавышы әнә...
Күңел тулып
Күздән ташымасын дип, көчкә
Тыелып торам.
Бригадирым килде:
— Кеше кирәк, энем, бер эшкә...

* * *

Башым әле тәрттем генә кебек,
Әнкәй инде селкеп уята:
— Тор, улым, тор,
ат кәтүе кайтты.
Соңга кала күрмә, таң ата!

Күзне тырнап ачып җиргә тәшәм,
Җылы урыным кала печәндә.
Яңа гына сауган җылы сәтне
Чүлмәгеннән тотып эчәм дә

Йәгәнемне алып эшкә китәм.
Сәгатем юк.
Чамам — таң минем.
Тәш җиткәнен беләм күләгәдән,
Будильнигым уртак — чаң минем.

Кино-фәлән әзрәк эләкте шул,
Гел таң күрдем мин ул заманда.
...Киноларның күбесе онытылган,
Ә таңнарым истә һаман да!

«Сәнәк каерылса да, билләр түзде»

Нинди генә эшләр күрмәделәр
Ныгымаган безнең яшь куллар!
Йөгереп калды арба асларында
Куна барып үткән күп юллар.

Сәнәк каерылса да, билләр түзде,
Салам өйдек, кибән куйдык без.
Билдән карга батып, урман кистек,
Ызбаларга чатлык уйдык без.

Атлар егылганда, сыер җиктек,
Көрәк белән кырны актардык.
Көтә идем: әткәй кайтыр менә,
Шушы кырлар буйлап атлар дип.

Нинди генә эшләр күрмәделәр
Ныгымаган безнең яшь куллар!
Йөгереп калды арба асларында
Куна барып үткән күп юллар...

* * *

Кырык дүртнең язы авыр булды,
Сыгылдырып басты иңнәргә.
Без дә, әткәй, моннан фронт тоттык,—
Солдатларга була тиңләргә.

...Кар киткәнче азык бетеп китте,
Бер сәнәк тә салам калмады.
Чәчкечләргә тиздән җигәр атның
Улагына ул көн салмадык...

Каралтының иштек түбәләрен...
Җилләр белән калды төренеп.
Арык атлар кабыргасы кебек,
Сайгаклары торды күренеп.

Яткан атлар тора алмый иде...
Күп хәлләргә ул чак күнелде.
Син колхозга авызлыклап төшкән
Туры айгыр шул яз күмелде.

* * *

...Чәчүлек тә юк иде шул безнең,
Стансадан булды ташыйсы.
Атлар анда йөксез җитә алмас...
Гаҗиз булып җилкә кашыйсың.

Кайбер күңелләрне «Җирләр шулай
Буш калырмы?» дигән шик телдә.
Җиргә төшми калган орлык бит ул
Тими калган ядрә шикелле...

Кечкенә арба тартып, юлга чыктык,
Капчык салып кайттык иңнәргә.
Без дә шулай моннан фронт тоттык,—
Солдатларга була тиңләргә.

Учлап бодай сипкәч тубалыннан,
Яшь аралаш бабай ник көлде?
Вакытында төшкән орлык бит ул
Чәчрәп тигән ядрә шикелле!

* * *

Әткәй, әткәй, мин соңгарак калып
Сөйлим бугай сиңа бу хакта.
Әрнемәсен, дидек, йөрәкләрең,
Язмадык шул сиңа ул чакта.

Басуларда — урман кебек әрем,
Тамырлары киткән тирәнгә.
Әрем ачыларын,—
бар ачыны
Мин дәшмичә йотып өйрәнгән.

Бер «колесный» йөрде бураznада,
Иснәргә дә җитми төтене.
Безнең генә майламаган сабан
Җир кимерә шыңшып көн-төне.

Арып кайткач, читән буйларыннан
Яшь-яшь кычытканнар өзәм мин.
Витаминнар анда күп ди бугай...
Күп булса да, нишлим, түзәм мин.

«Ятимлекнең беләм ни икәнен»

Очар кошлар кире кайткан кебек,
Булып синең йөргән якларда.
Окопларны күреп, кире кайтты
Сагынып язган безнең хатлар да.

Элгәреге сугышлардан калган
«Кара пичәт» сүзе телләрдә.
Көтмәгәндә капкаларны шакып,
Кермәде ул инде кемнәргә...

Һаман әле кайта безнең хатлар...
Кача, әткәй, ул төн йокыбыз —
Аптырагач, үзебез сиңа язган
Шул хатларны җыелып укыйбыз...

Хат ташучы яхшы хәбәрләрне
Торган саен күбрәк ташыды.
...Теге көзне сиңа дип үстергән
Казларны, әткәй, бүре ашады...

* * *

Кырык дүртнең кышы узып китте...
Без белмәдек күңел тынгысы.
Сөенешеп укыган теге хатың
Кайгылысы булды, соңгысы...

...Ә бер көнне, зарыгып хат көткәндә,
Почта авыр хәбәр китерде.
Кош теледәй кәгазь
энкәйне — тол,
Безне кинәт ятим иттерде...

* * *

Календарьлар күпме яфрак койды,
Саргайдылар инде хатларың...
Сагынган ла саен укый торгач,
Мин күңелдән инде ятладым.

«Яраландым Матвей курганында,
Госпитальдә булдым»,— дигәнсең.
Соңгы рәсмең килде шушы хатта,
Соңгы шинелеңне кигәнсең...

Ничә еллар инде, керфек какмый,
Алмыйсың гел миннән күзеңне.
Менә-менә әйтеп бирерсең күк
Әйталмыйча калган сүзеңне...

Яңа сүзләр килеп чыкмасмы дип,
Хатың укып, күзем талдырдым.
Бер-ике сүз нигә өстәмәдең,
Кайткач сөйләргә дип калдырдың?

* * *

Мин унҗиде яшьлек егет инде,
Синең күлмәкләр дә бик таман.
Тәннәреңнең җылысын саклый алар,
Сине хәтерләтеп гел-һаман.

Бүрегең тора чөйдә, туның тора,
Син аларны инде кимәссең.
«Әйдә, улым, бер аппетит өчен
Утын кисеп керик!» димәссең.

Тырнавычлы чалгың ята әнә,
Тоеп синең кулның эзләрен.
Салам башлы шушы өйгә, эткәй,
Сеңеп калган күпме сүзләрең!..

Шахтер лампаң тотып, бусагада
Син ничәмә тапкыр күрендең?!
Җир астында йөреп исән кайттың,
Җир өстендә йөреп күмелдең.

* * *

Күзләремә ничек моң сеңмәсен,
Сабыйлыкның тыеп шуклыгын,—
«Эткәй» диеп кеше дәшкән саен,
Әрнеттереп сизелә юклыгың.

Сыңар канат
сыңар канат инде,
Талпынса да, ерак киталмый...
Бәхет кошы чая оча бит ул,
Сыңар канат куып җиталмый.

Ятимлекнең беләм ни икәнен...
Китаплардан нигә укырга?
Йөрәккә ул эчтән генә йоткан
Кайгы яше булып утырган.

Кайталмасың синең белсәм дә мин,
Торган саен күбрәк сагынам.
Үзән буйлап поезд тавышы килә
Ерак станция ягыннан...

«Син күрмәдең, әткәй, бу көннәрне»

Тарих тынды, әткәй, синең өчен
Кырык өчнең июнь аенда.
Сиңа сөйләр хәлләр шактый әле,
Син күрмәдең Җиңү маен да.

Син күрмәдең, әткәй, бу көннәрне...
Рәшәткәгә әнкәй сөялеп:
«Исән кеше кайтыр, безнең генә
Кайтмас...» — диде, яшькә төелеп.

Авыз тутырып «әткәй» диялмыйча,
Яшьтән ятим калган балалар:
— Күп әтиләр кайтты, нигә кайтмый
Минем әти?— диеп калалар.

...Бу ятимнәр соңгылары булсын,
Кеше каны бүтән акмасын.
Безнең әткәйләргә төшкән бомба
Музейларда гына саклансын.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрь бу поэманы кемгә багышлаган?
2. Поэмада кайсы чор чагылдырыла?
3. Шагыйрьнең бала чагы ничек үткән?
4. Әтисез үсүнең авырлыгын сурәтләгән юлларны табып укыгыз.
5. Поэманы тулысы белән укып чыгыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.
6. *Син күрмәдең, әткәй, бу көннәрне* дигән бүлекне ятлагыз.

Хәсән Сарьян

(1930—1978)

ӘТКӘМ ҺӨНӘРЕ

(өзекләр)

Әткәй! Мин сине бик аз хәтерлим — төштә генә күргән сыман. Ләкин мин синә охшаган диләр, хәтта балта һөнәрең дә миңа күчкән. Әткәй, Хәсән улы Салихҗан! Синең рухыңа багышлап яздым бу әсәремне.

Беренче бүлек

Гаяз палубага чыкты.

Кояш шактый күтәрелгән. Күтәрелгән дә, Агыйделне күреп, тик туктап калган — менә-менә сикереп төшәр дә йомшак су өстеннән тәгәрәп китәр сыман тора иде. Әле кичә генә аяз көннәр булуга инде өмет өзгән, яңгырга изелеп яткан күңелне бүгенге кояш тыеп булмас көч белән җилкендереп җибәрде. Күңел генә түгел — Агыйдел буйлары да бер талпынып, яшәреп киткәндәй булды. Юкса кичә, инде шаулап яфрак ярыр, чәчәк атар бер заманда, вакытсыз салкыннан гаҗиз калган агачлар катып-бөршәеп утыралар иде.

Кинәт ярдан Гаязның күзенә ап-ак нәрсә чалынып китте. «Эреп бетмәгән кармы әллә?» дип төбәп караса — күрче, тау битендә бер оя шомырт агачы чәчәк атып утыра икән. Гүя алар, шомырт агачлары, «Җылы көн, бәлки, булмас та, аңа карап без чәчәк атмаска тиешмени?» дигән төсле, яз башында

посып яткан, ә май җиткәч килеп җиткән салкын көннәргә үч итеп, шулай эшләгәннәр иде. Әле яфракланып кына килгән башка агачлар арасында фәкать шомыртның, уйлап та бирмичә, шау чәчәктә утыруында Гаяз язның бөек көчен күрде: бу — башкаларга өндәү иде, бу — «Яз җиттеме, безне бернәрсә дә туктата алмас!» дигән сүз иде.

Инде су шактый кайткан — Агыйдел, итәкләрен җыеп, үз ярына төшә башлаган. Ихтимал, төшеп тә беткән булыр иде, ләкин бер атна яуган яңгырдан соң ул тагын мөлдерәмә тулган: тугай җирләрдә таллар бил тиңентен суда утыра иде әле. Шулай да быел Агыйдел рәхәтләнеп җәелеп китә алмаган: күрәсең, кыш карсыз килгән. Су күп елны Агыйдел болай гына булмый, болыннар гына түгел, авылларны да су баса. Шуңа күрә бу тирәнең кешеләре Агыйделнең биек ягын «Кар ягы» дип, ә язларын су эчендә кала торган ягын «Идел эче» дип йөртәләр дә.

Инде башка пассажирлар да уяна башлады. Уянган бере палубага чыгып баса иде. Пароход исә, Гаяз күңеледәй ашкынып, чапкан ат тизлеге белән алдыра гына. Менә Агыйдел, калын урман үсеп утырган тауга килеп төртелү белән, аңа тибеп кенә җибәрде дә борылып әрәмә эченә кереп китте. Бу инде — соңгы борылма. Бу инде — туган як. Һәр җире татлы хатирә уяткан туган туфрак иде... Әнә Күгәрчен болыны. Анда Гаязның бөрлегәнгә килгәне бар, ашаганнан калганын күп күрсәтер өчен, чиләк төбенә яфрак тутырып кайтканы бар... Әнә Шәяхмәт бакены. Гаязның балыкны Шәяхмәт карттан сорап алып кайтканы бар... Өзелеп сагындырган җирләр!.. Гаязның әтисе бу җирләр турында күп нәрсә белә иде: «Әткәй сөйләрие: монда җылан җире бетә, Гәрәй дачасы башлана, дип күрсәтерие. Гәрәй — безнең җиденче буын бабабыз. Ә Гәрәйнең бабалары болгар булган, Масрадан күчеп килгәннәр, соңыннан ак патшага баш иеп барып, күп җир алганнар — шуннан башкорт булып киткәнбез...» — дип сөйләргә ярата иде аның әтисе. Ниндидер шәҗәрә буенча үзен уникенче буынга чыгара иде. Димәк, Гаяз — ниндидер болгар бабайларның унөченче буыны; димәк, унөч буын буена аларның канына шушы җир һавасы сеңгән. Һәм менә туып үскән якларны яңадан күрү белән, аның һавасын яңадан иснәү белән, Гаязның йөрәге сагыштан бер кысылып куйды да ләззәт белән тибәргә тотынды; каны, язгы Агыйделдәй, тамырларына тулып ага башлады.

Кояшка кызынып, тирә-якны бернинди уйсыз-хиссез карап барган бер пассажирның:

— Хәзер нинди пристань була? — дип соравы Гаязны айнытып җибәрде.

— Хәзер безнең пристань!— диде ул һәм каютага кереп китте.

Гаяз, урын-җирен тапшырып, билетын алды да төшәргә чыгып китте.

Пароход пристаньга җитеп килә иде инде. Катыктыр, күкәйдер сатарга төшкән апалар, бала-чагалар, пароходтан сыра эчеп чыгарга җиң сызганып торган абзыйлар күренде.

«Телеграмманы алдылар микән?» — дип уйлады Гаяз.

Пароход сузып бер кычкыртты да, агымга каршы туктар өчен, кыйгая төшеп борыла башлады. Ун-унбиш минуттан инде ул, пристаньга каерып бәйләнгән килеш, пассажирларның төшеп-утырып беткәнен юаш кына көтеп тора иде.

Пристаньдагы халык беравыздан «Гаяз!» дигән кебек булды. Кемдер аның кулыннан чемоданын алды. Гаяз, берәүгә дә карамыйча, әнисенә таба атлады. Ике якка аерылып, аңа юл бирделәр. Әнисе, кечкенә генә булып, иң артта басып тора иде.

Аның шатлыкны — аз, хәсрәтне күп күргән карт йөзен күргәч, Гаязга әллә ничек булып китте. Ул ни әйтергә дә белмичә:

— Исәнме, инәй! — дип күрешергә кул сузды. Үзе, елап җибәрмәс өчен: — Әллә җылап торасың инде, инәй?— дигән булды.

Әнисе гаепле кешедәй тиз генә күзен сыпырып карады. Күзләре коры иде. Ул хәзер еламый. Ул бая елаган иде. «Атасы мәрхүм каршы алалмады бит»,— дип, кайгыдан елаган иде. Хәзер еламый. Хәзер аннан да бәхетле кеше юк. Бәхеттән кеше елыймыни!

Кифая әби улын, ике-өч яшьлек чагындагы төсле, күкрәгенә кысып сөярдәй булып торган иде, ләкин каршысына килеп баскан егетне күргәч, ни эшләргә дә белмичә аптырап калды. Төпчек улы шулхәтле зур иде — бер көндә генә сөеп бетерерлек түгел иде. Шулай да ана, үрелеп булса да, аның битләреннән сыйпап, иңсәләреннән сөеп алды.

Җаинәт апасы көлеп җибәрде:

— Инәйнең буе җитмәгәч, Әбел-Гаяз да риза булып иелеп тора тагын.

Гандәлиф җизнәсе дә килгән икән.

— Җә инде, әби, каенишне безгә дә бир, без дә тотып карыйк,— диде ул.

Күрешү бик озакка китте. Һич көтмәгән кешеләр, хәтта пристань буенда трай тибеп йөргән бала-чагасына хәтле, «Исәнме»... дип, Гаязның кулын тотып ала иде. Ләкин каршы алучылар арасында иң якын ике кеше: этисе һәм абыйсы юк иде.

Үзләре генә калгач, Гаяз:

— Бәлкабзый нишләп төшмәде?— диде.

— Аламаланып тора,— диде әнисе.— Кан төкерүдән бик курыккан идек, ярый әле, Ходай үзе саклап үтте, ахры. Язы да бик салкын килде бит.

— Врачлар ни ди соң?— диде Гаяз.

— Мондагы брачлар нәмә әйтсен инде? Үпкә чире дип әйтәләр. Мин яшь чакта безнең авыл Әскәр абзый шуның белән чирләгәние. Мәгәр аның бит алмалары алсуланып торырие. Кушкаен авыл мулласына баргач, французчихүткәсе дип җибәргән. Житен тастымалны чылатыр иде дә Әскәр абзый, аркасына ябар иде, чылатыр иде дә ябар иде. Шулай терелде. Таһирҗанның дәвасын белүче юк.

Җаинәт коры гына:

— Юкны сөйләмә син, инәй. Врачлар белә: алар шуңа укыган. Таһирҗан былтыр җәй бик әйбәтләнгән иде әле. Эткәйнең үлеме генә бетерде аны,— диде.

Эткәй дигәч, Гаяз, туктап, Агыйделгә карады. Пароход инде кузгалып киткән. Пристаньдагы халык ярга чыгып баскан. Шул тирәдә буталып йөрүчеләр дә, озатучылар да тик басып торалар. Гаязлар киткәндә дә яр буе шулай сабыр гына озатып калган иде. Тик этисе мәрхүм генә, пароход артыннан ияреп бара-бара, менә шушында «өзелеп» калган иде...

гаҗиз калган — аптырап калган
бөрлегән — ежевика
ләззәт — наслаждение
хәсрәт —кайгы
инәй — әни
төпчек — иң кечкенә
бәлкабзый — *бәләкәй абзый*дан үзгәргән
аламаланып тора — авырып тора

Сораулар һәм биремнәр

1. Автор бу әсәрен кемгә багышлап язган?
2. Гаязны туганнары ничек каршылый?
3. Улының әнисе белән очрашуы ничек сурәтләнә, шул турыда сөйләгез.
4. Гаяз этисе турында нинди хатирәләрне искә төшерә?
5. Әсәрдән табигать күренешләрен тасвирлаган урыннарны табып укыгыз.

Икенче бүлек

Таһирҗан таза чакта тракторда эшләгән иде. Ләкин Гаяз армиягә киткән көзне, боз ватылып, тракторы-ние белән Агыйделгә төште. Күргән кешеләр: башта бүреге калыкты, бик озак торгач, үзе килеп чыкты, диделәр.

— Андый хәлнең теләсә кемгә килүе мөмкин,— диде Гандәлиф.

— Теләсә кемгә килмәгән бит. Тәчиб кортка малаена әнә килмәгән. Чыгып өлгергән. Нигә ул да төшмәгән?..

— Кулыңны бик селтәмә, ашыңны түгәсең,— диде аңа хатыны. Кави кулын селтәвендә булды.

— Кыскасы шул: безгә техника төс түгел.Безгә балта төс. Акман нәселе балта тотарга тиеш!..

— Ярар,— диде Кави.— Әйдә, тарт әле, Таһирҗан, гармуныңны! Өз әле үзәгемне!

Ул сандык өстендә торган баянны үрелеп кенә алды да Таһирга сузды.

Бөтенесе дә, ашаудан туктап, Таһирга текәлделәр. Таһир моңсу гына кыяфәт белән баян каешларын иңбашына киде. Күрек тартырга иркенрәк булсын өчен, уң як читкәрәк шуышты. Башын кырын салгандай итте дә, йөзен сулга бора төшеп, бармакларын сәдәфкә тигезде — өзмичә-йолыкмыйча, өф итеп тоткан нәрсәдәй кадерләп кенә, «Гөлҗамал» көен уйный башлады. Дөнья онытылды: гүя аның көннәр начарлыктан көчәйгән сырхавы беткән, күкрәге дә чәнечми, үпкәсе дә саф һаваны бөтен күзәнәкләре белән сулый иде; Таһир гүя үзе дә моңга әверелгән, ә уйнаган көеннән үләргә яткан кешене дә терелтерлек көч-сихәт агыла иде...

Көйне бер тапкыр уйнап чыкканчы, аңа беркем дә кушылмады. Икенче тапкырында гына Җаинәт көр тавыш белән күтәреп алды:

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал...

Гадәттә, башын гел уен-көлкегә салып, шалтырабрак йөргән Җаинәт, җыр башлау белән, бөтенләй үзгәрде: язгы кояштан караеп тупасланган бите йомшарып, мөлаемланып китте. Ул җыр гына җиткән хыялый еракларга текәлгән дә Гөлҗамал атлы кызның үзедәй сагышланган иде. Аның гәүдәсендә бернинди боргалану юк, бернинди интегү юк — тын алганы да беленми иде, ул тынны да, шул тикле озын көй уртасында бер генә кабат ала иде. Авызы бер илле генә ачылган, иреннәре бөтенләй кыймылдамый кебек; әгәр авызын ялгыш зур ачып җибәрсә, көйнең бар моңы түгелер сыман: күкрәгеннән ургылып чыккан тыны аны берьюлы өреп чыгарыр кебек иде. Аның тавышы һаман көчәя барып, тоташ бер агымга, дәрьяга әйләнде; язгы Агыйделдәй җәелеп, бөтен тарафны күмеп ташлады; өйгә генә сыймагач, тәрәзә пыялалары, стена бүрәнәләре аша урамнарга чыкты, Миңештә, Агыйдел буйларына төште...

Көй табындагыларны берьюлы әсир итте, көндәлек мәшәкать белән ката төшкән күңелләр назланып, хисләр сафланып, җанга һәм тәнгә табигый халәт кайтты. Гаяз җырның тагын бер ягын белде: «Гөлҗамал» төсле сагышлы озын көйләр дә кешене изми икән — алай гына да түгел, җанга азык иңдерә, илһам бирә икән; туган җиргә, бөтен җан иясенә ягымлы мәхәббәт уята, йөрәкне җилкендереп, куллардан бөркет канаты ясый икән. Һәм син бер талпынасың да үз-үзеңнән күтәрелеп, моңдай көчле ашкыну белән югарыга ашасың. Туган җиреңне әнә шул биеклектән күрәсең, күтәрелгән саен туфрак якыная бара — Агыйдел ярларына кабат төшеп, сине үстергән, сине ир иткән нык җиргә нык итеп басып торасы килә, аунап-тәгәрәп, капланып ятасы килә...

Туган җир! Нигә син шулхәтле кадерле, кочаклап үбәрлек якын икән? Бездәге иң бөек тойгы ата-бабаларыбыз дөнья көткән, дөнья калдырган менә шушы кечкенә йорттан башлана бит! Әле син — нарасый бер бала гына: күкрәк сөтен имгәндә, күзеңне ачалмасаң да, авызыңны ачып, башыңны чайкый-чайкый имчәк эзләгәндә, син үзеңнең дөньяда яшәвеңне дә белмисең, ләкин шул вакыттан ук инде синең карыныңа йөз төрле ризыкны алмаштырган татлы сөт ага; сөттән соң тамагың кибеккәч син, авызыңны очлайтып, тагын нидер сорыйсың — аны әниең генә белә: су сорыйсың син,— һәм әниең балкашык белән генә синең авызыңа су сала... Сөт һәм су! Ана күкрәгеннән килгән сөт нинди пакь булса,

җир күкрәгеннән сөзелеп кенә чыккан чишмә сулары да — шундый ук. Шулай булгач, Анага булган мәхәббәтнең — сөттәй, Җиргә булган мәхәббәтнең чишмәдәй сафлыгына гаҗәпләнмәгез...

Менә нинди тойгылар уята үз җиренң, үз көенң!..

Җыр агылды-агылды да тагын үз ярларына кайтып туктады. Өй эче тып-тын булып, үтә сәер булып калды, ләкин җыр колактан китмәгән, колак төбендә генә эленеп тора иде. Беренче булып Кави телгә килде — Таһирның бармакларыннан күзен алмаган килеш:

— Әллә сөягe юкмы соң, апай, синең ул бармакларыңның? — диде.— Моңа чаклы бер дә игътибарлап караганым юк иде.

— Гел сөяк кенә, абзый!

— Ышанмыйм, булмас! Сөяк булса шул төсле йөри алмас иде. Күз иярми бит, парень! Телләренә тигән кебек тә түгел.

— Безнең каениш уйный инде ул!— диде Гандәлиф тә.

— Нигә мине берегез дә мактамый әле?— диде дә Җаинәт, кычкырып көлеп җибәрде.

— Синең турда сүз особый әле,— диде аңа Кави.— Син нигә алай Гандәлиф җизнәй алдында: «Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы» дип җырлыйсың? Җәле, җизнәй, үзенә дә җырлап җибәр әле берне, хотя бы: «Син сөймәсәң, бүтән бар...» дип.

— Бик җырлар иде дә, җыр белми бит,— диде Җаинәт.

Алар сөйләгәннәрне елмаеп кына тыңлап утырган Гандәлиф:

— Мин күңелдән генә җырлыйм,— диде.

— Нишләп син, җизнәй, һаман күңелдән генә җырлыйсың? Кырыкка җитеп тә, кычкырып җырлый белмисең? — диде Кави.—Әйдәле алай булгач, Таһирҗан апай, тартып җибәр әле минем көйне, үзем җырлап күрсәтим әле җизнәйгә.

Таһир маңгаена бәреп чыккан тирен сөртте дә Кави гына җырлый белгән көйне башлады. Кави карлыккан тавыш белән җырлап җибәрде:

Агыйдел буйлары ямьле,
Бакенщик буйлары ком.
Эчкәйләрем тулы кайгы,
Тышкайларым тулы моң...

Ләкин соңгы өлешен икенче кабатлап тормады.

— Миннән дә булмый икән, авыр,— дип кул селтәде.

* * *

Таралышканда, Гандәлиф тагын эшне искә төшерде.

— Шулай да, каениш, синең чутта мин Әсфәндияров абый белән сөйләшеп куям,— диде.

Гаяз дәшмәде. Локман аның колагына үрелде:

— Бик ашыгып барма, улым. Башка эш чыгарга тора...

— Ял ит тә дип әйтмиләр бит, ә!—диде Кави.—Әбел-Гаяз апай, карама шулар сүзенә! Ял ит...

Гаяз аларны озата чыкты. Кич җилсез, болытсыз иде. Күк, көндезге зәңгәрлеген җуеп, карасу төскә кергән. Кояш инде «Идел эче»нә төшеп баеган, ләкин офык чите саргылт-кызыл төсләр белән ялкынланып яна иде әле.

— Кояш аязга баеды. Көннәр әйбәтләнеп китәр инде, боерган булса,— диде Локман.

Алар киткәч, өй эче бушап, тынып калды. Гаяз кергәндә, Таһир әле өстәл яныннан кузгалмаган иде. Гаяз да аның янына килеп утырды. Сөйләшер сүзләр бөтенләй юк кебек. Мондый чакта, күңелләр урыныннан кузгалган чакта, телләр түгел, туганлык хисләре сөйләшә иде. Таһир, энесенә елмаеп, яратып карап торганнан соң, ничектер борчылып сорап куйды:

— Китәргә кайтмагансыңдыр бит, апай?

Бу сорау аның теленә, Гаяз кайтып, туган өй бусагасына аяк баскач ук килгән иде. Тик ул сорарга һаман кыймый торды, сораса, «Китәм шул, күрергә генә кайттым» дигән җавап ишетер сыман иде.

Ләкин Гаяз:

— Юк, бәлкабзый, китәргә кайтмадым,— диде.

— Китмә шул...— диде Таһир.

сырхавы — авыруы
кортка — карчык
сәдәф — төймә
көр — күтәренке

Сораулар һәм бирем

1. Таһирҗан белән көз көне нинди вакыйга була?
2. Җыр табындагыларга ничек тәэсир итә?
3. Туган җир нинди тойгылар уята? Әсәрдән шул урынны табып укыгыз һәм сөйләгез.
4. Таһир белән Гаязның туганлык хисләре ничек чагыла?

5. Сез нинди татар халык көйләрен яратып тыңлыйсыз?
6. Геройларның сөйләмнәренә игътибар итегез, аларның үзенчәлеге нәрсәдә?

Унбишенче бүлек

Бригадирлар әкрен-әкрен генә чыга башладылар. Председатель Хәйдәргә калырга кушты. Хәйдәр ипләп кенә кузгалган җиреннән кире утырды. Сәйдәшев, аның белән Фаизга тыңлыйсызмы дигәндәй карап алганнан соң, Гаязга сөйли башлады:

— Мин сине бүген шуңа чакырткан идем, апай: теге вакытта машина сораган идең бит. Бирә алам мин сиңа машина. Тик яңа түгел. И бүгеннән утырып та китеп булмый.

— Юк,— диде Гаяз.— Әйтүең өчен рәхмәт, Сәйдәшев агай. Тик мин машинага утырмыйм. Бу көннәрдә мин бик күп уйландым. Кулымда — балта, күңелемдә — эткәй. Кайсы гына коралына килеп тотынмыйм — яныма эткәй килеп баскандай була, өйрәтеп, сөйләшеп торгандай була. Эткәй кулына җайлашып беткән кораллар минем кулга да ип килеп тора. Миңа алар белән эшләү җиңел, рәхәт... Беркөн син мине, Сәйдәшев агай, балта эшенә чакырган идең. Аннан соң без шул турыда Фаиз белән дә сөйләштек. Менә мин килдем. Языгыз бер бригадага.

— Вот рәхмәт! — диде Сәйдәшев. Урынында сикереп куйды. Аннары, менә күрдегезме дигәндәй, бер Фаизга, бер Хәйдәргә карап алды.

— Рәхмәт, Сәйдәшев агай,— диде Гаяз.— Болай булгач, мин эшкә иртәгә үк килә алам.

Сораулар һәм биремнәр

1. Председатель Гаязны ни өчен чакырта?
2. Машина йөртүдән Гаяз нигә баш тарта? Аңа нинди һөнәр ошый? Шул юлларны табып укыгыз.
3. Әсәр ни өчен «Эткәм һөнәре» дип атала?
4. Повестьны тулысынча укыгыз.

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

КАЗ ӨМӘСЕ

Татар халкының бик күңелле бәйрәмнәре, бай гореф-гадәтләре һәм йолалары бар. Мәсәлән, ел фасылларына бәйле Сабантуй һәм Нәүрүз бәйрәмнәре, ислам диненә бәйле Корбан бәйрәме, йолаларга бәйле каз өмәсе һ. б. Еллар үткән саен бу бәйрәмнәр яңара, аларның формалары үзгәрә һәм эчтәлекләре тулылана бара.

Каз өмәсе ничек оештырыла һәм үткәрелә соң? Күп көч, вакыт сарыф итә торган авыр эшне ирекле рәвештә, түләүсез, бергә-бергә башкаруны өмә дип йөртәләр. Халыкта күп эшләр өмә җыеп башкарылган. Әле хәзер дә кош-корт сую, йорт күтәрү һ. б. эшләр вакытында өмә җыялар.

Каз өмәсе һәр елны көз ахырында яисә кыш башында үткәрелә. Ул — бүтән өмәләрдән аермалы буларак, башыннан азагына кадәр кызлар өмәсе. Башка өмәләр кебек, каз өмәсен оештыру һәм уздыруның да үзенә генә хас тәртибе бар. Казлары күп кешеләр иртәгә өмә уздырыласы көнне кызларны чакырып чыгалар. Беренче чиратта туган-тумачаны, күрше кызларын дәшәләр. Гадәттә, өмәгә чакыру эше балаларга кушыла.

Әйтелгән көнгә кызлар иртүк килә. Казларны эшкәртәләр, зур канатларын йолкып сыдыралар. Иң оста чистартылган казның бер генә шырпысы да (канат төпләре) калмый һәм бер җирдә дә тиресе ертылмый.

Казлар йолкынып, эчләре алынып, аяк-башлары чистартылып бетә. Өмәнең иң күңелле вакыты — чистартылган казларны, көянтә башларына элеп, кызларның су буена юарга баруы. Алар белән, сыдырылган канатларны алып, яшүсмер кызлар да бара. Алар канатларны су юлына бара торган сукмак буйлап тараталар. Моньсы киләсе елда хуҗабикәнең казлары сукмакны тутырып йөрсен дигән теләк белән эшләнә. Кызларның кайберләре өй җыештырырга кала.

Су буеннан кайтуга, кызларны «каз коймагы» көтеп тора. Каз коймагына күршедәге ятим карчыклар да чакырылырга мөмкин.

Ашаганнан соң, кызларның бер өлеше, каз боткасы пешерү өчен, көйледә ярма күзләргә (төеп чистартырга) китә. Караңгы төшәр алдыннан өмәдә катнашкан кызларның әниләре ашка чакырыла. Аларга каз шулпасында токмачлы аш, каз калҗасы белән бәрәңге, каз ите белән бәлеш пешерелә.

Каз өмәсенең иң кызыгы кич белән. Кызлар, матур күлмәкләрен киеп, өмә булган өйгә җыелалар. Җор телле, тапкыр сүзле кызлар ишек төбенә баса. Алар каз канаты «сата». Егетләр өйгә һөнәрләрен күрсәтеп, канат «сатып» алганнан соң гына кертелә.

Кунак җыю, кунак сыйлау татар халкында гомер-гомергә дәрәҗәле эш исәпләнгән. Туганнарың, күршеләрең, авылдашларың белән аралашып, ашка-суга йөрешеп яшәү тормышны тагын да ямьләндереп җибәргән. Өмәдә эшләнгән эшләр, уен-көлке хатын-кызга ел буена җитәрлек дәрт биргән. Ул көнне хатын-кызларның ни дәрәҗәдә уңган булулары ачыкланган.

Каз өмәсенең кичке уеннары К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында бик ачык сурәтләнә. Тула басу өмәсе турында да татар халкының бик матур җыры бар. Мондый бәйрәмнәргә багышлап, язучыларыбыз шигырьләр, композиторларыбыз көйләр иҗат иткән.

КАЗ ӨМӘСЕ

Эльмира Шәрифуллина

Каурый сибәм су юлына,
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш күрсәтеп,
Ярлар табып калыгыз.

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы төймәсе.
Борынгыдан килгән гадәт
Татарның каз өмәсе.

Каз мамыгы яшь киленгә
Түшәк, ястык, юрганга.
Мамыктай кулын сөйгәнең
Иңнәреңә куйганда,

Сокланырсың сылу кызга,
Чыңлый чулпы төймәсе.
Борынгыдан килгән йола
Татарның каз өмәсе.

Юл аягы — каз коймагы —
Сыйлансаң, суык тимәс.
Каз йолка белмәгән кызны
Егет солтаны сөймәс.

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы төймәсе.
Борынгыдан килгән йола
Татарның каз өмәсе.

Сораулар

1. Татар халкының нинди милли бәйрәмнәре бар?
2. Сез аларның кайсыларын яратасыз һәм бәйрәм итәсез?
3. Каз өмәсе турында нәрсәләр белдегез?
4. Татар халкының милли бәйрәмнәренә, йолаларына бәйле нинди җырлар беләсез?

ЭЧТӘЛЕК

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ. Бәетләр 4

«Сак-Сок» бәете турында 5

Сак-Сок 6

«Сөембикә бәете» турында 10

Сөембикә бәете 12

Галиәсгар Камал 18

«Беренче театр» комедиясе турында 19

Беренче театр 20

Комедия 37

ТАТАР ТЕАТРЫ ТАРИХЫ 38

С. Гыйззәтуллина-Волжская 42

Габдулла Кариев 44

Гаяз Исхакый 47

«Сөннәтче бабай» повесте турында 48

Сөннәтче бабай 49

Гомәр Бәширов 55

Туган ягым — яшел бишек 56

Повесть 74

Васил Маликов 76

Кави Нәҗми 77

Миңлебикә кодагыйның кайгысы 78

Хәят апа 83

Солтан Габәши 86

Опера 88

Муса Җәлил 89

Бер үгет 91

Имән 92

Катыйльгә 93

Җырларым 94

Мәрьям Рахманкулова 96

Галия Кайбицкая 99

Харис Якупов 102

«Хөкем алдыннан» картинасы турында 103

Габдрахман Әпсәләмов 106
«Ак чәчәкләр» романы турында 107
Ак чәчәкләр 108
Нәби Дәүли 130
Яшәү белән үлем арасында 131
Шамил Рәкыйпов 146
Чәчәкләр сөйли белә 147
Атилла Расих 158
«Ишан оныгы» романы турында 159
Ишан оныгы 160
Гариф Ахунов 168
«Идел кызы» романы турында 169
Идел кызы 170
Шәүкәт Галиев 181
Әткәйгә хат 182
Хәсән Сарьян 194
Әткәм һөнәре 194

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ 203

Каз өмәсе 203

Учебное издание

Хабибуллина Закира Нуриевна
Фардиева Халида Газизовна
Хузиахметов Анвар Нуриахметович

ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 8 класса
средней общеобразовательной школы
с русским языком обучения
(для учащихся-татар)

3-е издание, пересмотренное

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Хәбибуллина Закирә Нуриевна
Фәрдиева Халидә Газизовна
Хуҗиәхмәтов Әнвәр Нуриәхмәтович

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рус телендә урта гомуми белем бирүче
мәктәпнең 8 нче сыйныфы
өчен дәреслек
(татар балалары өчен)

Яңартылган 3 нче басма

Редакторы *Т. Р. Шакирова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкҗанова*
Корректоры *Р. Ә. Фәйзуллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Басарга кул куелды 24.05.2005. Форматы $60 \times 90^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 13,0 + форз. 0,25. Тиражы 22 000 д. Заказ К 5/105.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
httr: //magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.

Х. Якупов. Хөкем алдыннан